
# КЫЯМӘТ КӨНЕ




ХАРУН ЯХЪЯ

Көръәндә үзенчәлекле рәвештә аңлатылган Кыямәт Көне белән һичшиксез каршыланачаксыз. Ул көнне бөтен ия булганнарыгызның, хәтта үзегезнең гәүдәгезнең дә сездән ераклашканын күрәчәк һәм яп-яңа бер терелү белән тереләчәксез.
Сезне көткән мәңгелек тормышта, бу дөньядагы белән чагыштыра алмаслык нигъмәткә, рәхәтлеккә һәм хозурга ия булувыгыз өчен, Аллаһ сезгә әле дөньяда булган вакытыгызда биргән форсатны кулланырга тиешсез. Моның өчен эшләнүве кирәк булган бердәнбер нәрсә: Аллаһка иман итү, Аның каршылыксыз буларак биргән нигъмәтләренә шөкер итү һәм Ахирәт Көненең шиксез бер хакыйкать икәнлегенә инану.
Бу китапта язылганнар сезне көнлек шөгыльләрдән һәм фани теләкләрдән бер мизгел өчен булса да аерып, яшәүнең бар булувындагы асыл максатны күрүвегезне булдыра. Бу бөек һәм авырлыклы көн килеп җитүдән элек, сезне “шиксез хакыйкать буларак” каршыланачак Кыямәт Көне белән уяруны максатланган. Бу уяру - әһәмиятле бер уяру. Чөнки мондый бер көннән һәм бу көннән соң булачаклардан гафләт эчендә яшәгән һәркеше тарафыннан шаһит булыначак вакыйгалар, чыдый алмаслык булачак һәм Ахирәттә бу кешеләр дә мәңгелек авырлыклар белән каршылашачак.



Харун Яхъя псевдонимын кулланучы Аднан Октар, 1956нчы елда Анкарада туды. 1980нчы еллардан алып көнебезгә хәтле имани, гыйльми һәм сәяси темалар белән бәйле бик күп әсәрләр хәзерләде. Бу әсәрләрдән тыш, язучының эволюционистларның фабрикацияләрен, идеологияләренең яраксыз һәм Дарвинизмның канлы идеологияләр белән булган караңгы баглантыларын фаш итүче бик әһәммиятле әсәрләре бар. Язучы тырышлыгының асыл максаты – Көръән тәблиген (чакырувын) дөньяга ирештерү, моның аркылы кешеләрне Аллаһның барлыгы, берлеге һәм Ахирәт кебек асыл имани темалар турында уйлануга этәрү һәм инкарчы системаларның черек фундаментларын һәм дөреслектән тайпылганлыкларын күрсәтү. Шулай итеп, бүгенгә кадәр 60 телгә тәрҗемә ителгән әсәрләр, дөньякүләм масштабта бик күп санлы укучылар тарафыннан күзәтелә бирә.

Харун Яхъя көллияте, Аллаһның рөхсәте белән, 21нче йөзьел дөнья кешеләрен Көръәндә белдерелгән хозур һәм солыхка, дөреслек һәм сәгадәткә ирештерүгә сәбәп булачак.


بسم الله الرحمن الرحيم
الله
رسول
محمد

# УКУЧЫГА

Бу китапта һәм башка әсәрләрдә дә эволюция теориясенең бетүвенә аерым бер урын бирелүвенең сәбәбе - бу теориянең һәртөрле дингә каршы булган фәлсәфәнең асылында булганлыгы. Яратылуны һәм шулай ук Аллаһның барлыгын инкяр иткән Дарвинизм, 150 ел буенча күп кенә кешеләрнең иманын югалтувына яки кешеләрне шикләндереп, аларның иманнарының какшауна сәбәпче булган. Шуның өчен, бу теориянең бер уйдырма булганлыгын күрсәтү бик әһәмиятле иман вазыйфасы. Бу мөһим хезмәтнең бөтен кешеләргә ирешүве исә катлаулы. Кайбер укучыларыбызның, бәлки тик бер генә китабыбызны уку мөмкинлегенә ия булганлыкларыннан, һәр китабыбызда, кыска булсада, бу темага урын бирелде.

Белгертелергә тиеш булган башка бер хосус, китапларның эчтәлеге белән бәйле. Язучының бөтен китапларында иман белән бәйле булган темалар Коръән аятьләренә күрә аңлатыла, кешеләр Аллаһның аятьләрен өйрәнергә һәм шулар буенча яшәргә чакырыла. Аллаһның аятьләре белән бәйләнгән темалар укучының асылында һичбер шик яки сорау калдырмыячак формада аңлатыла.

Бу аңлатылу вакытындагы җитди, гади, тоташ ысул китапларның җиде яшеннән алып җитмешкәчә булганнарга, ягъни һәркем тарафыннан җиңел аңлашувна сәбәпче була.

Бу китаплардагы тәэсирле һәм ячык аңлату рәвеше аларны “бер сулышта укылган китаплар” рәтенә кертә. Хәтта динне кискен рәвештә инкяр иткән кешеләрнең дә, бу китапларда аңлатылган хакыйкатьләрдән тәэсирләнүве һәм аңлатылганнарны инкяр итә алмауларпы күренә.

Бу китап һәм язучының башка әсәрләре укучының барытик үзе тарафыннан укыла алганы кебек, җыелма хәлдә дә укылырга мөмкин. Бу китаплардан файдаланырга теләгән бер группа укучыларның берләшеп, җыелышып китапларны укулары, тема белән бәйле булган үзләренең фикерләре һәм тәҗрибәләре белән уртаклашувы ягыннан файдалы булачак.

Моның белән бергә, барытик Аллаһнын ризасы өчен генә язылган бу китапларны таныту һәм аларның укылувын булдыру бөек бер хезмәт булачак. Чөнки язучының бөтен китаплары исбатлау һәм ышандыру ягыннан гаять көчле. Шул сәбәпле, динне аңлатырга теләгәннәр өчен иң тәэсирле ысул – бу китапларны башка кешеләр тарафыннан укуга этәрү.

Китапларның артында язучының башка әсәрләрен таныткан булек булганлыгының мөһим сәбәбе бар. Аның аркылы, бу китапларны кулына алган кеше, югарыда сүз ителгән сыйфатларга ия булган һәм сәяси темаларда файдалана алачагы бай бер китап көллиятенең булганлыгына шаһит булачак.

Бу әсәрләрдә, башка кайбер әсәрләрдәге кебек, язучының шәхси фикерләрен, шикле урыннардан алынган аңлатмаларны, изгелекне ихтирам итмәгән начар әхълакны, ихтирамсыз ысулларны, өметсезлек бирүче, шикле аңлатмаларны тапмаячаксыз.

# КЫЯМӘТ КӨНЕ

*Кеше алдында булганын да ( бетмәс киләчәгендә  дә) гөнаһлы рәвештә тормыш сөрергә теләр. “Кыямәт Көне кайчан?”- дип сорар. Әмма, “күзлер сукыраеп, Ай каралгач”. Кояш белән Ай берләшкән вакытта. Кеше ул көнне: “Качу кая?”, - дияр. Юк, сыгынырлык һичбер урын юк. Ул көнне соңында китерелеп карар кылыначак урын барытик Раббыңныкыдыр.*

*(Кыямәт сүрәсе, 5-12).*

**ХАРУН ЯХЪЯ**

## ЯЗУЧЫ ҺӘМ ӘСӘРЛӘРЕ ХАККЫНДА

Харун Яхъя псевдонимын кулланучы язучы Аднан Октар, 1956 елда Анкарада туды. Башлангыч, урта мәктәп белән бергә лицейны Анкарада тәмамлады. Аннан соң Истанбулдагы Мимар Синан университетының гүзел сәнгатьләр факультетында һәм Истанбул университеты фәлсәфә бүлегендә белем алды. 1980 нче еллардан алып хәзерге көнгәчә иман, фән һәм сәясәт белән бәйле бик күп әсәрләр хәзерләде. Болардан тыш, язучының эволюционистларның яңлышлыкларын, идеологияләренең уйдырма икәнлеген һәм Дарвинизмның "канлы" идеологияләр белән бәйле булганлыгын фаш итүче бик күп һәм мөһим әсәрләре бар.

Харун Яхъяның әсәрләре якынча 30 000 рәсемнән һәм тулаем алганда 45 000 биттән торган бер көллияткә керә. Һәм бу көллият 63тан артык телгә тәрҗемә ителгән. Язучының псевдонимы инкярчыларга, аларның, фикерләренә каршы көрәшкән ике пәйгамбәрне хәтерләтеп, аларга хөрмәт йөзеннән Харун һәм Яхъя исемнәреннән тора. Язучы тарафыннан китапларның тышлыгында Аллаһ рәсүле (с.а.в.)нең тамгасы кулланылган булувы исә, китапларның эчтәлеге белән бәйле. Бу тамга Көръәни-Кәримнең Аллаһның соңгы китабы һәм соңгы сүзе, пәйгамбәребез (с.а.в.) нең исә соңгы (Хатәмүл әнбия) пәйгамбәр икәнлеген мөһерли.

Язучы бөтен әсәрләрендә Көръәнне һәм Аллаһ Рәсүленең сөннәтен юл күрсәтүче итеп алган. Шулай итеп, инкярчылыкка корылган барлык фикри системалар тарафыннан фундаменталь буларак якланган претензияләрне бөтенләй сүзсез калдырып, соңгы сүз әйтүне максатлаган һәм камиллек иясе булган Аллаһ рәсүленең тамгасы, бу соңгы сүзне сөйләү ниятеннән язучы тарафыннан бер дога буларак кулланылган.

Язучының бөтен әсәрләрендәге асыл максаты - Көръән тәблиген (чакырувын) Дөньяга ирештерү, шуның аркылы кешеләрне Аллаһның барлыгы, берлеге һәм Ахирәт кебек асыл, иман белән бәйле булган хакыйкатьләр турында уйлануга этәрү һәм инкярчы системаларның черек һәм ялган уйдырмаларын фаш итү.



Харун Яхъяның әсәрләре Һиндыстаннан Америкага, Англиядан Индонезияга, Польшадан Босния-Герцеговинага, Ипаниядан Бразилияга, Малайзиядан Италияга, Франциядан Болгарияга һәм Россияга кадәр Дөньяның бик күп илләрендә ярatылып

укыла. Инглиз , француз, алман, итальян, испан, португаль, урду, гарәп, албан, рус, уйгур, Индонезия, Малайзия, бенголи, кытай, кишваһили (Танзания теле), һауса (Африкада таралган тел), дһивелһи (Мавританияда кулланыла), Дания һәм Швеция кебек бик күп телләргә тәрҗемә ителгән әсәрләрдән һәм алар чит илләрдә күп кенә китап укучы тарафыннан күзәтелеп бара.

Бөтен Дөнья буенча күп кешеләр тарафыннан укылган, көтеп алынган бу әсәрләр, бик күп кешенең иман итүвенә, бик күбесенең дә иманнарының көчәюенә, артувына вәсилә булып тора. Китапларны укыган, җентекләгән һәркем бу әсәрләрдәге хичакрымәтле, үзенчәлекле, җиңел аңлашылучан һәм җитди ысулның, акыллы һәм фәнни алымнарның барлыгына шаһит була. Бу әсәрләр дәвамлы тәэсир, кискен нәтиҗә бирү, инкяр итeлә алмау сыйфатларына ия. Бу әсәрләрне укыган һәм алар турында җитди буларак уйланган кешеләрнең, материализм фәлсәфәсен, атеизм һәм башка яңлыш карашларны һәм фәлсәфәләрне җитди буларак яклауларын дәвам итүләре мөмкин түгел. Чөнки язучының әсәрләре аларның фикри нигезләрен юк итә, черетә. Моннан соң шундый карашларны һәм фәлсәфәләрне яклауны дәвам итү бары тик эмоциональ киреләнү, эмоциональ кабул итмәү сәбәпле генә булырга мөмкин. Заманыбыздагы бөтен инкярчы агымнарның Харун Яхъя көллияте каршында, үзләренең яраксыз икәнлекләрен күрсәтү белән бергә, җиңелеп барганлыклары күренә.

Һичшиксез, бу сыйфатлар Көръәннең хичакрымәт һәм камил аңлату үзенчәлекләренә ия булганлыгыннан килә. Язучы үзенең әсәрләре белән мактану халәтендә түгел, барытик кешеләрне Аллаһның тугъры юлына, хакыйкатькә эндәргә генә ниятле. Басылган һәм таралган әсәрләреннән матди мәнфагать күрми, андый максатлардан саклана. Күп хакыйкатьләрне ирештерүче, кешеләр күрмәгән нәрсәләрне күрсәтүче, кешеләрнең тугъры юлны табуларына вәсилә булучы бу әсәрләрнең укылувына сәбәпче булу бик әһәмиятле бер хезмәт икәнлеге аңлашыла.

Бу кыйммәтле әсәрләрне тарату урынына, кешеләрнең зиһенләрен бутаган, фикер буталчыгы яралдырган, шик һәм шөбһәләрне таратуда, иманны коткаруда көчле һм кискен тәэсире булмаганлыгы гомуми тәҗрибә белән расланган китапларны тарату исә, көч һәм вакыт югалуга гына сәбәпче булачак. Иманны коткару максатыннан башка, язучысының әдәби көчен белдерүгә юнәлгән әсәрләрдә дә, бу тәэсирнең була алмаячагы ачык күренә.Бу мәсьәләдә шикле булганнар, Харун Яхъя әсәрләренең бердәнбер максаты динсезлекне черету һәм Көръән әхлагын тарату булганлыгын, бу олы хезмәтендәге тәэсирнең, уңышлы булуның һәм җитдилекнең ачык буларак куренувен укучыларның гомуми хуплауларыннан аңлый алалар. Белергә кирәк, җир йөзендәге золым һәм буталчыкның, мөселманнар чиккән изаларның төп сәбәбе – динсезлекнең фикри хакимияте. Болардан котылуның юлы исә, динсезлекнең фикри яктан җиңелүве, иман хакыйкатьләренең ирештерелүве һәм Коръән әхлагының кешеләр аңлап яши алырлык формада аңлатылувы булып килә. Дөньядагы һәркөн артып баручы золымга, әхлаксызлыкка һәм буталчыкка игътибар ителгәндә, бу хезмәтнең булдыра алынган кадәр тиз һәм тәэсирле булырга тиеш икенлеге аңлашыла. Киресенчә булганда бик соңга калынырга мөмкин.

Бу мөһим хезмәттә баш рольга ия булучы Харун Яхъя көллияте, Аллаһның теләге белән, 21 нче гасыр кешеләрен Көръәндә белдерелгән хозур һәм салыхка, дөреслек һәм гаделлеккә, гузәллек һәм сәгадәткә ирештерүгә вәсилә булачак.

у китаптагы кулланылган аятьләр Али Булачның “Көръәни-Кәрим һәм төрекче аңлатмасы” исемле хезмәтеннән алынды.

**w w w . h a r u n y a h y a . c o m**

**h t t p / / e n . h a r u n y a h y a . t v**

# ЭЧТӘЛЕК


Кереш сүз ....................................................................10

Кыямәт Көне якынлашып килә ..........................................12

Кыямәт Көне булачак вакыйгалар ....................................19

Космосны Аллаһ яратты ...................................................50

Космосның улеме артыннан ............................................78

Үлем белән башланган асыл тормыш ...............................108

Нәтиҗә ..........................................................................128

Дарвинизмның соңы .......................................................130

# Кереш сүз

***...Ай каралгач. Кояш белән Ай берләшкән вакытта.Кеше ул көнне: “Качу кая ?”,- дияр. Юк, сыгыныплык һичбер урын юк. Ул көнне соңында китерелеп карар кылыначак урын барытик Раббыңныкыдыр. (Кыямәт сүрәсе, 8-12)***

Тормышыгызга юнәлеш биргән кешеләрне, вакыйгаларны тагын бер кузаллагыз. Кайбер нәрсәләргә ирешергә тырышып, “яшәү өчен көрәш” алып барасыз. Тормышыгызның куп кенә әйберләренә нык игътибар итеп, алар турында тирәнтеп уйлансагыз. Әмма, тормышыгыз барышында икеләнмәгән хәлдә уйланырга теләнмәгән һәм сез качкан темалар да бар. Өстәвенә, тирә юнегездәге кешеләрнең күпчелеге дә сезнең белән бер фикердә. Боларның берсе, бәлки дә иң әһәмиятлесе үлем – чарасы табыла алмаган бер “соңдыр” аларга күрә. Үлем кебек галәмнең бетүвенә китерүче Кыямәт тә кешеләргә бик ерак булып тоела. Кыямәт Көне булачак вакыйгалар кешеләр тарафыннан бик аз беленә, алар турында уйлану аларны куркуга сала. Бу теманы онытып, курку тоймыйча яшәүне акыллылык санарлар. Бердә чигенмичә шундый тормышны сайларлар.

Кешеләр иң күп Кыямәт Көненең җанлы-җансыз һәрбарлык өчен “соңгы көн” булувыннан тәэсирләнер. Кыямәт Көне Дөнья тормышының, хәтта бөтен галәмнең соңгы көне, ләкин берүк вакытта, Ахирәттәге мәңгелек тормышның башлангычы. Ул көнне кешеләрнең барчасы да яңа терелү белән тереләчәк. Дөнья тормышларында Аллаһка һәм бу көннең килүвенә иман иткәннәрне җәннәт, инкярчыларны Җәһәннәм көтәчәк. Шуңа күрә, бу көннең килүвен белгән, көткән берәр

кеше өчен Дөньяда булган вакытында ук үлем, Кыямәт һәм Ахирәт кебек хакыйкатьләрдән качуның мәгънәсе юк. Киресенчә, Кыяməттә булачак вакыйгалар һәм үлем хакыйкате аны тагын да күбрәк хәрәкәткә китерәчәк, Аллаһ юлында изге гамәлләр кылуга этәрәчәк, Ахирәткә юнәлтәчәк, Аллаһка якынайтачак. Барытик иман иткәннәр генә Кыямәт Көнненең тасвирлана алмаслык вакыйгаларыннан курку тоймас хәлдә булачаклар. Мөэминнәрнең хәсрәт эчендә булмаганлыкларын һәм курычакрымыячакларын Аллаһ бер аятендә шулай белдерә:

***Юк, кем изге гамәл кылып үзен Аллаһка буйсындырса, аның өчен Раббы хозурында әҗер (бүләк) бар. Алар өчен курку юк һәм алар хәсрәтләнмиячәкләр. (Бакара сүрәсе, 112)***

Дөньяда килеш бу хакыйкатькә иман китереп, кирәгенчә хәзерләнгән кеше исә, ул авыр көнне үзенең иминлектә булачагын белә. Чөнки Көрьәнгә иман китереп, асыл тормышның Ахирәт тормышы икәненә төшенгәндер ул. Үлемнең барлыгыннан качмый торып, Аллаһка гыйбадәт кылуда тәккәберләнмәгәндер ул. Мондый кеше Ахирәт тормышында чиксез гүзәллекләргә тап бучачак. Кыямәт Көне Аллаһның нуры да аның белән бергә булачак. Иман иткәннәр Көрьәндә болай шатландырыла:

***Ул көнне Аллаһ пәйгамбәрне һәм аның белән бергә иман иткәннәрне түбәнчелеккә төшермиячәк. Нурлары алларыннан һәм уң якларыннан хәрәкәт итәр. Диярләр ки: “Раббыбыз, нурыбызны бөтен кыл (тулыландыр), безне кичер. Шиксез, син һәрнәрсәгә көч җиткерүче.” (Таһрим сүрәсе,8)***

Бу китап сезгә Кыямәт Көнен һәм ул көнне булачак вакыйгаларны аңлатачак, ул авыр көн белән кисәтәчәк. Асыл мәсьәлә, Кыямәт Көненең барлык кешеләрне дә көтүче хакыйкат булувы. Шиксез каршыланачак булган бу бөек хакыйкатькә әһәмият бирмәү һәм аның турында уйланмау акыллылык итеп саналырга тиеш түгел. Бу китаптагы Көръән аятьләре аркылы ясалган ачыклаулар Кыямет Көненең барлыгы һәм хак булганлыгы турында уйлануны булдырычак.

Киттапның максаты һичшиксез булачак бу көн белән сезне кисәтү, мондый бер көндә иминлек эчендә булувыгыз һәм мәңгелек җәннәт тормышын казанувыгыз өчен сезгә юл күрсәтү. Кыямәт Көненең акылларга дәһшәт бирүче вакыйгаларга сәхнә булганлыгы, кешеләрне аның турында уйлануга юнәлдерү ягыннан бик әһәмиятле. Шул сәбәпле, Кыямәт вакытының үзенчәлекләрен нечкәлекләре белән китап буенча сезгә танытып, аларның хак икенлегенә тукталачакбыз.

# КЫЯМӘТ КӨНЕ ЯКЫНЛАШЫП КИЛӘ

***Хакыйкать шул ки, Кыямәт сәгате якынлашып килә бирә, анарда шөбһә юк. Чыннан да, Аллаһ кабердә булганнарны терелтәчәк. (Хаҗ сүрәсе, 7).***

Үлем адым-адым якынлаша. Яшь булсагыз да, карт булсагыз да, үткән һәр көн, хәтта һәр минут белән үлемгә тагын бераз якынлашасыз. Заманга каршы торалмыйсыз һәм үлемнең якынлашувына һич чара таба алмыйсыз. Ни кылсагыз, нинди хәзерлекләрәгез булса да, һичбере дә сезне һәм тирә юньдәгеләрегезне фани булудан коткара алмый. Дөньядагы һәрнәрсә кебек, сез дә тормышыгызның соңгы көненә таба атлый бирәсез.

Әмма, Дөньяда үлемгә барытик кеше генә дучар ителмәгән. Башка бөтен җанлылар, җир йөзе, хәтта бөтен галәм дә уләчәк, алар юк булачак көн билгеләнгән. Ул көннән соң Дөнья тормышы бетәчәк. Юк булу тик дәһшәт бирүче, ни дәрәҗәдә икәнлеген һичбер кеше күз алдына китерә алмаслык кадәр куркыныч булган хәлдә, шул ук вакытта, күркәм бер “соңгы көн” дә булачак. Җир йөзендәге һәрнәрсә җир белән тигезләнәчәк, йолдызлар себерелеп түгеләчәк, кояш караланачак. Шул заманга хәтле җир йөзендә яшәгән бөтен кешеләр бер урында тупаначаклар һәм бу көнгә шаһит булачаклар. “Соңгы көн” инкярчылар өчен авыр көн булачак. Һичшиксез, бу көннең хуҗасы - галәмнәрнең Раббысы Аллаһтыр.

Кыямәт якынлашып килә. Күпчелек кешеләрнең инануларына

киресе буларак, Кыямәт һич тә ерак түгел. Ул көнне Дөнья белән бергә Дөньядагы бөтен нәрсә дә юкка чыгачак. Дөньяви файда өчен булган ашкынулар, теләкләр, ачу тотулар, нәрсәнедер көтү, шәһвәт (җенси теләк), дошманлык һәм ләззәтләр бетәчәк. Киләчәккә юнәлгән планнарның мәгънәсе калмаячак. Аллаһка кайтарылачагын оныткан һәркем өчен ул бик яраткан, мәңгелек тормыштан хуп күргән Дөньяның, бөтен алдатучы байлыкларның, гүзәллекләрнең һәм мәшгуль иткән нәрсәләрнең бетүве булган көн килгәндер. Бу көнне кешеләр Аллаһның барлыгына кискен рәвештә шаһит булачак, онытырга теләгән үлем көне белән кара-каршы калачак. Инде Аллаһны һәм Ахирәт тормышын онытып кичергән бу кыска гомер тәмамланды һәм яңа бер башлангыч көтәдер үзен. Бу башлангыч һич бетмәячәк һәм һич тә инкярчыларга сәгадәт (бәхет) китермәячәк. Бу бетмәячек тормышның беренче мизгеленнән ук башланган газап шундый көчле ки, аны хис иткәннәр газап урынына "үлемне" һәм "юк булуны" теләячәкләр. Бу тормышның башлангычы - Кыямәт сәгате. Һәм, һичшиксез, "Кыямәт сәгате якынлашып килә".

## ДӨНЬЯ ТОРМЫШЫ ФАНИ ҺӘМ ҮЛЕМ ШИКСЕЗ БЕР ХАКЫЙКАТЬ

Балалык чагыгызның беренче көненнән алып киләчәккә таба билгеле бер максатка юнәлерсез яки башкалары тарафыннан юнәлдерелерсез. Ихтимал ки, шулар белән каршылашырсыз: яшегез тулгач бер гаиләгез һәм эшегез булачак. Тагын да күбрәк акча казану һәм тагын да рәхәтрәк яшәү өчен чара эзләрсез, балаларыгызны тәрбияләп, аларның киләчәккә сездән тагын да әйбәтрәк тормыш итүләрен теләрсез. Атнада бер гаиләгез белән җыелып ял итәрсез. Эшегезне дәвам итеп, калган вакытыгызны өегездә үткәрерсез. Берничә җитешсезлектән башка, тормышыгыз тәртипле рәвештә дәвам итәр. Бик четерекле тәэсирле ситуациаләр белән дә гел каршылашмассыз. Тормышыгыздагы һәрнәрсә тагын да алданрак билгеләнгән кебек, тирә юнегездәге кешеләрнең тормышларында да бик күп охшашлыклар бар. Бу охшаш

сценариялар буенча яшәвегез өчен эшләвегез, нәселегезне дәвам итү өчен гаилә корувгыз кирәк. Бу фикер итү буенча, “яхшы бер гаилә һәм яхшы бер эштән” тыш, яшәүнең тагын нинди башка максаты булырга мөмкин! Боларны булдырганнан соң, бәхетле бер тормыш турында хыялланырсыз. Шулай итеп һәрнәрсәгез шәмәхә төскә керәчәк һәм калган гомерегезне тыныч иттереп кичерәчәксез.

Әмма, сез болар турында уйлаган вакытта гәүдәгездә һәм тирә юнегездә мөһим үзгәрешләр бара. Гәүдәгездәге төрле функцияләргә ия булган күп кенә клеткалар вазыйфаларын тәмамлап үлә бирә һәм яшегез арткан саен аларның яңарувы тагын да әкренәя бара. Гәүдәгез картая һәм моны күрсәтүче билгеләр, авырулар, җитешсезлекләр күренә башлый. Вакыт үтә бирә һәм кирегә кайту мөмкинчелеге буимаган көн бара-бара үзен тагын да ачык буларак күрсәтә. Һәм сез тыныч һәм рәхәт кичерегә исәпләгән “калган тормышыгыз” аркылы да, ул дәвам иткән саен, үлемгә таба якынаюгызны аңлыйсыз һәм бу яшәешнең бер соңы барлыгына төшенәсез.

Бу яшәешнең бер соңы бар ки, бу соң артыннан асыл хакыйкатьләр белән кара-каршы киленәчәк. Шулай булгач, Дөнья тормышында максат ителгән һичбер нәрсәдә сезнең чын максатыгыз булмаска тиеш. Чөнки Дөнья тормышы барытик фани бер имтихан урыны гына. Кемнең изге гамәлләр кылачагын сынау урыны. Аллаһ безгә бу мөһим хакыйкатьне шулай белдерә:

***Ул гамәл (эш, хәрәкәт) ягыннан кайсыгызның тагын да яхшырак (гүзәлрәк) булачагын сынар өчен үлем һәм тормышны яратты. Ул өстен һәм көчле күп ярлыкаучы. (Мөлек сүрәсе, 2)***

Яшәешнең хакыйкый максаты “яхшы гаилә һәм яхшы бер эш” түгел. Һәркемнең барытик бер генә яратылу максаты бар – Аллаһка кол булу. Дөньяда кулга кергән мал, ир яки хатын, бала-чага, дәрәҗә, ихтирам ителү – барысы да яшәеш барышында кешеләрне үзләренә көчле итеп бәйләгән нәрсәләрдән. Әмма, үлемнең беренче мизгеле белән бу Дөньяви нәрсәләр, бер мизгелдә бөтен кыйммәтлекләрен һәм әһәмиятлекләрен югалталар. Бу һәркем тарафыннан беленгән, ләкин аның турында

уйланудан качылган бер хакыйкать. Шуның өчен, асыл максат бу булмаска тиеш. Ул вакытта хакыйкый максат һәм казану ни икәнлеге турында бик яхшы уйланырга, төшенергә кирәк. Яратылуның асыл максатын Аллаһ Көръәндә болай белдерә:

***Мин җеннәрне һәм кешеләрне барытик Миңа гыйбадәт итсеннәр өчен генә яраттым. (Зарият сурәсе, 56)***

Бары Аллаһка коллык вазыйфасының тулаем җиренә җиткерелмәсе белән генә, үлемнән соң башланган Ахирәт тормышы өчен гүзел бер өмет өчендә булырга мөмкин. Кешеләрнең бөек бер өлешендә яңлыш бер өмет бар. Кешеләрнең күпчелеге бу ихтималга инанып үзен рәхәтләтергә тырыша. Югыйсә, бу бөек бер хаталану. Әгәрдә берәр кешенең Ахирәткә, үлемнән соң булган тормышка карата бер өмете дә юк икән, ул вакыт бер генә ихтимал кала: үлем белән берлектә юк булу! Бу ихтимал исә, башкаларына карата бик күпкә куркынычрак. Аллаһка коллык итүне инкяр иткән кешеләр бу мөмкинчелектән курыкканнары һәм онытырга теләгәннәре өчен, үзләренә төрле-төрле ысуллар китереп чыгарырлар. Бу ысуллар исә, гел бер төрле: үлем турында сөйләшелмәс, бәхәсләшелмәс, хәтерләтелмәс. Үлемнең яшәләчәге ачык булган хәлдә, “юк” кебек кабул итәлер. Җәмгыятьнең бөек бер өлеше тарфыннан моның кабул ителүве дә, кешедә бер рәхәтләнүгә сәбәпче була ала. Бит, аның кебек башка кешеләр дә алдана. Кешеләр үлемне, Кыямәт Көнен һәм Ахирәтне белерләр, ләкин уйланмаслар. Дөнья тормышы белән хушланырлар. Дөресрәге, хуш булырга теләрләр. Бит, Аллаһ Көръәндә кешеләрнең алар качкан үлем хакыйкате белән ачык буларак каршыланачакларын белдерә. Аятьтә шулай боерыла:

***Әйт ки: “Әлбәттә, сез үзеннән качкан үлем, шиксез, сезнең белән каршылашачак. Соңында беленмәгәнне дә, шаһит була алынганнны да белүчегә (Аллаһка) кайтарылачаксыз. Ул да сезнең кылганнарыгыздан хәбәр бирәчәк”. (Җомга сүрәсе, 8).***

Үлем бары тик кешеләр өчен генә максус тугел. Фани булган Дөнья тормышында кеше кебек “һәрнәрсәнең” дә үлеме бар. Аллаһ безгә, эчендәге бөтен җанлылар белән берлектә, галәмнең юк ителәчәге бер

көннең барлыгын, ягъни “Кыямәт Көнен” белдергән. Кыямәт Көне имтихан беткән көн, соңгы көн. Ул көннең килүвен җир йөзендәге һәркеше бик күп билгеләре буенча аңлаячак, галәмнең үлеме белән тәмамланачак вакыйгалар бик кот алучан булачак. Һәм ниһаять, Дөньядагы бөтен кешеләр Кыямәт булган көнне, үзләрен көткән “яңадан терелүне” аңлаячаклар. Мондый бер көн белән каршылашуларына инанамаганнар, каршыларындагы бик ачык булган бу хакыйкатьне инкяр итә алмыйча, Аллаһның әмеренә “теләсәләр дә, теләмәсәләр дә” буйсыначаклар. Аллаһ бөтен галәм өчен бөек бер соң хәзерләгән. Кешеләрнең күпчелеге ни кадәр инкяр итәргә тырышсалар да, Кыямәт Сәгате билгеләнгән бер вакытта үзләрен көтә бирә.

## КЫЯМӘТ КӨНЕ ШИКСЕЗ БЕР ХАКЫЙКАТЬ

Элегрәк сүз иткәнебез кебек, Дөньяның фани кыйммәтлекләренә хуҗа булуларын үзләре өчен җитәрле дип белгән кешеләр, хакыйкатьләрдән төрле ысуллар аркылы качарлар. Үлем, бөтен хаклыгы белән каршыларында булган хәлдә, моны исәпкә алмыйча, яңадан тереләчәкләре көнне дә онытырга тырышырлар. Болар турында уйланмау үзләренчә бер качу алымы. Шулай итеп, кешеләр Аллаһ каршындагы вазыйфаларын акылларына китермичә, барытик үзләрен кызыксындырганнарга гына бирелеп яшәүләрен зан итәрләр. Бит, Кыямәт Көне шиксез бер хакыйкать. Бу хакыйкать Көръәндә белдерелгән.

Шулай ук, Көръәндә Кыямәт Кәнендә булачак вакыйгалар да тасвирланган. Бөтен нечкәлекләре белән аңлатылган. Кыямәт вакытында җир йөзендә һәм бөтен галәмдә булачаклар, моның белән беррәттән кешеләрнең рухи хәле, бөтен минлекләренә хаким булачак бөек шашкынлык, курку һәм паника ачык буларак аңлатылган. Шиксез, галәм кимчелексез буларак юктан бар ителгән кебек, шулай ук кимчелексез һәм могҗизалы, искиткеч рәвештә бетәчәк. Планеталар орбиталарын таба алмаячак, таулар урыннарыннан кузгалачак. Элегрәк, һәрнәрсәнең үзеннән-үзе барлыкка килгәнлеген сәбәп итеп, Аллаһны инкяр иткәннәр,

бөтен аһәңлелекләрне (гармонияне) юк иткән бу бөек вакыйгалар каршысында, үзеннән-үзе булдырылувын түгел, ә боларның барытик Аллаһның әмере белән генә булдырылувын аңлаячак. Кыямәт вакытында булачак вакыйгалар турында Көрьәндә Аллаһ шулай хәбәр итә:

***Әйт ки: "Күкләрдә һәм җирдә булганнар кемнеке ?". Әйт ки: "Аллаһныкы". Ул мәрхәмәтлекне Үзенә язды. Сезне шиксез булган Кыямәт Көнендә,әлбәттә, туплаячак. Үзләрен хәсрәткә атучылар, алар ки, инанмаучылар. (Әнъам сүрәсе, 12).***

***Сурга (боргыга) тик бер өрү белән өрелгән вакыт, җир йөзе һәм таулар урыннарыннан кузгатылып күтәрелгән вакыт, аннан соң тик бер бәрелеш белән бер-берсенә бәрелеп, өлеш-өлеш булачак вакыт. Менә бу көнне вакиа (бер хакыйкать булган Кыямәт) булачак. (Хакка сүрәсе, 13-15)***

## КЫЯМӘТ КӨНЕ БИЛГЕЛӘНГӘН БЕР ВАКЫТ

Заман үткән саен, Кыямәт булачак заманга таба тизлек белән якынлашабыз. Кешеләрнең күбчелеге Кыямәтне үзләреннән күпкә соң киләчәк нәселләр тарафыннан каршыланачак бер вакыйга буларак исәпли. Шиксез, бездән алдарак булган нәселләр дә шундый ук фикер белән хәрәкәт иткәннәр һәм "ерак киләчәктәге" бу вакыйга турында уйланмаганнар да. Бит, җир йөзендәге беренче кешенең яратылувыннан алып яшәгән һәркеше, Кыямәт Көне булачак вакыйгаларга шаһит булачак . Өстәвенә, бу көннең сез көнлек тормышыгызны дәвам иткәнегездә, киләчәк өчен планнар корганыгызда була алмавы өченбер гарантиягез дә юк. Шиксез булачак Кыямәт вакытын барытик Аллаһ белә. Моның белән бәйле буларак аятьләрдә шулай боерыла:

***Әйт ки: "Белмим, сезгә вәгьдә ителгән (Кыямәт һәм газап) якынмы яки Раббым аның өчен озын бер вакытмы билгеләде?" Ул беленмәгәнне белүчедер. Беленмәгәнне (күрелмәгән белем хәзинәсен) беркемгә дә ачык кылмас (аңа белдермәс). (Җен сүрәсе, 25-26)***

Бөек бер тәртип белән яраткан яшәешне Аллаһ белмәгәнебез бер вакытта, бөтен тәртибе белән берлектә соңына китерәчәк. Кешеләрнең күбчелеге тарафыннан моңардан шикләнүне яки бу нәрсәгә карата нәрсәдер планлауны акылсызлылык кабул итүләре, шул сәбәптән инкяр итүне сайлаулары таралган күренешләрдән. Ләкин, тасвирланган бу соңгы көн инкярчылар өчен бик авыр, өркетүче (куркыныч) бер көн булачак.  Шуның өчен, ышанмыйча булачакларны көтү урынына, барлыгыннан шикләнмичә Кыямәт Көненә иман итү кешенең үзе өчен файдалырак һәм казану китергәннәрдән булачак. Чөнки, Дөньядагы тырышлыгының  “буш бер тырышлык” икәнлеген Кыямәт Сәгате белән аңлаган бер кешенең үкенүвен тасвирлау бик авыр. Бик көчле үкенү бу. Бер аятьтә Аллаһ шулай боера:

***Кайчан ул - һәрнәрсене батырып килүче бөек һәлакәт (Кыямәт) килгән вакытта. Ул көнне кеше ни өчен тырышлык куйганлыгын төшенер, аңлар”. (Назият сүрәсе, 34-35).***

# КЫЯМӘТ КӨНЕ БУЛАЧАК ВАКЫЙГАЛАР

Көръәндә хәбәр бирелүвенә күрә Кыямәт Көне ул: “кешеләрнең, галәмнәрнең Раббысы өчен калыкканы көндер” (Мутаффифин сүрәсе, 6). Ул көн, җанлылар белән бергә бөтен галәмнең юк булачагы дәһшәтле бер көн. Бу юк булу хәзерегә хәтле һичбер җирдә күрелмәгән вакыйгалар соңында булачак. Ул көн – кешеләрнең, хайваннарның, бар булган һәрнәрсәнең, кыскачы бөтен галәмнең үлем көне. Ул көн – Аллаһның Бөек кодрәте ачык буларак күрелгән һәм кешеләрнең барчасы тарафыннан беленгән көн. У көн – инкярчылар өчен дәһшәт, курку һәм иза китерәчәк бер көн. Ул көн – элек һич яшәлмәгән берүкенечнең, курку һәм хурлыкның хис ителәчәге көн.

Кыямәт Көне Көръән аятьләрендә, төрле чагыштырмалар аркылы, үзенчәлекләре белән аңлатылган. Бу булемдә, Көръәндә Кыямәт Конне булачагы белдерелгән вакыйгалар гомуми буларак тасвирланып, Аллаһ аятьләре белдергән вакыйгаларның нинди мәгънәләргә ишарәт иткәнлекләре күрсәтеләчәк. Әлбәттә, һәрнәрсәнең иң дөресен Аллаһ белә һәм Аллаһның гыйльме соңсыз. Без исә, һәрвакыттагыча, Кыямәтне дә барытик Ул безгә белдергән һәм өйрәткән кадәр генә аңлата алабыз.

Бу бүлемдә аңлатылган вакыйгалар Көръән аятьләреннән алынды һәм һәммәсенең дә булачагы шиксез. Бөтен тасвирлауларның булу рәвешен дә Аллаһ билгеләгәндер. Фәкать, бу вакыйгаларның ихтимал ителгәннән тагын да аермалы буларак тормышка ашувы мөмкин. Безнең

ачык буларак белгәнебез – Аллаһ вәгъдә иткән вакыйгаларның шиксез яшәләчәге, кешеләрнең  Кыямәт Көнендә элегрәк һич күрелмәгән, бөек бер манзара белән кара-каршы калачаклары һәм галәмнең эчендәге бөтен җанлылар белән бергә бөтенләй юк булачагы. Кешеләрнең исә, бөтен булганнарның сәбәбен өйрәнү, бу һәлакәтләрдән качып котылу яки чара эзләү кебек бер ихтималлары булмаячагы. Ул көнне һәркемнең күрәчәге хакыйкать: Аллаһның һәм Ахирәтнең барлыгы.

# СУРГА ӨРҮ

### Кыямәт Сурга өрү белән башланыр

***Сурга өрелгәндер инде. Инде бу алдан әйтелгәннең (тормышка ашачагы) көндер. (Каф сүрәсе,20).***

Сурга өрү - Аллаһ Көръәндә вәгъдә иткән Кыямәт Сәгатенең инде килеп җиткәненең хәбәре. Бу тавыш Дөнья тормышының бетүвен һәм Ахирәтнең башланганын белдергән тавыш. Дөньяда булганында бу бөек көндә ни күрәчәге  турында хәбәр ителгән һәм бирәчәк хисаб белән уярылып куркытылган һәркем инде узенә вәгъдә ителгән хакыйкатъ белән кара-каршы. Һич көтелмәгән бер мизгелдә ишетелгән бу тавыш, элгрәк ишетелгән тавышлар белән һич тә охшаш түгел. Кешеләр үзләренә бирелгән заманның беткәнлеген бу ишарәттән аңлаячак. Бу тавыш көферлеккә бирелгәннәрнең мәңгелектә дәвамлы буларак яшәячәкләре курку, дәһшәт һәм арыганлыкның, авыр бер көннең башланувын күрсәтүче хәбәрче. Аллаһ аятьләрендә шулай боера:

***Чөнки ул боргыга (Сурга) өрелгән вакыт. Инде ул көн, авыр бер көн, кяферләр өчен исә һич җиңел түгел. (Мүдәссир сүрәсе, 8-10)***

Дөньядагы системаның үзенә тартучан гүзәллекләренә алданып, аңа каты итеп бәйләнгәннәр, Аллаһның барлыгы һәм берлеге хакыйкатенә каршы сукыр. Бөтен боларның Яратучысын, яратылувын һәм бетувене

таба тизлек белән барылганнын һич уйламыйча, барытик аларны алдаган бер манзара белән сүздә бәхетле булып, шуның белән җитенерләр. Югыйсә, аларны алдаткан бу камил система – һәрнәрсәнең хуҗасы булган Аллаһның әсәре. Аллаһ яраткан бу күркәм система, Аның тик бер әмере белән акылларга сыймас дәрәҗәдә бетәчәк. Менә мондый бер көн белән шиксез буларак каршылашмаячакларын исәпләгәннәр, Сурның тавышы белән бу гафләттән бер мигелдә уяначак. Ләкин, бу уяну инде файдасыз. Чөнки Аллаһ һәм Ахирәт өчен нәрсәдер эшләү өчен бик соң.

Соң инде, чөнки кайбер кешеләр бер имтихан булган бу Дөнья тормышын, Ахирәтнең барлыгын саңга сучакрымыйча, буш бер тырышлык белән үткәрде. Ахирәткә инанмаган кешеләрнең мондый бер фикердә булуларының бер сәбәбе –бик шәхси бер тырышлык. Бу тырышлыкның асылы һәм җәзасы бик бөек. Асылындагы бер сәбәп, Дөньядагы бу чикләнгән тормыш бәлән җитенеп, киләчәк яки үткәннәр турында мөмкин булганча уйланмау. Бу аңлаеш кешеләренең күбчелеге нигә яшәгәннәрен, ни өчен яратылганнарын, Яратучының аларданниләр теләгәнен һәм нигә үлемнең бар булганлыгын уйламыйча гомер кичерерләр. Үлем алар тарафыннан беленгән нәрсәдер, әмма, үлем хакыйкатенең үзләренә уйланулары кирәк булган моның ише сорауларны да тудырачагын белерләр.  Шуның өчен, мөмкин булганча бу фикердән ераклашырга тырышырлар.  Югыйсә, кеше яратылышының һәм Дөньядагы кыска тормышның барытик бердән бер сәбәбе – тик Аллаһка гына коллык итү. Үлемнең якынлыгын, Дөнья тормышының кыскалыгын, ия булган яки булмаган һәрнәрсәнең нибары имтиханның бер өлеше булганлыгын белгән кешеләр, Көрьән  аркылы кешеләргә танытылган хакыйкатләр белән дә шиксез кара-каршы киләчәкләрен белер. Шулай итеп, Дөньядагы бердәнбер максатның “Аллаһ өчен яшәү” икәнлеген төшенер. Моңа Дөньяда булган чакта ук төшенү – кеше өчен бөек бер казану. Шулай итеп, алдатучы Дөньядан ераклашып, бердәнбер хакыйкатькә, ягъни Ахирәткә юнәләчәк. Нәфсенә, ягъни барытик ләззәтләренә, шәһвәтенә ияреп хәрәкәт иткән бер кешенең иң бөек теләге шул ки: эчендә булган системаның гел дәвам итүве, һич тә бетмәве.

Асылында, хәленнән дә бик риза түгел, чөнки тормышында дәвамлы авырлыклар һәм күңелсезлекләр бар. Ләкин, шайтан мең төрле ысул белән игътибарын алып аны алдата. Күңелсезлекләр һәм хәсрәт чиктергән бу тормышны, мәңгелек бер газап буласын инкяр итеп сайлый бирә кеше. Бит, бер иртәдә эшкә барганда яки бер кичәдә ниндидер планнарын һәм өметләрен киләчәк көннең иртәсенә калдырып йокларга хәзерләнгән вакытында, көтмәгәндә "Сурның" тавышын ишеткән бер кеше шиксез чарасыз калачак. Дәвам итәргә теләгән Дөнья тормышының, үзе белән бергә, соңгы минутлары килеп, белгән хәлдә инанмаган бу бөек хакыйкать көтмәгәндә тотып алган үзен. Гомере буе аны саклаячагын санап, ялган көчләргә сыенган бер кеше өчен ул мизгелдә ярдәм сорый алачак кемсә, яки сыена алачак һичбер урын да юк инде. Чөнки, мөэминнәрдән башка һәркем шундый ук хәлдә,чарасыз буларак башларына киләчәкләренә тәслим булганнар, җир йөзендә шул вакыткача яшәгән бөтен кешеләр Аллаһ билгеләгән урынга тупланганнар:

***Сурга өрелгәндер: шулай итеп алар каберләреннән (терелтелеп) Раббыларына таба (өлеш-өлеш) аерыла-аерыла килер. (Ясин сүрәсе,51)***

Сурның тавышы берәр инкярчы өчен "гомере буенча качкан хакыйкатьләр белән кршылашу" булган кебек, "инде кылганнарның төзәтү мөмкинчелеге һич була алмыячагын да" аңлата. Ул вакыттагы куркуны тасвирлау мөмкин түгел. Элегрәк "ни күрелгән, ни ишетелгән" бер дәһшәт һәм паника яшәлә. Дөньяда кылынган барлык хаталарның төзәтелуве мөмкин, яки вакыт үтү белән бу хаталар онытыла ала. Ләкин, һәрнәрсәнең соңы килгәнен белдергән бу тавыш, кылынган хаталарның төзәтелүве өчен вакыт калмаганлыгын хәбәрчесе инде. Ул көндәге Сурның тавышы инкярчыларга бөек бер курку китерәчәк һәм һәркеше каршындагы бу хакыйкать алдында башын иячәк, беркем дә бу хакыйкаттән кача алмаячак, Аллаһ бу хәл турында Көръәндә шулай хәбәр бирә:

***Сура өреләчәк көнне, Аллаһ теләгәннәрдән башка, күкләрдә***

***һәм җирдә булган һәркем инде куркуга бирелән һәм һәрберсе "башын иеп" Аңа килгән. (Нәшл сүрәсе, 87)***

Югыйсә, кешеләрнең барчасына да, киләчәк шушы Көннән элек, бу хакыйкать хәтерләтелгән иде. Аллаһ кешеләрне аятьләре белән дә, илчеләре белән дә "кире кайтарылу мөмкинлеге булмаган бер көн" килгәнче, Аңа (Аллаһка) юнәлергә кирәклеге турында уярган, киресенчә хәрәкәт кылганнар өчен исә, үлем килгәннән соң ярдәм ителмиячәген белдергән. Коръәндә көтелмәгән бер мизгелдә газап белән каршылашкан кешенең хис итәчәге үкенеч һәм үзенә һичничек тә ярдәм итәлмиячәге хакыйкате шулай ачыклана:

***Газап сезгә килеп җиткәнче Раббыгызга юнәлегез һәм Аңа тәслим булыгыз. Соңыннан сезгә ярдәм ителмәс. Раббыгыздан сезгә иңдерелгәннең иң гүзәленә иярегез. Сез һич көтмәгәндә, газап бермәлдә сезгә килеп җиткәнче. Кешенең (үкенечтән янып) шулай диячәге көн: "Аллаһка каршы кылган хаталарым өчен кайгы-хәсрәт миңа! Чынлыкта мин Аллаһның диненнән көлүчеләрдән идем". Яки: "Чынлыкта Аллаһ мине тугъры юлга күндерсә иде", - диячәге, яки дә газапны күргән вакытта: "Минем өчен тагын бер тапкыр (Дөньяга кайту форсаты) булса иде, яхшылык кылучылардан булса идем", – дип әйтәчәге көннән сакланыгыз. "Юк, Минем аятьләрем сиңа килгән иде, ләкин, син аларны ялганладың, тәккәберләндең һәм кяферләрдән булдың". Кыямәт Көнне Аллаһка каршы ялган сөйләгәннәрнең йөзләренең кап-кара булганлыгын күрәчәксең. Тәккәберләнгәннәр өчен Җәһәннәмдә калыначак берәр урын юк мы әллә? (Зүмәр сүрәсе, 54-60)***

Үтүчән, фани бер файда өчен хуп күрелгән бу Дөнья тормышы Сурның тавышы белән тәмамланды. Бөтен кешеләр үзләренә вәгъдә ителгәннәр белән кара-каршы. Булып беткән вакыйгаларның чынлыгы кешеләрдә бик бөек курку һәм дәһшәт уяндырган. Бөтен кеше берүк чакыруга ияреп, кире кайтарылу булмау хакыйкате белән каршылашканын аңлаган инде. Шиксез, бу бер бөек көн һәм бу бөек көнне булачак вакыйгалар өчен Сурның тавышы барытик бер хәбәрче генә.

# КЫЯМӘТ ВАКЫТЫНДА ҖИР ЙӨЗЕНЕҢ ХӘЛЕ

## Көчле тетрәүләр башлар

***Җир шул көчле тетрәнү белән тетрәгән, җир авырлыкларын тышка атып чыгарган һәм кеше: “Аңа ни була ?”- дигән вакыт. Ул көнне (җир) хәбәрләрен аңлатачак. Чөнки синең Раббың аңа ильһам иткән. (Зилзилә сүрәсе, 1-5)***

Кыямәт Көнендә һәр җанлы ишетә алырлык Сур тавышыннан соң колакларны шартлатучы бер тавыш булыр һәм җир йөзе моннан элек һич күрелмәгән тетрәүгә дучар ителер. Дәү таулар, агачлар, зур биналар, кыскасы, җир йөзенең һәр ноктасы берүк вакыт та тетри башлар. Моннан элек һич күрелмәгән бу тетрәү каршысында кешеләр бөек бер паникага һәм куркуга бирелер. Иң куркыныч булганы исә, бу тетрәүдән качу яки сыенып котылырлык һичбер урынның булмавы. Чөнки бу тетрәү, элек кешеләр таб булган һәм барытик билгеле бер район яки шәһәрдә булган, секундалар белән хисапланган тетрәүләргә бердә охшамаган. Бу тетрәү, аңардан һичбер качу юлын калдырмаган һәм берүк вакытта бөтен Дөньяда башланган һәм Дөньяны җир белән тигезләгән бер тетрәү. Дөньяы җир белән тигез кылганчы да бетмиячәк (иң дөресен Аллаһ белә). Кыямәт Көнне кешеләр таб булачак тетрәүләрне Аллаһ Көрьәндә шулай белдерә:

***Ул тетрәүнең булачагы көн. Артыннан аны башка тетрәү дәвамлаячак. Ул көнне йөрәкләр (дәһшәт эчендә) тибәчәк. Карашлар кимсетелгән булачак. (Назиат сүрәсе, 6-9).***

Җир йөзендә яшәлгән һәм нәтиҗәләре кешеләрдә тирән тәэсир калдырган җир тетрәүләрен күзаллагыз. Бу җир тетрәүләрнең бөтенесе дә барытик берничә секунд булган хәлдә, артларыннан бөек харабәләр кала. Йөз меңнәр белән хисапланган кешеләр харабәләр астында калып, калганнары исә һич көтелмәгән хәерчелеккә һәм юклыкка юлыга. Өйләр,

маллар, керемнәр, сарыф кылулар бик кыска бер вакыт эчендә җир белән бер була. Бу һәлакәтләр һәркемнең куз алдында булган һәм бу мизгелләр эчендә һичбер көч тетрәүне туктата алмаган. Кыямәт Көнне буласы тетрәү исә, ни көч, ни нәтиҗә, ни мәйдан ягыннан элегрәк Дөньяда яшәлгән тетрәүләргә охшамаячак һәм иң әһәмиятлесе, үзеңнән соң харабә түгел, бер тормыш билгесе дә калдырмаячак.

Дөньядагы җир тетрәүве ни кадәр көчле булса да, күп очракта кешеләр өчен котылу чаралары калдыра. Кешеләр моны белгәннәре өчен, җир тетрәве башлар-башламас үзләрен коткару максаты белән берәр төрле хәзерлекләр күрә, тиз рәвештә тетрәүдән иминлек эчендә булачак бер җирдә сакланырга тырыша. Югыйсә, кешеләрнең һәммәсе Сурга өрелү белән аңлаячаклар ки, бу тетрәүләр элек яшәлгәннәргә охшаш түгел: берничек тә качып котылу ихтималы юк.

Шиксез, кешеләр Кыямәт Сәгатендә булачак һәрнәрсәдән кисәтелгәннәре кебек, тормышка ашачак һәм качу мөмкинчелеге булмаячак бу тетрәүләрдән дә Көрьәндә шулай кисәтеләләр:

***Әй кешеләр, Раббыгыздан куркыгыз, чөнки Кыямәт Сәгатендәге тетрәү бөек бер нәрсә. (Хаҗ сүрәсе, 1).***

Бу вакытта җир йөзендәге һичбер нәрсәнең кыйммәте һәм мәгънәсе калмаган инде. Кешеләрне алдаткан һәрнәрсә: люкс өйләр, дәү биналар, биш йолдызлы отельлар, гомерләре буенча акча җыеп алынган һәм күп хезмәт кертеп төзелгән һәм җиһазландырылган өйләр, солтан-сарайлар күперләр, йөз еллар буенча табигатькә бирешмичә аякта кала алган пирамидалар, тарихи кальгалар, шәһәрләр, диңгез янында ясалган ком кальгалары кебек тизлек белән җимереләчәкләр. Өмет бирүче эш урыннары, люкс машиналар, кыскасы, Дөнья тормышында кеше ия булган, ия булганы белән мактанган бөтен матди байлыклар бер мизгелдә юк булачак. Кешеләр ия булган шан, шөһрәт, авторитет һәм хакимиятнең һичнинди мәгънәсе һәм әһәмияте калмаган инде.

Ул көндә җирнең өлеш-өлеш булып комга әйләнәчәген Көрьән шулай белдерә:

***Юк, җир өлеш-өлеш булып комга әйләнгәне, Раббың (ның боерыгы) килгән һәм фәрештәләр саф-саф торган вакыт. Ул көнне Җәһәннәм дә китерелгән. Кеше ул көнне уйланып хәтерләр, ләкин (бу) хәтерләүдән аңа ни файда? (Фәҗр сүрәсе,21-23).***

Ул көнне кешеләр тарафыннан моннан элек иминлек белән өстендә йөрелгән җир аяклары астыннан качачак. Төрле сәбәпләр аркылы Аллаһны инкяр итәргә тырышкан һәм үтәлергә кирәклеген белгән хәлдә, гыйбадәтен үтәүдән качкан һәркеше, соңында Аллаһтан башка сыена алырлык бер көч булмаганлыгын бик яхшы аңлаячак. Әмма, инде аның өчен ни кирегә кайтарылу, ни кылганнарын төзәтү мөмкинчелеге бар. Яшәлгән үкенеч тә кешегә бер файда да китермәячәк.

Ул көнне  кешеләр тарафыннан курку һәм дәһшәт белән берлектә татылган иң бөек хисләрнең берсе – чарасызлык.  Дөньяда була алган һәртөрле һәлакәт өчен хәзерләнгән, иң куркыныч афәт, иң бөек җир тетрәү, иң көчле ураган, иң дәһшәтле атом сугышы эчендә качыр, сыеныр урынын хәзерләгән адәм баласы, шундый бер вакыйга белән кара-каршы килер ки, качып сыеныйрлык, котылырлык тик бер имин урын да таба алмаячак. Дөньяда булганда ваз кичелмәс дип белгән “акыллылыгы” да, үзенә инкярны кабул иттергән акылы да, көчле икәнлекләренә ышанган кешеләр дә бу дәһшәтле тетрәүгә каршы һичбер чара таба алмаячаклар һәм үзе һәм алар өчен дә һичбер качу урыны да юк инде.

## ҖИР АВЫРЛЫКЛАРЫНЫН ТЫШКА АТЫП ЧЫГАРЫР

***...Җир авырлыкларын тышка атып чыгарган һәм кеше:”Аңа ни була ?”- дигән вакыт. Ул көнне (җир) хәбәрләрен аңлатачак. Чөнки синең Раббың аңа илһам иткән. (Зилзилә сүрәсе, 2-5).***

Беленгәнчә, Дөньяның мәркәзендә (җир кабыгыннан 5 000- 6 000 килом аста) бик югары басымга ия булган ялкынсу бер катлам бар. Һәм бу катламның температурасы якынча 4 500°С булганлыгы фаразлана.

Вулканнарның шартлаулары нәтиҗәсендә җир йөзенә чыккан лава бу бүлемдә, ягъни магмада урын ала. Сүз ителгән шартлаулар тарих буенча бик күп шәһәр халкына дәһшәт тулы мизгелләр яшәтеп, кешеләрнең үлеменә, кайвакыт хәтта шәһәрләрнең дә бөтенләй юк чыгувына сәбәп булган. Төрле сәбәпләр аркылы туфрак катламнарында барлыкка килгән чатнамалар нәтиҗәсендә җир йөзенә чыккан лавалар, басым ни кадәр көчле исә, шул хәтле көчлерәк атылырлар. Асылында бу газның микъдарына бәйле. Магма җир йөзенә чыкканда газлар сыекча кебек матдәдән аерылып магма өстенә таралыр һәм шулай итеп басымның артувына сәбәпче булыр. Магма газ белән ни кадәр йөкле исә, атылган вакытынтда шул кадәр шартлау була һәм җир астында кайнаган лавалар җир йөзенә чыгып җир  өстен "Җәһәннәмгә" әверә. Бу төрле шартлау – бары билгеле бер районны үз эченә алган локаль шартлау. Өстәвенә, заманыбызда ясалган эзләнуләр нәтиҗәсендә, купчелек вакытта мондый бер һәлакәттән алдан хәбәрле булып, куркыныч янаган районда төрле хәзерлекләр күрелә.

Көръән аятьләренең "җирнең авырлыкларын тышка атувын" аңлатувында , ул көнне "җир астында булган бик күп нәрсә белән берлектә җир төшендәге сыекча сыман кысымның бөтенлеге белән җир өстенә чыгачагына ишарәт ителә.

Бөтен җир йөзен биләп алган көчле тетрәүләр һәм бөтен катламнарының ярылувы, мондый бер нәрсәнең җиңеллек белән тормышка ашувы өчен нигез хасил итәчәк. Ягъни Кыямәт Көнендәге көчле тетрәүләр җирнең астын өскә китерәчәк, кешеләр өстләренә төшүче таулардан, дәү биналардан котылырга тырышкан вакытта, җирнең ачык урыннарыннан чәчрәүче лавалар һәрьякка таралачак, бу  да кешеләрнең үлеменнән берничек тә кача алмаганлыкларын тагын бер тапкыр аңлауларына  сәбәп булачак. Һәлакәтләрне һәлакәтләр алмаштырачак, берсеннән котылырга тырышкан, бер башкасы белән каршылачак. (Иң дөресен Аллаһ белә)

Җир йөзе Аллаһка буйсынган хәзер. Бу хәл Көръән аятьләрендә шулай белдерелә:

***Җир тигезләнгән, эчендә булганнарын тышка атып бушалган һәм яратылышы кирәктергәнчә Раббыңа баш игән вакыт. (Иншикак 3-5)***

Инде соңгы көн килгән. Кешеләргә бирелгән заман беткәнд һәм һәрнәрсә үзенең ахырын тапкан. Бу көннән котылучы һичбер җанлы юк. Бөтен вакыйгалар булып беткәннән соң, җир йөзендә тик бер орлык, тик бер үсемлек, бер микроорганизм, хәтта җир йөзенең үзе дә калмаячак.

Ул көнне җирнең тышка атылачак авырлыгы бары магма катламы гына түгел. Магма манта дип аталган тышкы кысымны да, манта белән җир кабыгы арасындагы температура һәм матдә мәркәзләрен дә ташлый. Ихтимал буенча, магма белән берлектә ташланган җир астындагы купчелек мәддә, югары температуралы булган килеш, җир йөзенә чыгачак. Бу да җир йөзенең элек күрелмәгән бер халәттә җылынувына сәбәп булачак. Булган вакыйгалар нәтиҗәсендә җир астындагы нефть, күмер кебек матдәләр белән берлектә башка файдалы казылмалар, сөякләр, гәүдәләр, кыскасы – җир асты өскә киләчәк. Аллаһ бу халәт турында Көрьәндә шулай хәбәр бирә:

***Һәм каберләрнең эче "тишелеп тышка атылган" вакыт. һәркем алдан хәзерләгәннәрен һәм калдырганнарын өйрәнгәндер. (Инфитар сүрәсе 4-5)***

Җир сулары да тетрәү көче белән ярылган җир катламнарыннан тышка атылачак. Басым белән атылган суның тәэсире бик көчле. Атылган урынга бик зур зыян китерәчәк һәм яшәешне яраксыз кылып, җир йөзенә таралачак.

Һәркайсы бер районда янартау (вулкан) шартлавы булган вакытта, сансыз тузан һәм каты кисәкләр атмосфераның өске катламнарына атылыр. Күпчелек вакытта, шартлау артыннан бөтен районның көл белән капланганлыгы, тузан томаны эчендә калганлыгы беленә.

Аллаһ аятьтә Кыямәт Көнендә "тауларның тузан томаны хәлендә таралачагын" (Вакиа сүрәсе, 6) белдергән. Көрьән аятьләре буенча,

Кыямәт Көне Дөньяның һәръягында моңа охшаш шартлау булувы бик тә ихтималлы.

Күренгәнчә, кешеләр һәръяклап көчле бер газапка юлыгачаклар. Һәръякны каплаган тузан болыты, берүк вакытта таралган газлар кешеләрнең сулыш ала алмауларына һәм газаплануларына сәбәп булачак. Ул көнне яшәлгән бөтен бу вакыйгалар инкярчыларның Җәһәннәм эчендә татачак мәңгелек газапның бөеклеген аңлаулары өчен җитәрле. Мондый дәһшәтле бер бетү белән кешеләр яшәешен тәмамлаган Аллаһ, Җәһәннәмдә инкярчылар өчен беленгән газапларга һичнинди охшашлыгы булмаган матди һәм рухи бер газап та хәзерләгән. Яшәлгән вакыйгаларның бөеклеге аркасында дәһшәтле бер үлем куркусы һәръякны биләп алган. Һәркемдә курку һәм үкенечтән башка һичнәрсә калмаган.

# ТАУЛАРНЫҢ ХӘЛЕ

## Таулар тамырлары белән алынып таралачак

Беленгәнчә, тауларның җир тетрәүләреннән саклый торган сыйфатлары бар. Бу хакыйкать Көръән аятьләрендә шулай хәбәр ителә:

***Сезне тетрәүләргә юлыктырмас өчен җирдә селкенмәгән таулар урнаштырды, елгалар һәм юллар да кылды. Бәлки сез тугры юлны табарсыз. (Нәхл сүрәсе, 15)***

***Без җир йөзен тигез урын кылмадычакрымы? Тауларны да берәр казык буларак? (Нәбә сүрәсе,6-7)***

Бүгенгә хәтле Дөньяда булган иң көчле җир тетрәвенең дәрәҗәсе 9.2 балл. Мондый дәрәҗәдәге бер җир тетрәве бик кыска бер вакыт эчендә булган районына бөек бер һәлакәт китерер. Кыямәт Көнне булачак тетрәү исә, Аллаһның теләге белән, Дөньяда ул көнгә хәтле булмаган, күрелмәгән көчле бер терәү. Бу тетрәү казык кебек җирләшеп җир йөзен көчле тетрәүләрдән саклаган тауларның да каршы тора алмаячак

кадәр көчле. Җир йөзендә исә, сау-сәламәт табигатькә ия булган, мәһәбәт һәм кузгатылмас дип беленгән таулар урыннарыннан кузгатылып, асларындагы туфрак белән бергә тая башлар. Ул көнне тауларның хәрәкәтләнүвен аңлатучы Көрьән аятьләре шулар:

***Һәм таулар урыннарыннан кузгатылып йөрер. (Тур сүрәсе,10)***

***Таулар йөретелгәндер, бер мираж булгандыр. (Нәбә сүрәсе,20)***

***Тауларны йөреткәнебез көнне җирне яп-ялангыч (тип-тигез хәлдә) күрерсең. Аларны бергә туплаганбыз да, араларыннан һичбере тышта калдырылмагандыр. (Кәхф сүрәсе, 47)***

Җир йөзенең бөек бер бүлемен таулар тәшкил итә һәм аларның берүк вакытта урыннарыннан куптарылып хәрәкәт итүләре, мондый зур-зур кисәкләрнең җир өстеннән шуыша-шуыша бер урында тупланулары һәм җирнең тип-тигез бер хәлгә килүве, әлбәттә кеше күрәчәк иң куркыныч манзараларның берсе булачак. Кешенең моны күзаллавы бик авыр.

Уйлап карагыз, кешеләр югары нокталарына авырлык белән менгән һәм урыннарыннан кузгалтмас дип белгән Гималай, Альп һәм Торус таулары бер мизгелдә тетри һәм урыннарыннан кузгала башлаячак. Югарылыклары меңнәрчә мда булган таулар һәм бу тауларның битәләрендә урнашкан шәһәрләр бер мизгелдә җир белән бер булачак.

Тауларда юллар ясар өчен бик зур технология мөмкинчелекләренә хас машиналар, җиһазлар кирәкле, хәтта кайвакыт алар да ярләм итә алмый. Юл ачу ниятеннән динамит белән тишелергә теләнгән таулардан ни бары өлешчә бер уңышка гына ирешелә. Динамит барытик бер өлешкә генә тәэсир итә, хәтта күпчелек вакыт аның һич бер тәэсире дә булмый. Хәтта, шул сәбәпле кайбер таулы районнарга ирешү бик авыр бирелә. Югыйсә, Кыямәт Көнендә җир йөзендәге бөтен таулар тузанга әверелер. Бу вакыйга ул көндә яшәлгәннәрнең дәһшәтен аңлау өчен бик тәэсирле бер урнәк. Дөньяда булган бөтен тауларның бермәлдә ком массасына

әверелүве, ул мәһабәт тауларның бер мизгелдә ишелүве бик дәһшәт бирүче бер манзара. Аеруча, Аллаһның сансыз көчен, кодрәтен аңлау өчен бик әһәмиятле. Таулар белән булачаклар шулай аңлатыла:

***(Шундый ) бер көн ки, җир йөзе һәм таулар тетрәр һәм таулар күченүчән бер ком җыелмасы булыр. (Мүзәллим сүрәсе,14)***

Тауларның өлеш-өлеш бүленеп ишелүвеннән соң җир йөзенең һичбер калкулыксыз, тип-тигез хәлдә булачагы турында Көрьәндә болай хәбәр ителә:

***Синнән таулар турында сорыйлар. әйт ки : " Минем Раббым аларны комга әйләндереп таратачак. Урыннарын буш, яп- ялангыч калдырачак. Анда ни бер кәкрелек, ни дә бер калкулык күрәчәксез." (Та-һа сүрәсе, 105-107)***

Безгә артыгыннан тигез булмыйча күрелгән Дөнья ул көнне бөтенләй тигезләнәчәк. Тип-тигез бер урында кешеләр бергә тупланачак. Аллаһ "Кәһф" сүрәсендә бу хакыйкатьне шулай белдерә:

***Тауларны йөреткәнебез көнне җирне яп-ялангыч (тип-тигез хәлдә) күрерсең. Аларны бергә туплаганбыз да, араларыннан һичбере тышта калдырылмагандыр. (Кәхф сүрәсе, 47)***

## ТАУЛАР ТӨРЛЕ ТӨСТӘГЕ ЙОН КИСӘКЛӘРЕ КЕБЕК ОЧАЧАКЛАР

Ул көнне таулар өстендәге үсемлекләре, чәчәкләре – бөтен яшеллекләре һәм эчләрендә сакланган төрле-төрле казылмалары, төрле төрдәге һәм төстәге туфраклары белән берлектә тирә юньгә атылачак. Тузан томаны булган таулар кисәк-кисәк бүленеп таралачак. Бу төсле манзара аятьләрдә төрле төстәге йон кисәкләренә охшатыла:

***Һәм тауларның “тирә якка таралган” төсле йон кебек булачаклары (көн). (Кариа сүрәсе, 5)***

***Таулар да (тирә якка очышкан) төрле төстәге йон кебек булачак. (Мәариҗ сүрәсе, 9)***

Җанлы – җансыз бөтен барлыклар өчен дә килгән Кыямәт Көненең һәр сәхнәсе бөек бер курку белән тулы. Иң җиңел тетрәүдән паникага бирелгән, берәр җир тетрәү ихтималы булган хәлдә , үлем куркусыннан сәгатьләрчә өенә керә алмагән кешеләр өчен күз алларына тауларның урыннарынан куптарылувы, җирнең эчендәгеләрен тышка атувы , каберләрнең тишелүве, кешеләрнең бергә тупланувы һәм һәлакәтләрне һәлакәтләр алмаштырувы чыдарлык нәрсәләрдән түгел. Инде ышана алачаклары “тик бер кеше”, сыена алачаклары “тик бер урын” да юк. Каршылашкан вакыйгаларның дәһшәте чыдый алырлык дәрәҗәне күптән ашкандыр. Һичбер чаралары юк. Инде җир йөзендә яңа берәр төрле башлангыч, барырлык бернинди урын юк. Яңа башланачак яшәеш Ахирәт – ул мәңгелек һәм Дөньяда Аллаһның ризасына омтылмаганнар өчен үкенеч һәм кайгы-хәсрәт тулы. Ләззәтләр, ашкынулар һәм фани Дөнья тормышы бетте. Каршылашканнары дәһшәт Аллаһның кодрәтен ачыклагандыр.

Югыйсә, боларның бөтенесе Аллаһның илчеләре һәм инанганнар тарафыннан үзләренә элегрәк ирештерелгән иде. Ләкин бу каһәрләүче Көн үзләренә ерак тоелып, үзләре кебек фани нәрсәләргә ышанган иделәр. Аллаһ Көрьәндә инкяр итүчеләрнең алдан ук кисәтелгәнлекләрен шулай белдерә:

***Газапның үзләренә киләчәге көн белән кешеләрне кисәт, куркыт. (Ул көнне) золым кылганнар шулай диячәкләр. “Безгә якын бер заманга хәтле вакыт бир ки, синең чакырувыңа җавап биргәннәрдән булыйк һәм илчеләреңә иярик”. Югыйсә, элегрәк үзегез өчен һич ???  юктыр дип ант итүчеләр сез идегез түгелме? Сез үзләренә золым иткәннәрнең җирләшкән урыннарында яшәдегез. Аларга ни кылганыбыз сезгә ачыкланган иде һәм сезгә үрнәкләр биргән идек.(Ибраһим сүрәсе, 44-45)***

Хәзер яп- ялгыз килеш куркынычлык белән кара-каршы калганнардыр. Һәркем үз җаны турында уйлана, һич бер дус башка бер якын дусны курмәс хәлгә килгән. Инде бер кем өчен дә качу юк. Инде Аллаһның вәгъдәсе үтәлгән. Ул көнне өйдән качуның да бер мәгънәсе юк. Тетрәү бары тик өйләргә генә тәэсир итми ки, тышка чыгу кешенең якынлашкан афәттән коткарсын! Ул көнне бар булган һәрнәрсә юк була, җир йөзе белән таулар урыннарыннан кузгатылып күтәрелә. Ни сыена алачак бер урын, чыдый алырлык бер көч, ни дә алдан күреләчәк бер чара бар. Көрьәндә җир йөзе белән тауларның кисәк-кисәк булачак Кыямәт Көне шулай аңлатыла:

***Җир йөзе һәм таулар урыннрыннан кузгатылып күтәрелгән вакыт. Аннан соң тик бер бәрелеш белән бер-берсенә бәрелеп өлеш-өлеш булачаклары вакыт. Менә бу көнне “вакиа”(бер хакыйкать булган Кыямәт) булачак. (Хакка сүрәсе, 14-15)***

## ДИҢГЕЗЛӘРНЕҢ ХӘЛЕ

Бөтен бу тасвирлауларны ясаганда мөһим бер нәрсәне хәтергә китерү урынлы булачак. Элегрәк тә белдергәнебезчә , зиһеннәребездә җанландырырга тырышкан бу манзараларның бөтенесе Көрьән аятьләрендәге тасвирлаулардан алынды. Болар Аллаһ теләге белән тормышка ашачак һәм Аллаһ вәгъдә иткән хакыйкатьләрдән. Бар булган һәрнәрсәне яраткан Аллаһ, шиксез, боларның һәрбересен юк кылырга яки җир белән бер итәргә дә кодрәтле. Аятьләр безгә хабәр иткәнчә, Кыямәт Көнне һәрнәрсә акылга сыймаслык дәрәҗәдә булган бер сәхнәләндерү белән юк булачак.

Бу Аллаһның китабында шулай белдерелә:

***(Бу) Аллаһның вәгъдәседер. Аллаһ вәгъдәдән ваз кичмәс. Ләкин кешеләрнең купчелеге белмәсләр. (Рум сүрәсе, 6)***

Үзенең бөеклеге белән тәкәберләнгән кешенең һичбер кыйммәте калмагандыр инде. Үзен Аллаһ каршында сыйфатлы һәм көчле дип

санаган, алданып Аллаһны инкяр итүдән ваз кичмәгән кеше, булып беткәннәр каршысында бик тә көчсез һәм гаҗиз хәлдәдер. Кеше үзен алардан өстен дип санаган барлыклар да, Аллаһ билгеләгән бу бөек көнгә тәслим булганнар. Таулар, диңгезләр һәм бөтен галәм, үзләренең элегрәк булган сыйфатларын югалтып, барытик Аллаһка итагать иткәннәр, Аллаһның бер “бул” диюве белән һәрнәрсә булып беткән. Һәрбересе Ул биргән хөкемгә баш иеп, җиренә китерелмәсе вазыйфаларын тәмамлаган. Тауларның төрле төстәге йон кисәкләре кебек очышулары, җирнең бөтен авырлыкларын тышка атувы, Кыямәт Көнне дингезләрдә булачак вакыйгалар да тагын бер тапкыр Аллаһның соңсыз-чиксез кодрәтен белдерә. Көръәндә белдерелгәнчә , ул көнне диңгезләр яначак һәм атылып ташачак.

**<u>Диңгезләрнең януы</u>**

Дөньяның дүрттән өч өлешен каплаган иң бөек су җыелмаларыннан саналган диңгезләрнең бер мизгелдә кайный башлауларын кешенең күз алдына китерүве чыннан да авыр. Кешенең ул вакыттагы дәһшәтне аңлый алырлык бер тәҗрибәсе юк. Ләкин, чикләнгән хыялын кулланып өлешчә зиһенендә җанландыра ала. Бүгенгә хәтле барытик вулкан шартлавына, сыек ягулык ташыган бер танкерда янгын чыгувына шаһит булып, боларны телевизорларда , фотоларда күргәндер. Әмма, аятьләрдә безгә китерелгән тасвирлаулар бу үрнәкләр белән каршылаштыра алмаслык дәрәҗәдә маштаблы. Ләкин, Аллаһның чиксез бөеклеген, көчен, кодрәтен белүвебез, безнең яшәләчәк һәлакәтләрнең ни дәрәҗәдә булачагы турында фикер иясе итәр. Аллаһ галәмдә бар кылган һәм саклаган бу системаны теләгәнчә үзгәртергә һәм һәрнәрсәне бер план белән астын өскә китерергә кодрәтледер.

Ул көнне җирнең бөтен авырлыкларын тышка атувы: җир астындагы якынча 4.500*С градуслы катламның мөмкин булган һәр урыннан ташувын аңлата. Моның эченә диңгез астында булганнар да керә. Берәр гыйльми тапшыруда лаваларның диңгез суларында барлыкка аитергән акылга дәһшәт бирүче манзараларга шаһит булганнардыр кешеләр. Югыйсә , Кыямәт Көнендә тормышка ашачак манзара бу

манзарадан бик күпкә аермалы, тагын да масштаблырак һәм дәһшәт бирүчерәк булачак. Җир йөзендәге бөтен диңгезләр ялкын эчендә калачак, каршына чыга алмаслык ут һәм ялкын кешеләргә таба юнәләчәк.

Ул көнне бөтен диңгезләр дә яначак. Тема белән бәйле аятьтә Аллаһ шулай боера:

***Диңгезләр яндырылган вакыт. (Тәквир сүрәсе, 6)***

Яшәлгән вакыйгалар нәтиҗәсендә җирдә булганы кебек, диңгездә дә тормыш бетәчәк. Нормаль шартларда эсселектән саклаган һәм рәхәтлек хисе биргән диңгезләр бер мизгелдә тирә якка бөек дәрәҗәдә эсселек таратачак. Диңгезләрнең дәү дулкыннарын ялкын болытлары алыштырачак, һавадагы төтен кислородны бөек дәрәҗәдә әзәйтәчәк. Иге-чиге булмаган диңгезләрнең ялкынланган һәм көчле буларак янган булувы, Дөньяның зур бер өлешенә таралып бик күп һәлакәтләрне дә үзе белән китерәчәк.

<u>**Диңгезләрнең ташувы**</u>

Кыямәт Көне алдыннан тормышка ашачагы белдерелгән вакыйгаларның берсе дә – диңгезләрнең ташувы. Бу хакыйкать безгә аятьләрдә шулай итеп хәбәр ителә:

**“Диңгезләр чәчрәтелеп таштырылган вакыт”. (Инфитар сүрәсе, 3)**

Ул көнне, Аллаһның теләге белән, җирдә булган һәлакәтләргә диңгездә булганнары да кушылачак. Боларның тормышка ашулары өчен барытик Аллаһның теләге генә җитүве шиксез. Аллаһ нибары “бул” әмере белән юктан бар кылган җир йөзен, төрлечә иттереп җир белән тигезләргә кодрәтле. Боларның тормышка ашуларында мөмкинчелек була алган ихтималлы сәбәпләр исә, безнең өчен бер хәтерләтү, Аллаһка якынлашувыбыз һәм Аның газабыннан куркувыбыз өчен бер юлдыр. Бу вакыйгаларның ничек тормышка ашачагын , сәбәпләренең ни булачагын бары тик Аллаһ кына белә. Бәлки һичбер сәбәпсез, бер мизгелдә Кыямәтнең бөтен билгеләре тормышка аша башлаячак. Шуның өчен, бу

бүлемдә бирелгән үрнәкләр бер фараздан гыйбарәт.

Тормышка ашувы ихтимал булган кайбер үрнәкләр диңгезләрнең ташувы белән бәйле. Беленгәнчә, диңгез астында берәр тетрәү булган вакытта су өстендә дәү дулкыннар барлыкка килә. Тетрәү мәркәзеннән таралган тәэсир белән дулкыннар Океанны сегатенә 750 чакырымдагы югары бер тизлек белән үтеп, тизлек белән ярга ирешә. Океан уртасында бер мга җитмәгән дулкын ярга килеп җиткәндә 60 мны аша ала. Үрнәк буларак 1896 нчы елны Япониянең Хошу шәһәрендә барлыкка килгән олы бер диңгезасты тетрәве артыннан күтәрелгән бер дулкын 25-30 мны ашты, 25 000 кешенең үлеменә сәбәп булды.

Дәү дулкыннарның беленгән башка сәбәпчесе дә вулканнар.

"Краката" вулканының югары ноктасында барлыкка килгән ишелүдән соң күтәрелгән дулкын Ява һәм Суматра арасындагы бер утрауны көчле җимерелүләр белән югалып, көтелмәгән һәм бөек бер дулкынга сәбәпче булырга этәргән. Моның нәтиҗәсендә барлыкка килгән цунами, Ява утравының халык агыннан иң күпчелеген тәшкил иткән ярына бәрелеп, 165 авылның юк булувына һәм 36 000 кешенең үлеменә сәбәп булган. Бу дулкынның буе ярга килеп җиткәндә 35 мны ашкан . Күрелгәнчә , диңгез астында барлыкка килгән локаль тетрәүләр яки вулканнарның шартлавы барытик билгеле бер районга гына тәэсир итүләренә карамастан, диңгезләрнең ташувына , меңләгән кешенең үлеменә сәбәпче була. Югыйсә, Кыямәт Көнне җир өстендә дә , диңгезләр астында да тетрәүгә дучар булмаган һичбер урын калмаячак. Диңгезләр астында барлыкка килгән тетрәүләр белән берлектә диңгезләр үзләре дә ташачак , моңа хәтле күрелмәгән цунамиларның тәэсире бөтен җир йөзенә таралачак. Диңгезләрнең ташып ул көнне кешеләргә һәлакәт китерүве өчен тагын бик күп сәбәпләр бар. Бу зур күләмле су җыелмасының кузгалмыйча урынында калувы берничә канунга бәйле. Ләкин , ул көнне һичбер табигать кануны үтемле булмаячак, күкләрне, җирләрне, диңгезләрне һәм кешеләрне гармониядә тотучы хас закончалыклар юк булачак. Аллаһның теләге белән барлыкка килгән бу камил системаның кануннары, яңадан Аллаһның теләге белән бер

мизгелдә юк булачак. Алдагы бүлемдә аңлатылганча, ул көнне җир астындагы эсселек һаваның температурасын күтәреп , тышка чыгып бозларның эрүвенә сәбәп булачак. Бу да булган су микъдарының күтәрелүвенә китерәчәк. Боларның барысы да ихтималдыр, ләкин моның ничек тормышка ашачагын барытик Аллаһ кына белә.

Беленгәнчә, таулардан купкан туфрак яки тау кисәкләре берәр су җыелмасы өстенә төшеп локаль дулкыннарга сәбәпче була ала. Кыямәт Көнне исә, ишелмәгән, аумаган һичбер тау калмаячак һәм алдан белдерелгәнчә , бу таулар бөтен чокырларны тулдырып җирнең тип-тигез булувына сәбәп булачак. Таулардан төшүче кисәкләр диңгезләрне тулдырып аларның ташувына китерәчәк.

Аллаһ билгеләгән вакыт темамлангач , йөрәкләргә дәһшәтле курку салучы вакыйгалар чиратлашып тормышка ашачак. Кешеләрне биләп алган коточкыч тавышлар , тауларның җимерелүве, кешеләрнең аяклары астыннан аккан лавалар, һәръякны сарып алган тузан томаны һәм газ болытлары, кайнаган килеш кешеләр өстенә ташучы сулар... Билгесез-шартсыз һәркемне баш иярргә мәҗбүр иттергән, кешеләргә үзләренең гаҗизлекләрен һәм гөмерләре буенча зиннәтле күреп ашкынган нәрсәләренең ни хәтле кыйммәтсез икәнлеген күрсәткән каһәрләүче бер газаб... Ул көнне кешеләр хис иткән куркуны һәм дәһшәтне тасвирлап булмый. Кешеләр бер җирдән бер җиргә чабачак, качып котылырлык бер урын эзләргә тырышачак. Әмма һәркем белә ки, бу көннән котылу юк!

## КҮК ЙӨЗЕНЕҢ ХӘЛЕ

Кыямәт белән берлектә килгән җимерелү һәм дәһшәт барытик җир йөзе белән генә чикләнми. Кеше тарафыннан беленгән , күнеккән һәм гел дәвам итәчәге саналган бөтен барлыклар һәм системалар да юк булачак, бозылачак ул көнне. Дөнья тарихы буенча асылы аңлашылмаган, серләренә соңгы йөзьелда гына ирешелеп, акылга сыймаслык бөеклектәге күк җисемнәре һәм космос өчен дә үлем вакыты килгәндер. Күк йөзе: ай,

кояш, йолдызлар һәм планеталар барысы да ул көнне җимерелеп , кисәк-кисәк булып юк булырлар. Бу хакыйкатьне Аллаһ Көръәндә шулай белдерә:

***“Шиксез , сезгә вәгъдә ителгән тормышка ашачак. Йолдызлар “капланып (нурлары) сөртелгән “ вакыт . Күк ярылган вакыт.... (Мүрсәләт сүрәсе, 7-9)***

Галәм яратылган беренче мизгелдән соң булган һәр вакыйга һәм һәр күренеш – аларда бер могҗизалык барлыгын сизенгән һәм бер Яратучының барлыгын ачык буларак күрергә теләгән һәр кеше өчен бөек бер иман дәлиле. Иксез- чиксез космосның һәр ноктасындагы планеталар , йолдызлар, сансыз күк җисемнәре Аллаһның тик бер әмере белән генә яратылып, Аның кодрәте белән бөек бер система буларак корылган. Бу башлангыч һәм система әлегә серен саклап, кешеләрнең зиһеннәрен мәшгуль итә. Асылында бу эзләнешләр нәтиҗәсендә кеше каршысына чыккан тик бер хакыйкать бар – Аллаһның барлыгы. Кыямәт Көне яшәләчәкләр дә Яратучының бөеклегенә туры килгән хәлдә тормышка ашачак. Аллаһ , барлыкның һәрнәрсәсе өчен булганы кебек , күк йөзендәге бу бөек Дөнья өчен дә күрелмәгән бер ахыр әзерләгән.

Күк йөзе кешенең һәрвакыт барлыгыннан һәм дәвамлыгыннан имин булган бер түбә кебек . Аллаһ тарафыннан күк йөзенең һичбер таянычы булмаган хәлдә корылып, күтәрелеп һәм тотылып торган, иксез-чиксез космос белән кеше арасында пәрдә вазыйфасын үтәгән искиткеч бер түбә.

Бу түбә йөз елларча Дөньяны һәм өстендәге җанлыларны сансыз куркынычлыклардан (ультрафиалет нурларыннан, күк ташларыннан , космосның туңдыручы суыгыннан һ.б.) иң кечкенә бер җитешсезлек барлыкка китермичә саклаган, җанлылыкның дәвамы өчен кирәкле булган иң әһәмиятле калкан ролен уйнаган. Караңгы космостан үтеп килгән нур атмосфераның үзенчәлекләре сәбәпле Дөньяга кирәгенчә таралган, бөтен планетаны яктырткан һәм кеше атмосферага хас кислород пропорциясе нәтиҗәсендә сулыш алып яши алган. Югыйсә , Кыямәт Көнне күк бөтен функцияләрен тәмамлаячак. Инде аның да

Аллаһ тарафыннан билгеләнгән әҗәле бар. Ул көнне күк Аллаһның теләге белән селкенер, тетрәр, чайкаланыр, чатнар һәм ярылыр. Бу вакыйгалар турында аятьләрдә шулай хәбәр бирелә:

***"Ул көнне күк селкенер". (Тур сүрәсе, 9)***

***Бу сәбәптән күк тә ярылып чатнагандыр; (инде) Аның вәгъдәсе тормышка ашып, җиренә җиткерелгәндер. (Мүзәллим сүрәсе, 18)***

***Күк ярылып чатнагандыр; инде ул көнне (күк) асылган, зәгыйфләнгәндер. (Хакка сүрәсе 16)***

Дөнья тормышы буенча сансыз җанлының тормыш сөрүве өчен иң кирәкле шартлардан берсе булган һава бөтен функцияләрен тәмамлар. Ул көндәге закончалыклар күнегелгән закончалыклардан аерылыр. Сансыз физика кануннары буенча һәм дәвамлы система рәвешендәге пропорцияләр белән көйләнеп куелган күктәге атмосфера эреп ага башлар. Көръәндә ул көндәге күкнең таб булачагы соңы шулай аңлатыла:

***Күк йөзенең эрегән металл кебек булачагы көн. (Мәариҗ сүрәсе, 8)***

Атмосфера ул көнне эрер, кызар һәм яктылык белән яна башлар. Кешеләр тарафыннан зәп-зәңгәр булып күрергә күнегелгән күк йөзе, ул көнне кызыл буларак күренер. Күк йөзе ярылып эрегән май кебек булган:

***Соңыннан күк ярылып, май кебек эрегән кып-кызыл бер гөл булган вакыт. (Рахман сүрәсе,37)***

Кыямәт Көнне - "ул көнгә" кадәр Аллаһның бөеклеген һәм көчен күрергә теләмәгән , белә торып танымаган кешеләр өчен бөек үкенечнең яшәләчәге көн. Бу үгет алып уйлану һәм кылганнарны төзәтү мөмкинчелеге булмаган берүкенеч. Бөтен кешегә Аллаһтан башка дус, ярдәмче һәм саклаучы булмаганлыгын, Аллаһның көчен һәм газабын тәмам буларак аңлаганнар инде. Хәзер Аллаһка һәм Ахирәт көненә каршы инкяр эчендә була алачак һәм бу инкярны дәвам итәчәк "тик бер кеше" дә

юк. Бу хакыйкать бөтен кешеләргә шулай белдерелгән:

***Аллар Аллаһның кодрәтен кирәгенчә бәяли алмадылар. Югыйсә, Кыямәт Көнне җир бөтенлеге белән Аның кулындадыр; күкләр дә уң кулы белән төрелеп бөгелгәндер. Ул ширек кылганнардан пакъ һәм Олыдыр. (Зүмәр сүрәсе,67)***

Ул көнне кеше танып белгән барлык кануннур юк булыр. Яратылган вакытларында Аллаһның “теләп яки теләмичә итагать итегез” дигән чакырувына җавап китергән күк һәм җир, үзләренең яратылышлары кирәктергәнчә, хакыйкый Хуҗалары һәм Яратучылары булган Аллаһка баш иячәкләр. Көрьәндә Аллаһның күккә һәм җиргә эндәшүве шулай аңлатыла:

***Әйт ки : “Сез чыннан да җирне ике көндә яратучыны инкяр итеп, Аңа төрле ширекләр кыласызмы?” Ул галәмнәрнең Раббысы. Анда (җирдә), аның өстендә кузгатылмас таулар бар итте, аннары да бәрәкәт яратты һәм теләп әзләгәннәр өчен тигез булган хәлдә, андагы ризыкларны дүрт көндә билгеләде. Соңыннан томан хәлендә булган күккә юнәлде, шулай итеп аңа һәм җиргә диде: “Теләп яки теләмичә килегез!”***

***Икесе дә : “Теләп” (итагать итеп) килдек“ диделәр. (Фуссиләт сүрәсе, 9-11).***

Беленгәнчә, инкярчылар матдәнең үзеннән - үзе барлыкка килүвен исбатларга тырышыр. Тирә-юньдә күрелгән барча гүзәллекне табигать көченә сылтарлар. Калган нечкәлекләр, ягъни боларның ничек барлыкка килгәне, акылгы ия булучы Яратучы, һәрнәрсәдә Аның сыйфатларын чагылдырган бөтен барлык, хәтта табигатьнең үзе булмаганы килеш, ничек юктан бар ителгәне, җансыз табигатьтән ничек терелекнең, тормышның килепчыкканы турында һич уйланмаслар. Бу мантыксыз исбатлауга күрә, һәрнәрсәне табигать үзе-үзеннән бар кылгандыр. Ягъни хаким иткән могъҗизалы аһәң һәм тәртипнең хуҗасы таш, туфрак һәм судыр. Югыйсә , Кыямәт Көне килгәч кеше тауның, туфракның нинди хәлгә килгәнен күрер һәм бу көч хуҗасының

табигатьнең үзе булмаганлыгына шаһит булыр. Җанлы-җансыз һәрнәрсәнең яратылышы үзенә сылтау ителгән табигать ул көнне үзен саклый алмаячак. Аллаһ һәрнәрсәне тик үзенең көче һәм ихтияры белән генә бар иткәнлеген, тик Аның теләге буенча гына сакланып торганлыгын кешеләргә күрсәтәчәк. Вөҗданнары кабул иткән хәлдә, бу хакыйкатьләрдән качкан бик күп кеше ул вакытта аларны бөек берүкенеч белән хәтерләячәк. Кыямәт Көнне булачакларны Аллаһ аятьләрдә шулай хәбәр итә:

***Күк ярылып өлеш-өлеш булган һәм "үзенең яратылышы кирәктергәнчә" Раббысына баш игән вакыт. Җир тигезләнгән , эчендә булганннарын тышка атып бушалган һәм яратылышы кирәктергәнчә Раббыңа баш игән вакыт. Әй кеше, чынлыкта син һич туктамыйча Раббыңа карата бер тырышлык кылып торасың; соңында Аңа барачаксың. (Иншикак сүрәсе, 1-6)***

## Йолдызларның , Кояшның һәм Айның хәле

Космосның караңлыгына һәм суыклыгына карамыйча, Дөньябыз яктыртылувының һәм җанлылар яши алувының төп сәбәпчеләренең берсе – атмосфера. Ул моның өчен урта җылылык барлыкка китерә. Дөньябызны саклаучы бер түбә буларак беленгән атмосферада җылылык һәм яктылыкның таралу үзенчәлеге бар. Кап караңгы юлдан үтеп Дөньябызгача ирешкән кояш яктылыгының җир йөзен яктыртувы һәм җылытувы атмосфераның бу үзенчәлекләреннән килә. Ләкин, Кыямәт Көне килгәндә, бар булган һәрнәрсә кебек, күк тә чатнап ярылачак һәм бөтен функцияләрен тәмамлап, Көрьәндә белдертелгәнчә эреп агачак. Көрьәндәге Тәквир сүрәсенең беренче аятендә Кыямәт Көне аңлатылганда , "кояш каралтылганы вакыт" диелә. Бу Кояш яктылыгыннан инде Дөньяга бернинди дә файда булмаячагын аңлата.

Кыямәт Көнне Дөньяга яктылык бирүче Кояш һәм Ай берәр-берәр каралачаклар. Ул көнне Дөньяга яктылык килмәгәнлекнең сәбәбе бары атмосфераның юк булувы түгел. Чөнки Көрьәндә белдерелгәнчә ,

ул көн тик күкләр, җир һәм икесе арасындагы булганнарның гына юк булачагы бер көн түгел. Бөтен галәмнең юк булачагы көн.Тәгабүн сүрәсенең беренче аятьләрендә дә белдергәнчә, Аллаһ һәрнәрсәне камил һәм кимчелексез буларак Яратучы һәм һәр теләгәнен теләгән вакытында тормышка ашырырга көч җиткерүче. Миллиардларча галактикага һәм һәр галактикада миллиардларча йолдызларга ия булган космосны Ул яраткандыр һәм теләгән заманында бер “бул” диюве белән юк итүчесе дә Аллаһ...

Космосның киңлеген кеше акылының бөтенләй һәм чын буларак аңлавы мөмкин түгел. Әмма, берничә сан белән бу серле Дөньяның бөеклегенә якынча төшенү өчен тырышлык күрсәтә алабыз.

Кояш безнең галактикабызның 200-250 миллиард йолдызларыннан берсе генә. Дөньядан 325,500 тапкыр зуррак булувына карамастан, космосның кечкенә йолдызларыннан санала. Диамы 125 мең яктылык елы булган галактикабызның мәркәзеннән Кояш 30 мең яктылык елы ераклыгында. Бер яктылык елы якынча 9460800000000 килом. Дөнья исә, үзе тирәли сәгатенә 1670 килом тизлек белән әйләнгән 6 квадрилиард тонна авырлыгындагы масса.

Кояш сәгатенә 72000 килом тизлек белән хәрәкәт итәр, галактикабыз үзенең күчәре тирәли сәгатенә 900 000 тизлек белән әйләнер. Ләкин, акылларга сыймаслык бу галәм , Кыямәт Көнне Аллаһның теләге белән җимереләчәк, аңлатыла алмаслык зурлыкларга ия булган йолдызлар, Көрьәндә хәбәр ителгәнчә , “капланып себереләчәк” , юк булачак.

Космосның һәр ноктасы Аллаһ барлыгының, бөеклегенуң һәм көченең аерым бер дәлиле. Алар тик Аның теләге белән генә, Ул билгеләгән заманга кадәр генә булдылар, Аның рөхсәте белән генә бар ителделәр. Бу аһәңне яраткан һәм саклаган Аллаһ, әлбәттә, боларның барысын теләгәнчә юк итәргә дә кодрәтле. Космосның үлеме , бар ителүвендә булганы кебек, тик Аның рөхсәте белән , Ул билгеләгәнчә тормышка ашачак. Кешеләрнең гөмерләре буенча бөеклекләреннән хәйран калганнары һәрнәрсә тар-мар ителәчәк. Бөтен планеталар,

йолдызлар, Кояш һәм Ай кучәрләреннән (орбиталарыннан) чыгачак, йолдызлар коелачак, күк җисемнәре берәр –берәр үләчәк. Көръәндә ул көнне Айның ярылачагы , каралып чатнаячагы шулай белдерелә:

***Сәгать (Кыямәт вакыты) якынлашты һәм Ай ярылды. (Камәр сүрәсе,1)***

Бер аятьтә дә белдерелгәнә , инде ул көнне качачак бер урын юк. Дөнья тормышлары буенча үзләренә Аллаһтан башка дус һәм ярдәмче эзләгән кешеләр дә инде, юнәлеп кайтылачак хакыйкый дус һәм ярдәмче бары Аллаһ булганлыгын аңлаганнар. Ул көн – кешеләр ирешә алмаган , аларга искиткеч һәм серле күренгән йолдызларның да үлем көне. Һәрбересе тәртип һәм тигезлек белән әйләнгән кучәрләреннән чыгып , сибелеп таралачаклар:

***Йолдызлар сибелеп таралган вакыт. (Инфитар,2)***

Беленгәнчә, Кояш һәр секунд энергия бирүче бер йолдыз. Космостагы башка йолдызларның күпчелеге исә, Кояштан кат-кат зурраклыр һәм кояшның энергиясеннән тагын да күбрәк энергиягә ияләр. Югыйсә , Кыямәт Көне килгәндә барысы да көчләрен югалтып, сүрелеп түгеләчәкләр. Көръәндә Кыямәт Көнедә йолдызларның хәле шулай аңлатыла:

***Йолдызлар сүрелеп түгелгән вакыт. (Тәквир сүрәсе,2)***

***Йолдызлар "капланып (нурлары) сөртелгән" вакыт. (Мүрсәләт сүрәсе,8)***

Меңнәрчә ел яктылык бирүче, Дөньяның тормышын һәм энергиясен тәэмин итүче Кояш һәм күк йөзен бизәгән йолдызлар ул көнне каралыр. Һәркем тагын бер кат ул заманга кадәр аларны кучәрләрендә тотучының һәм яктылык бирүләрен көйләүченең , йолдызларның да хакыйкый хуҗасының Аллаһ икәнлеген һәм ул вакыткача бары Аның рөхсәте белән бар булганлыкларын аңлар.

Инкяр итүчеләр ул көнне Аллаһтан ярдәм күрмәс. Ярдәм күрә

алачаклары башка бернинди бер көч тә юк. Технология бик каты алга китеп һәм шуның аркылы космосның ерак бер читенә китү дә хәтта мөмкин булса, кешеләр өчен һичбер нәрсә үзгәрмиячәк. Газаб кешеләрне анда да табачак. Чөнки Кыямәт бөтен космосны каплагандыр. Барытик өстендә бер заманнарда иминлек эчендә йөрелгән җир йөзе генә түгел, ирешелмәс санаган ерак йолдызлар да Аллаһның әмеренә баш игәннәр, юк булганнар. Кешеләрнең ул көндәге чарасызлыклары Көрьәндә шулай аңлатыла:

***...Ай каралгач". Кояш белән Ай берләшкән вакытта. Кеше ул көнне "Качу кая?"-дияр. Юк, сыеныргылык һичбер урын юк. Ул көнне соңында китерелеп карар кылыначак урын барытик Раббыңныкыдыр. Кешегә ул көнне алдан хәзерләгәне һәм калдырган нәрсәләре турында хәбәр бирелер. (Кыямәт сүрәсе, 8-13)***

## Кыямәт вакытында кешеләр

Моңа кадәр аңлатылган барча вакыйгалар, кешеләрнең һич хәбәре булмаган бер мизгелдә, элегрәк һич ишетелмәгән һәм беленмәгән бер тавышның ишетелүве белән башлангандыр. Һәм Дөньядагы барлык кешеләр, хәзерге вакытта да булганы кебек, һәрнәрсәнең һич үзгәрмичә һәм бозылмыйча шулай ук дәвам итәчәген уйлаганда , көтелмәгәндә тотылганнардыр.

Сурга өрелүдән бераз алда тормышка ашкан вакыйгаларның алдагы көннекеннән бернинди аермасы да юк. Дөнья һаман да шул тизлек белән әйләнә , кояш Дөньяны яктырта , тормыш дәвам итә һәм кешеләрнең күбчелеге нигә, кем тарафыннан яратылганнары һәм соңнары турында уйланмыйча күнеккәнлек хәлдә тормышларын дәвам итәләр. Кем кич белән киләчәк кунагына хәзерләячәк ризыгын, кем башкарачак эш күрешүләрен уйлаганда, кем алыш-биреш, сәүдә иткәндә, кем йоклаганда һәм бөек бер өлеше дә Аллаһ барлыгына инкяр хәлендә була торып бу тавышны ишетәчәк һәм һәрнәрсә бер мизгелдә башлаячак, һәрнәрсә бер мизгелдә юк булачак.

Кешенең көчле дип санаганы, мактанып тәкәбберләнгән гәүдәсе, һич көтмәгән бер мизгелдә дурт яктан үлем белән сарылып алыначак. Җан коткарудан башка һичбер проблема калмаячак. Кешеләр яшәгән куркуның дәһшәтеннән, кыйммәт бирелгән, көчле иттереп бәйләнелгән, ия булу өчен һәртөрле фидакарьлек күрсәтелгән әйберләрне бер мизгелдә күрмәс дәрәҗәгә киләчәкләр.

Кыямәт китергән бөтен бу курку, дәһшәт һәм шашкынлык Дөньяда инкяр эчендә яшәгән бик күп кешенең гафләтенә бер каршылык. Ул көнне башланган бу чыдый алмаслык авырлыклар инкярчылар өчен мәңге дәвам итәчәк. Бер-бер артлы булган бөтен бу вакыйгалар алардагы паниканы , дәһшәтне тагын да арттырачак. Үткән һәр мизгел яңа газап һәм бәлаларны китерә. Акылга сыймаслык бу вакыйгалар аларга ул көнгә кадәр инкяр ителгән Аллаһның бөеклеген күрсәтер.

Кеше бу көч каршында гаҗиз һәм чарасыздыр. Үкенеч, кайгы һәм куркудан башка бернәрсә дә юк аның өчен. Секундалар үткән саен, мәңгелек тормышындагы үзенә Аллаһ тарафыннан хәзерләнгән куркыныч газапны тагын да яхшырак аңлый бирә. Ул көнне кеше каршылашкан дәһшәт тулы минутлар аның мәңгелек тормышы буенча яшәләчәк газапның бары тик чикләнгән шул вакыттагы кечкенә чагылышы гына. Бу мәңгелек газап артачак һәм аның соңсыз дәвамы булачак. Ул көнне яшәләчәк вакыйгалар каршысында кешеләр тоячак курку Көрьәндә җентекләп аңлатылган.

**Кешеләр тойган курку**

Аллаһ бик күп аятьләрдә кешеләрнең Дөнья тормышына бик каты бәйләнгән булуларын һәм моның Ахирәт тормышында һичбер файдасы булмаячагын белдергән. Кешеләр тарафаннан Дөнья тормышында бәяләнгән, мөһимсенгән, ия булулары өчен бик күп фидакарьлек күрсәтелгән кыйммәтле нәрсәләр, әгәр Аллаһ ризасы өчен һәм Аллаһ юлында кулланылмаса, кешегә югалтудан башка берни китермәс. Боларның һәрбересе кешеләрне сынар өчен аеруча яратылган. Асыл йорт - Ахирәт йорты. Дөньядагыларның һичбер әһәмияте булмаганлыгы Көрьәндә шулай аңлатыла:

***Хатыннарга, угылларга, кантар-кантар җыелган алтын һәм көмешкә, җитез, гүзәл атларга , хайваннарга һәм игенлекләргә тоелган хисле шәһвәт (теләк) кешеләргә “бизәкле һәм тартучан” кылынды. Болар Дөнья тормышында кулланылган фани нигъмәтләр . Асыл барылачак гүзәл урын Аллаһ Катында булганы. (Али Имран сүрәсе, 14)***

Дөнья тормышының аятьтә аңлатылган бөтен бу “тартучан” үзенчәлекләренә кеше хис һәм катылык белән бәйләнә, бөтен гөмерен боларга ия булыр өчен багышлый. Көрьәндә Дөнья тормышы белән бәйле буларак шулай боерыла:

***Белегез ки, Дөнья тормышы барытик бер уен, ”теләкле күңел ачу гына” , бер бизәк, үзегез арасында бер мактанышу (вакыты һәм нәрсәсе), мал һәм балаларда бер күбәю теләгедер. Бер яңгыр мисалы кебек: ул үстергән игенлек игенчеләргә (яки кяферләргә) хуш килер, соңыннан бер карарсың ки, сап-сары булган, соңыннан ул бер чүп-чарга әйләнелгәндер. Ахирәттә исә көчле газап , Аллаһтан ярлыкану һәм хуш булу (ризасы) бардыр. Дөнья тормышы алданыш булган бер нигъмәтләнүдән башка бер нәрсә түгелдер. (Хадид сүрәсе, 20)***

Дөнья тормышының иң бөек максатларыннан берсе булган маллар, уллар, кыскасы – ия булган бөтен нәрсәләр белән мактанышу. Көрьәндә аеруча игътибар ителгән һәм бөтен җәмгыятьләргә дә кагылган тагын бер мәсьәлә, Дөнья тормышындагы иң мөһим теләкләрнең берсе – балалар. Балалы булу теләге кешеләргә яшьлек елларыннан ук өйрәтелер. Бала кешеләр арасында сәбәпсез бер көндәшлек булдыручы, шул ук вакытта киләчәккә юнәлгән бер гарантияне дә аңлатыр.

Башка теләкләр – мал һәм байлык теләкләре. Беленгәнчә , кешеләрнең Дөнья тормышлары буенча куйган бөтен максатлары, планнары, тырышлыклар бу теләкләр белән бәйле. Мал һәм акча теләге кешеләрнең күзен каплаганлыктан бөтен әлак нормалары әһәмиятлекләрен югалтып, кеше холкын билгеләүче барытик матдият калгандыр. Көрьән әхлагы, әмер һәм тыюлары кеше тормышындагы

беренчелекләрен югалтып, мал җыю бердәнбер максатка әйләнгән, мөнәсәбәтләрдәг матди файдалар алгы планга чыккандыр.

Югыйсә , Кыямәт Көне килгәндә һәрнәрсә киресенчә булачак. Кешеләр каршылашкан көннең куркусыннан кыйммәт бирелгән һәрнәрсәне бер мизгелдә онытачаклар. Ашкынып теләнгән нәрсәләрнең инде бер мәгънәсе калмаганлыгын аңлаячаклар. Бәяләү системалары берничә секунд эчендә үзгәрер. Инде малның , хәтта балаларның да бер кыйммәте юк. Әнилек һәм әтилек хисләре мәгънәләрен югалткандыр. Дөньяда иң якын күргән кешесен – хәтта үзенең баласын да Кыямәт Көненең дәһшәтеннән онытачак. Бер кем дә баласының хәлен сорамыячак, моны хәтта акылына да китермәячәк. Шиксез , Кыямәт тормышка ашачагы бу көн, инанмаганнар өчен авыр бер көн:

***Күк йөзенең эрегән металл кебек булачагы көн. Таулар да (тирә-якка очышкан) төрле төстәге йон кебек булачак. (Мондый бер көндә) һичбер якын дус бер якын дусны сорамас. Алар бер-берсенә күрсәтелер. Бер гаебле-гөнаһлы ул көннең газабына каршылык итеп улларын фидья (фида) буларак бирергә теләр, үзенең хатынын һәм кардәшен һәм үзен саклаган кавемен дә. Җир йөзендә булганнарның барчасын (бирсә дә), соңыннан котылса. (Мәариҗ сүрәсе, 8-14)***

***Күкнең болытлар белән өлеш –өлеш булачагы һәм фәрештәләр бер иңдерү белән иңдерелгән көн. Бу көнне чын хакимият Рахман (булган Аллаһ)ныкыдыр. Инкяр иткән өчен бик авыр бер көндер. (Фуркан сүрәсе, 25-26)***

Хәтта бәбәйлек чакларында булган балалардан да гаиләләре ул көнне ваз кичәр. Кешеләр һич көтелмәгән һәм элек һич күрелмәгән бу вакыйгалар каршысында ни кылачакларын белмичә шашырыр. Курку шундый көтмәгән һәм көчле буларак килгән ки, авырлы хатыннар бу шокның тәэсиреннән балаларын төшерер. Бу авыр көндә яшәләчәк вакыйгаларның тәэсирендә хатыннарның имезгән балаларын онытулары Көръәндә шулай белдерелгән:

***Аны күргәнегез көн. һәр имезүче үзе имезгәнен онытып***

***китәчәк һәм авырлы үзенең йөген тошерәчәктер. (Хаҗ сүрәсе, 2)***

Кыямәт Көне, Дөньяда вакытта үзенә ясалган чакыруларга җавап бирмичә, хакыйкый дус һәм Яратучысы булган Аллаһны онытучыларның бер-берләреннән качып котылырга теләгән көндер. Һәркем үзе турында гына кайгырта. Ул дәһшәтле көндә кешеләр арасында һичбер мөнәсәбәт – ни нәсел, ни туганлык , ни дә дуслык мөнәсәбәтләренең калмаганлыгы Көръәндә шулай белдерелер:

***Кеше ул көнне үзенең туганыннан качар, анасыннан һәм атасыннан, хатыныннан һәм балаларыннан. Ул көнне алардан һәрберсенең үзенә җитәчәк бер эше бардыр. (Абәсә сүрүсе, 34-37)***

## Кешеләр исерек кебек

Кешеләр ул көнне күренгәннәр каршысында бөтен суык канлылыкларын, үзләренә булган ышанычларын һәм каты торучанлыкларын югалтачаклар. Үлем белән очрашкан вакытта һәрнәрсә үз кыймматен югалтыр, йөзләр , хәрәкәтләр, сөйләшүләр үзгәрер.

Кешеләрнең үлем каршысында курку һәм дәһшәтенә фильмнарда шаһит булырбыз. Ул вакыттагы реакцияләр кешеләр эчендәге булган рухи хәлне бик яхшы аңлатыр. Әмма, каралган күренешләрдә кешеләрнең әз дә булса котылу өметләре бар. Үләчәкләрен кискен рәвештә белсәләр дә, үлемнән соң ни булачакларын тулаем буларак белә алмаслар яки бөек бер өлеше үлем белән берлектә юк булачагын уйлар. Югыйсә , Кыямәт Көнендә әле үлем килеп җитмәгән булса да, яшәгән вакыйгалар кеше өчен һичбер котылу ихтималы булмаганлыгын бөтен ачыклыгы белән уртага куяр. Инкяр итүчеләр үзләренә вәгъдә ителгән хәлдә инанмаганнары бер көн белән кара-каршы килерләр. Ул көнне космос системасының бер Яратучысы һәм саклаучысы булганлыгы, Ул теләгән вакыт һәрнәрсәнең юк булачагы да бөтен ачыклыгы белән күрелгән бер көн.

Кешеләр үлемнең , ул көнгә кадәр уйлаганнары кебек, бер юк булу гына булмаганлыгын аңларлар. Бу вакытка хәтле Аллаһның

барлыгына, шуның белән бергә Ахирәткә инанмаганлыкларыннан, үлемнән соң булачак вакыйгалар турында да һич уйланмаганнардыр алар. Әмма, Аллаһның барлыгын һәм көчен, бер-бер артлы килүче бу вакыйгалар соңында ап-ачык буларак күргәннәр, үзләрен көткән бер соңны да көн кебек аңлаганнардыр. Котылу өмете булмаганлыгын аңлаган кебек, үзләрен көтүче яңа һәм соңсыз бер яшәеш булганлыгын да аңлаганнардыр инде. Инкярчылар өчен бу бик авыр бер яшәеш. Соңсыз буларак чигеләчәк газаплары һәм хәсрәтләре ул көнне яшәлгәннәр белән чагыштыра алмаслык кадәр авыр булачак. Инкяр итүчеләр мондый бер яшәеш урынына юк булуны хуп күрәчәкләре аятьләрдә шулай аңлатыла:

***Чыннан да, Без сезне якын бер газап белән кисәттек. Кеше үзенең куллары алдан ни хәзерләгәненә караячагы көн, кяфер булган да: “Аһ, мин туфрак булса идем!”- диячәк. (Нәбә сүрәсе,40)***

Кешеләрнең каршылашкан вакыйгалар сәбәпле көчле бер курку , паника һәм шашкынлык эчендә исерек кебек булулары аятьтә шулай белдерелә:

***“Кешеләрне дә исергән буларак күрерсең, югыйсә, алар исерек түгел. Тик Аллаһның газабы бик көчледер”. (Хаҗ сүрәсе, 2)***

Кешенең көчле курку вакытында гәүдәсендә барлыкка килгән үзгәрешләр һәм контрольсыз хәрәкәтләре һәм исерек кешеләрнең үз-үзләрен тотышлары бер-берсенә бик охшаш. Көчле курку вакытында баш әйләнүве, елау күрелә, күрү болганчыклана.

Моңа кадәр аңлатылган вакыйгалардан да аңлашылганча, ул авыр көнне кешеләр бик зур паникага биреләчәк. Кешеләр яшәгән бу көчле куркуны һәм курку нәтиҗәсендә барлыкка килгән физик реакцияләрне Аллаһ исерек булу белән чагыштыра. Исерек кебек булган кешеләр ул көнне контрольсыз хәрәкәтләр күрсәтеп, бер җирдән бер җиргә чаба башларлар. Көръәндәге чагыштырма кешеләрнең бу хәлен шулай ачыклый:

***Кешеләр “һәръякка таралган” күбәләкләр кебек булачак көн... (Кариа сүрәсе,4)***

## Күзләрдәге дәһшәт

***Чын булган вәгъдә якынлашкандыр, менә ул заман инкяр иткәннәрнең күзләре ояларыннан атылачак: “ Үкенеч безгә, без монардан бөтенләй гафләт эчендә идек,без залимнәрдән идек”,- (диячәкләр). ( Әнбия сүрәсе, 97)***

Күз - кеше яшәгән куркуның көчен иң элек күрсәтүче әгъза. Ул көннең куркусын яшәячәк кешеләр, каршылашкан дәһшәт сәбәпле, күзрәре урыннарыннан атылачак. Монда китерелгән “күзләренең ояларыннан атылу” чагыштырмасы кеше яшәгән куркуның көчен аңлатыр. Бу вакытта кешенең күз алмасы зурая, күз агы үзен күбрәк билгеле итеп төсен югалта башлый. Кыямәт тормышка ашкан вакытта “искәрмәсез кешеләрнең һәммәсе” бу куркуны яшәячәк . Бу бик куркыныч вакыйгалар каршысында кемсәнең дә кылачак нәрсәсе, башларына килгәннәрне туктату өчен табачак чарасы юк. Барытик курку тоярлар. Аятьтәге чагыштыру бу куркуны ачыклык белән аңлата.

## Балалар чәчләренең агаруы

***Әгәр инкяр итәчәк булсагыз , балаларның чәчләрен агартучы бер көндә үзегезне ничек саклаячаксыз? (Мүзәллим сүрәсе, 17)***

Кыямәт Көненең куркусы кечкенә балаларны да сорачак. Бу көннән хәбәрсез булган , аның максатын һәм газапның беренче көне булганын белмәгән балаларда олылардан аермалы булган бер курку бар . Кешеләр фани Дөнья буенча кылган әхлаксызлыкларыннан үкенеч эчендә. Балалар ни булып беткәнлеген дә төшенерлек хәлдә түгел. Моңа карамастан, күргән вакыйганың дәһшәтеннән чәчләре ап-ак булыр. Мондый бер физик үзгәреш ул авыр көннең бөеклеген аңлау өчен әһәмиятле . Чөнки ул көнгә кадәр Дөньяда күптөрле һәлакәтләр яшәлгән. Һәрбересе кешеләргә бик көчле курку биргән һәм аларны тирәнтен тәэсирләндергән. Әмма, һәлакәтләрнең һичбере, Кыямәт Көне булачак вакыйгалар белән чагыштырганда, балаларның чәчләрен агартачак кадәр көчле түгел! Ул көн - кешеләр тарафыннан Дөнья тормышларында яшәлгән иң авыр көн. Шундый ки, килгән вакыйгаларның дәһшәте, кыска

тормышларында куркуның асылына һәм куркынычлыкларның ни китерә алуларына төшенмәгән балаларның да хәтта, чәчләренең куркудан ап-ак булувына сәбәп булачак.

### Хайваннарның хәле

Вәхши хайваннарны күз алдыгызга китерегез: юлбарыс, арыслан, буре, шакал, аю... Бу хайваннар Кыямәт Көнне булган вакыйгаларның тәсиреннән инде бер-берләре белән көрәшне дәвам итүне ташлар һәм бер урынга тупланыр. Меңнәрчә вәхши хайваннан торган бу күренешнең өркетүче булувы бик ачык. Кыямәт Көнне табигатьтә булачак һәм кешеләргә кагылган бик олы үзгәрешләрне Аллаһ бик күп аятьләрдә шулай белдерә:

***Авырлы дөяләр ялгыз башын калдырылгын вакыт, вахши хайваннар тупланган вакыт... (Тәквир сүрәсе, 4-5)***

# КОСМОСНЫ АЛЛАҺ ЯРАТТЫ

Космосның ничек бар булганы хәзергәчә төрлечә аңлатылган. Берәүләр космосның бер башлангычы булмаган фикерен , теориясын тәкъдим иткән, берәүләре дә материяның гел булганлыган яклаган.

Материянең гел булганлыгын яклаучы бу теориянең берсе Статистик Космос Теориясе иде. Озын вакыт дәвам иткән һәм масштаблы эзләнүләр нәтиҗәсендә уртага чыккан көчле дәлилләр космосның бер башлангычы булганлыгы тезисын дөресләде. “Статистик Космос Теориясы” исә, белемнең тарихи тәрәккыяте сәбәпле, бары бер хәтирә буларак калды.

Эзләнүләр нәтиҗәсендә ия булган күрсәткечләр космосның юк булган хәлдә бар ителгәнен күрсәтте. Аларга күрә, космосның бер башлангычы бар. Һәм башлангычы “Big Bang” (Биг Банг исеме) бирелгән бөек бер шартлау аркылы тормышка ашкан. Биг Бангтан алда матдә, энергия, галәм, вакыт, урын - кыскасы һичбер нәрсә юк.

Бер ноктаның шартлавы нәтиҗәсендә куркыныч бер тизлек белән һәр тарафка таралган матдәләрдән йолдызлыр, кояшлар, планеталар барлыкка килгән, космос тизлек белән киңәйгән, шешеп зурайган һәм бер вакыттан соң суынып хәзерге хәленә килгән.

Бүгенге көндә галәмнең Биг Банг белән бергә башланганлыгы, аның барлыкка килеш формасы , шулай ук билгеле бер яше булганлыгы бөтен космология китапларында, гыйльми журналлар һәм мәкаләләрдә исбатлары белән урын ала. Моны берничә җөмлә белән генә аңлату мөмкин булмаганлыктан, барытик бер-ике үрнәк белән генә бу теманың әһәмиятен күрсәтү урынлы булыр.

Үрнәк буларак Калифорния университетыннан профессор Джорж О. Абел (Georrge O. Abel) “Expleration of Universe” (“Космосның ачылышы”) исемле китабында :

***“Бүгенге булган дәлилләр, космосның миллионнарча ел алда Биг Банг белән башланганын күрсәтә. Биг Банг теориясы кабул итүдән башка чарабыз юк. Шулай итеп, “Хәрәкәтсез хәл” теориясе инде үз көчен югалтты”- дип әйтә[1].***

Коларадо университетыннан Джеррит Л. Верхююр (Gerrit L. Verhuur) “Star Capes” исемле китабында “Биг Банг теориясе дини инанулар күрсәткән, Дөньяның һәм күк йөзенең яратылган булганлыгы хакыйкатен дөресли. Бу астрономиянең дин белән берлектә икәнлеген күрсәтүче сюрприз нәтиҗә,”-дип ачыклый.

Космосның бер башлангычы булувы – галәмнең юктан бар ителүвенә, ягъни яратылувына дәлил. Шиксез, Һәр яратылган барлыкның бер Яратучысы булувы тиешлеген дә барыбыз да бик яхшы беләбез. Яратылган бу космос һичбер үрнәк булмаган килеш, хәтта заманның һәм урынның да булмаганы килеш бар ителгән. Бу теория уртага куйган иң әһәмиятле хакыйкать – космосның бер башлангычы булганлыгы, өстен һәм көчле бер Яратучы тарафыннан яратылган булганлыгы, космосны Аллаһ яратканы.

Биг Банг космоста хисаплый алганыбыз иң элеккеге хәрәкәт. Бөек шартлаудан соң бүгенгә кадәр сансыз хәрәкәтләрнең һәм вакыйгаларның һәрберсе Аллаһның рөхсәте белән барлыкка китерелгән һәм Аның идарәсендә. Акылсыз , белемсез һәм башка һичнинди өстен сыйфатларга да ия булмаган бер шартлау нәтиҗәсендә таралган кисәкләрдән системалы галактикаларның, йолдыз системаларның һәм эчендә Дөньябызның да урын алган “Кояш Системасының” барлыкка китергәнен уйлау, акыл һәм мантык (логика) тышындагы бер халәт. Кешенең үзенең гәүдәсе белән бергә тирә ягындагы һәрнәрсәсе, Аллаһның гыйлеме һәм идарәсе белән бөек бер система , тәртип эчендә яратылган. Көръәндә Аллаһның башта күк йөзен яратканлыгы, аннан соң җирне барлыкка китергәнлеге, соңыннан да җанлыларны бар кылганлыгы турында белдерә.

Аллаһ космосны бик нечкә система буларак һәм нечкә пророцияләр белән яраткан. Атмосферадагы газларның микъдарыннан Дөньяның җылылыгына, яңгырның яву тизлегеннән Дөнья төшендәге тимер микъдарына кадәр кеше белгән һәм белмәгән сансыз детальләр бер-берсенә бейле. Моңа үрнәк буларак космостагы бөтен планеталарны һәм Дөньябызны Кояш орбитасында  тоткан массаның тарту (җирнең тарту) көчен китерә алабыз.  Космостагы бөтен объектлар зурлыкларына карата тарту көченә ия. Дөньябыз ия булган тарту көче диңгезләрне, җанлы – җансыз һәрнәрсәне җир йөзендә тотрыклы тотар. Шулай итеп , кешеләр дә, башка җанлылар да, таулар һәм диңгезләр дә галәм бушлыгына очмас. Иң мөһиме – җир шары зурлыгының шундый тормыш булдыручан әһәмияткә ия булганлыгы. Җир шары тагын да зуррак булган булса, өстендәге һәрнәрсәне тагын көчлерәк үзенә  тарту көченә ия булачак иде. Моның нәтиҗәсендә сулар җирнең эченә тартылачак, кешеләр көчле тарту сәбәпле йөри алмас хәлдә булачак, су агач ботакларындагы яфракларга барып җитмәячәк, җиргә тартылганы өчен үсемлекләр үсә алмый юк булачак, җанлыларның гәүдәләрендәге кан әйләнеше бозылачак һәм кан бөтенлеге белән аякларда тупланачак  булыр иде. Үрнәкләрне күбәйтергә мөмкин. Иң мөһиме, җир шары зурлыгының экологик  балансны саклап калырлык дәрәҗәдә бик нечкә буларак көйләнгән булувы.

Дөньяның соңы ничек булачагы турында эзләнүләр ясаган галимнәр һәр көн үтү белән һәр нәрсәнең искереп черегәнен һәм бу черү нәтиҗәсендә космосның соңы килүвен исәпкә алалар. Хәтта җир йөзендәге “тик бер протонның” гына пропорциясе бозылувы да начар нәтиҗәгә китерә алачагын  белдерәләр һәм бу куркыныч турында хәбәр бирәләр:

***“Космостагы черү, әгәр чын исә, гасырлар үтәчәк, ләкин тормышка ашачак вакытында ни йолдыз, ни кеше, ни атом , ни хәтирә калачак үзеннән соң...”***

Бу ачык хакыйкатькә игътибар ителгәннән соң, асыл куркынычка шулай ишарәт ителә:

***"Бүгенгә кадәр ясалган һичбер эзләнү яки эксперемент та бары бер протонның юк булганлыгын да исбатлый алмады. Ләкин , бу галимнәрне шул тема белән бәйле эзләнүләрдән ваз кичермәде. Галимнәрнең протон черүвенә шаһит булулары, бөтен космосның юк булу куркынычлыгы белән кара-каршы булганлыгын аңлатачак. Тик бер протонның гына юк булувы, космостагы һәрнәрсәнең черүве димәк, чөнки бер протонның гына черүве, бөтен протоннарның чери алувын һәм шулай итеп атомнарның , молекулаларның һәм ДНКларның формалашмаячагын күрсәтер[2].***

Монда китерелгән берничә деталь генә дә, космосның өстен бер көч тарафыннан бик бөек система буларак һәм бик нечкә пропорцияләр белән юктан бар ителгәнен дәлилли. Өстен көч иясе булган Раббыбыз бу кимчелексез системаны саклый, күзәтә:

***Шөбһәсез , Аллаһ күкләрне һәм җирне кузгалырлар дип ( Һәр мизгел кодрәте белән) тота. Ант ки, әгәр кузгалсалар, Аннан башка инде беркем дә аларны тота алмас. Чыннан да Ул - Халим, Ярлыкаучы. (Фатыр сүрәсе, 41)***

Аллаһ Көръәндә космоста бар булган һәрнәрсәнең соңы булачагын белдергән. Әлбәттә, космосны яраткан һәм аны һәрчак саклаган Аллаһ, теләгән мизгелендә аның барлыгына соң бирергә дә Кадир (көч җиткерүче). Ул бөек көнне (Кыямәт Көне) бар булган бөтен пропорция һәм системалар бозылачак, кешенең "аңларга тырышам" дип, тукталмыйча тырышлык күрсәткәне һәм бөеклеге белән бу кешене хәйран калдырган һәрнәрсәнең асты өскә китереләчәк:

***Берәр нәрсәне теләгәне заманда Аның әмере барытик " бул" диюве , ул да шунда ук барлыкка килер. Һәрнәрсәнең хакимияте һәм мөлкәте кулында булган (Аллаһ) ни бөек! Сез Аңа кайтарылачаксыз. (Ясин сүрәсе,82-83)***

## Космос бер мизгелдә юк була ала

Дөньябыз дурт яклап үлем китерә алырлык куркынычлыклар белән уралган. Күп кенә кешеләрнең бу куркынычлыклардан хәбәрләре булган хәлдә, космос барлыгының соңына китерәчәк һичбер куркынычлык юк кебек һәм тормышлары бик нык гарантияләнгән кебек яшәеш алып баруларына шаккатырлык. Бу аңлаешта булган кешеләрнең акылларына үлем, юк булу, үлемнән соң булачаклар килмәс.

Дөнья иксез-чиксез бушлык эчендә бер юлчылык хәлендә. Югыйсә, Дөнья юлчылыгын дәвам итә алувы өчен кирәк булган шартлар исәп кылынганнан тагын да күбрәк. Дөнья космостагы бу юлчылыгы вакытында дәү күк ташлары , каметалар, кара тишекләр, супернова шартлаулары кебек бик күп янаулар белән каршылаша . Дөньяның үз орбитасында калувы , тизлеген саклавы, янтаю градусын бозмавы, үз тирәсендә әйләнгән килеш, шул ук вакытта Кояш тирәли дә әйләнүве, әйләнүвенең спираль орбита буенча булувы, бу юлчылык заманында вакыт-вакыт булган бөтен пропорция һәм тигезлекләрнең дәвамлыгы аның яшәешен саклый бирә.

Югыйсә , бу пропорцияләрнең бозылмавы яки тыштан килүче берәр янауның үлем китерерлек итеп зарарлар бирмәве өчен һичбер сәбәп тә юк. Галимнәр бу янауның барлыгына һәр форсатта игътибар итәләр. Дөньяның һәр мизгелдә берәр янау белән кара-каршы килә алувы темасында гыйльми күрсәткечләргә таянып фикердәшлек күрсәтәләр. Профессор Др. Карл Сэйгон бу хәлгә шулай ишарәт итә:

***“Җир йөзе гүзәл һәм бик тыныч урын. Үзгәргән нәрсәләр булыр, фәкать алар бик әкрен барлыкка килер. Мөмкин ки, тормышыгызны берәр давылдан да көчлерәк табигый һаләкәт күрми калып тәмамлый аласыз. Шулай итеп, хафаланмыйча һәм кайгырмыйча яши бирә аласыз. Табигатьнең шартлары билгеле. Дөньяларның һәрбер мизгелдә юкка чыга алувыннан качып булмый. Без кешеләр хәтта үзебезнең һәлакәтләребезне яратырлык***

***технологиягә ирештек. Бу һәлакәтләр ниятле рәвештә була алган кебек, белмичә, берәр игътибарсызлык нәтиҗәсендә дә була ала. Озын заман эчендә булган һәлакәтләрнең эзләрен саклаган башка планеталарда бөек һәлакәтләргә кагылышлы күп кенә дәлилләр бар. Бөтен нәрсә вакыт микъдарына бәйле. Йөз ел эчендә булувы уйланылмаган бер һәлакәт, йөз миллион елда тормышка аша ала. Җир йөзенең хәтта йөз елы эчендә дә начар табигый һәлакәтләргә юлыгыла[3].***

Космостагы югарыда китерелгән сәбәпләрнең берәрсе генә дә аның һәлакатенә китерергә мөмкин. Аллаһтан башка бу һәлакатләрне һичкем дә туктатырлык түгел. Бигрәк тә искиткеч космостагы, Дөньядагы пропорцияләр турында фикерләсәк. Аллаһ тарафыннан Кыямәт Көнендә булачагы ирештерелгән вакыйгалар, бәлки дә Дөньядагы бөтен бу пропорцияләрнең бозылувы белән тормышка ашачактлар. Була алганча кимчелексез рәвештә эшләгән бу ситеманың бозылувы бер-бер артлы килгән һәлакәтләр белән тәмамлана ала. Кешеләр үзләреннән бу кадәр ерак дип белгән, хәтта лар тарафыннан барлыгы да ихтимал ителмәгән Кыямәт Көне, бәлки дә үзләренә бик якын.

## Дөньябызның үлеменә сәбәп була алачак ихтималлар

Дөньяның барлыгын дәвам итүве өчен космоста бар булган сансыз шартларның бурүк вакытта һәм берүк формада бар булувы кирәк. Бүген күп кенә галим бу нечкәлекләрнең һәм пропорияләрнең бозылувы өчен ниләр эшләнергә тиешлеген өйрәнә. Кечкенә генә үрнәк бирергә кирәк булса: галимнәр һәм экология саклаучы оешмалар бары бензин, күмер кебек җир асты ягулыкларының кулланувы нәтиҗәсендә килеп чыккан экономик һәм экологик проблемаларның да хәтта киметелә алмаячагын белдерәләр. Үз тармакларында профессиональ булган кешеләрнең темасы буларак саналган һәм ягулык куллану нәтиҗәсендә катастрофалар булачагына кискен буларак караучылар һәм хәтта бик якын даталар билгеләүчеләр тарафыннан белдерелгән һәлакәт сценарияләренең

кайберләре:

**Ганга һәм Нил кебек Дөньядагы иң зур елгаларның дельталары су астында калачак, Кытай елгаларының дельталары белән Бангладеш туфракларының дүрттән берен сулар каплаячак.**

**Мальдив утраулары белән берлектә Океандагы утраулар һәм утраулардагы дәүләтләр суларга күмелеп юк булачаклар.**

**Бөек игенчелек территорияләре (АКШның "Middle West" территориясе, Аурупа һәм Казахстан) чүлгә әвереләчәк. Төркия Сахра чүле кебек булачак.**

**Югары җирлекләрдәге туңган туфраклар (Себер һәм Канада кебек) эриячәк. Кайберләре торба юлларын, тимер юлларны һәм биналарны җимерәчәк.**

**Дөнья рельефындагы урман территорияләренең өчтән бере юк булачак. Дөньяның үпкәсе саналган яшел территорияләрнең әзәюве атмосферадагы карбондиоксит микъдарының тагын да артувына сәбәп булачак. Бу да сера тәэсиренең артувына һәм төрле-төрле һава җитмәгәнлектән килүче сәламәтлек проблемаларына китерәчәк.**

**Тропик җирлекләргә хас тайфун һәм циклон кебек табигать һәлакәтләре күбәячәк. Аеруча океаннардагы суасты агышлары (Эль-нино, Гольфстрим) юнәлешләрен үзгәртәчәк һәм диңгез климатларын астын өскә китерәчәк.**

**АКШтагы Техас штаты белән берлектә Аурупаның Урта Диңгез ярлыкларында лихорадка, малирия һәм охшаш чир эпедемияләре күреләчәк.**

**Альпалар һәм Гималай тауларында табигать бозлыкларының 25% эриячәк. ( Эрегән суның зарары исәп кылынганнан тагын да күбрәк булачак.) Эрегән бозлыклар күп кенә яр буе шәһәрләрнең су астында калувына сәбәп булачак, утрау дәүләтләре су астында калып юкка**

**чыгачак. Бу вакыйгалар шул җирлекләрдә яшәүче миллионнарча кешеләрнең үлеменә яки күчеп китүләренә китерәчәк.**

Болар тик көтелгән һәм гыйльми эзләнүләр нәтиҗәсендә билгеләнгән янаулар. Дөньяда бу процес башланганнан соң инде аны туктатуның, Аллаһ теләгеннән башка, һичбер юлы юк. Бары 1997 елда гына атмосферада карбондиоксит газының 25 процентка артувы дөьядагы сера тәэсирен арттырып, планетар җылынуга юл ачты, котыблардагы бозлыклар эри башлады, эрегән боз таулары океаннардагы су дәрәҗәсен күтәрде, кыш һәрзаманныкыннан тагын да авыррак үтте, чамадан тыш явым-төшем, көчле штормнар күп кенә кешеләрнең һәлакәтенә китерде. Азон катламының тишелүве белән Дөнья зарарлы нурларга таб булды, рак авырулары күбәйде, яңа чирләр пәйда булды, үсемлекләрдә негатив үзгәрешләр табылды. “Greenpeace” (Табигатьне саклау оешмасы) һәм АКШ галимнәренең Аляскада үткәрелгән бер эзләнүләре нәтиҗәсендә Беринг бозлыгының буе 12 чакрымга кимегәнлеге, озынлыгының исә 130 чакрымга кыскарганы белдерелде. Диңгезләрнең температурасы 0,8 градуска артты, су Дөньясындагы яшәеш өчен кирәкле булган билгеле бер балансны булдыручы кораллар үлә башлады һәм планктонның 80% юкка чыкты.

Соңгы берничә гасыр эчендә Дөньяның соңын китерә алырлык бик күп ихтималлар барлыкка килде һәм көн үткән саен бу ихтималларның саны тагын да арта бара. Хәзерге вакытта Дөньяда барлыкка килүче вакыйгалар индустриаль эчтәлекле һәм Дөньяның бер көне киләчәк шиксез соңын һәм бу соңның көн үткән саен якынлашканын күрсәтә. Аеруча физик галимнәре үзләренең хафалануларын дәвамлы буларак шулай белдереп килә:

***“Әгәр космос чикләнгән бер тәртип төзелешенә ия исә һәм тәртипсезлеккә таба туктый алмыйча – соңында термодинамик тигезлеккә – бара икән, ике бик тирән коега таб булачак . Элегрәге , космос соңында каты-каты җимерелеп, үзенең энтропиясе эчендә үләчәк. Бу физик галимнәре арасында космосның “җылылык үлеме” буларак беленә. Икенчесе, космос гел бар булган була алмый, шуның өчен чикле без заман алданрак пропорциясе соңгы дәрәҗәгә ирешкән***

***булачак. Нәтиҗә буларак: Космос мәңге бар булмаган.***

Шаккатырганы, үлемнең бу дәрәҗәдә якын булувы хакыйкатенә карамастан, әле дә җир йөзендә үзенең соңы турында уйланмаган, Аллаһтан курычакрымаган һәм көчле иттереп Дөньяга бәйләнгән, бирелгән күп кенә кешенең барлыгы. Һәм тагын шаккатырганы, үлем хакыйкате хәтерләтелгәндә һәм бу авырлыклы көн нечкәлекләре белән аңлатылганда кешеләр купчелегенең, бернигә дә карамыйча, бөтен бу нәрсәләрне үзләреннән бик еракларда дип күрүләре. Иң башта Көрьән аятьләрен кире какканлыкларыннан, Кыяматкә кагылган тасвирлаулар алар өчен берни аңлатмый. Бу кешеләр һич үлмәячәкләр һәм Дөньяда мәңге калачаклар кебек хәзерлек кылалар, бер мизгелдә соңын табачак гөмерләре өчен мәңгелек тормышларын куркынычлыкка аталар. Югыйсә, кеше үзеннән әллә кайлардан качырга тырышкан үлем, шиксез аны табачак. Ни кешенең, ни космосның үлеме каршысында берәр качу юлы яки күреләчәк берәр чара юк. Бу ачык хакыйкать Көрьән аятендә шулай белдерелә:

***Әйт ки: " Әлбәттә, сез үзеннән качкан үлем, шиксез, сезнең белән каршылашачак. Соңында беленмәгәнне дә, шаһит була алынганны да белүчегә (Аллаһка) кайтарылачаксыз. Ул да сезнең кылганнарыгыздан хәбәр бирәчәк". (Җомга сүрәсе,8)***

Күрелгәнчә, шиксез рәвештә Дөньяның бер көнне юк булачагы берәр инану гына түгел, ә физик бер хакыйкать. Бу бетүне хәзерләгән сәбәпләр берәр-берәр үзләрен күрсәтә, фәннең алга китүве белән бергә уртага салына. Кешеләрнең бер өлеше Аллаһның барлыгына ышанмауларына яки һәркайсы берәр дини инануга ия булмауларына карамастан, галәмнең качувы була алмаган бер бетүгә таба якынлавын теләр-теләмәс кабул итәргә мәҗбүр. Бу хәлдә, Кыямәт һәм Ахирәт аңлаешы тышында яңа бер аңлаеш пәйда була. Бу аңлаеш бигрәк тә куркыныч, чөнки мәгънәсе мәңге юк булуны аңлата. Галәм соңының якынлавын хәтерләткән галәмәтләр кешеләргә берничә альтернатива калдыра: инкяр итүчеләрнең кайберләренә күрә мәңге юк булу. Аллаһка ышанганнар өчен исә: йә мәңгелек газап яки мәңгелек нигъмәт....

## ЯБЫК ГАЛӘМ-АЧЫК ГАЛӘМ МОДЕЛЕ

Бинг Бангның кире кагыла алмаслык, күзәтүләр нәтиҗәсендә ия булынган фәнни бер теория булувында галимнәр бер фикердә. Аңа күрә , галәм чиксез тыгызлыктагы бер ноктаның боек бер шартлавы белән киңәеп таралувы нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Бу шартлау нәтиҗәсендә тизлек белән таралган, бара-бара киңәйгән һәм суынган космос бүгенге хәленә ирешкән.

Ләкин, бу киңәю тагын ни кадәр дәвам итәчәк? Бер матдәнең массасы ни кадәр күбрәк исә, аның тарту көче дә шул кадәр күбрәк. Бу хәлдә югары тарту көче киңәю тизлеген җиңәр. Киресенчә, тарту көче аз исә, бу көч киңәюне җиңә алмый. Галимнәргә күрә, әгәр космосның массасы билгеле бер күрсәткечтән артык икән, киңәю бер көнне туктаячак һәм космос үз эченә омтылып җимереләчәк. Бу “ябык галәм” моделе. Башка яктан караганда, әгәр космосның массасы билгеле бер күрсәткечтән кимрәк исә, тарту көче киңәю тизлеген җиңә алмаганлыгыннан, космосның киңәюве һич тукталмыячак. Бу да “ачык галәм” моделе.

### Космосның соңы : ачык яки ябык галәм

Элек тә белдергәнебез кебек, космос, Аллаһ тагын алдарак башка берәр сәбәпне вәсилә итмәгән хәлдә, йә ябылып тик бер ноктада тупланып яки һич тукталмыйча киңәеп юк булачак. Космосның ябык яки ачык , нинди модель белән соңын табачагын исәпләр өчен космостагы масса микъдарын белү кирәк.

Космосның массасын үлчәү бик авыр булганлыгыннан, галимнәр массасы урынына тыгызлыгын үлчәп караганнар. Чөнки космосның тыгызлыгы “критик тыгызлыкка” дигәнебез бер күрсәткечкә җитә икән, ия булганы тарту көче галактикаларның качу тизлеген җиңә ала. Шуның аркылы космос бөтен галактикаларны үзенә таба тарта ала. Ләкин тыгызлык критик бер күрсәткечкә ирешмәсә, киңәю тукталмыйча дәвам итәчәк. Чөнки бу тарту көче галактикаларның качу тизлеген җиңә алмас.

Бу күренеш күп кенә галимнәрне, космосның соңын өйрәнү ниятеннән , бик күп төрле эзләнүләр ясарга , сәгатьләрчә телескоплар янында галактик системалардан килгән нурларны анализ итүгә этәрде.

Моның өчен галактик системаларның тизлекләре, зурлыклары, яктылыклары, еракльклары хисапланып, космосның чын тыгызлык күрсәткече эзләнергә тиеш. Ия булынган беренче күрсәткечләр космоста булган әлеге тыгызлыкның критик тыгызлык күрсәткеченә бик тә якын булганлыгын күрсәткән. Ягьни космосның ябык булу ихтималы тагын да күбрәк икәнлеге билгеләнгән. Тагын да соңрак , 1986 елда бу эзләнүләргә Американың ике галиме : Эдвин Лор һәм Эрл Спилар кушылды. Алар тарафыннан меңнәрчә галактикаларны җентекләп алынган нәтиҗәләр космосның ябык булу ихтималын 90% ирештерде.

Аеруча , бу 90% лык ихтималны тәшкил иткән тыгызлык хисапланган вакытта игътибарга алынмаган күп кенә деталь бар. Үрнәге, яктылык таратмаган кара тишекләр космосның тыгызлык күрсәткече хисапланган вакытта һич тә күз алдына китерелмәгән. Шуңа күрә, космостагы тыгызлык күрсәткече кара тишекләрнең дә хисап ителүве белән бер микъдарга тагын да артачак. Соңгы елларда караңгы матдә буларак исемләнүче һәм бөтен галактиканы тулдырган, күз белән күрелмәгән матдәләрнең тыгызлыгын да боларга кушувыбыз белән уртада күрелгән табло, космосның киңәювен туктатып үзе эченә җимерелү ихтималын буласы иттереп күрсәтте. Һәм Др. Джон Гриббин бу стадияне шулай белдертте: “Ябык галәм моделе өчен уртага атылган дәлилләр хәзергә чаклы һич бу кадәр куввәтле булмаган иде” .

Ягъни бик тә критик бер яшьтә һәм пропорцияләрдә булган космос һәр мизгелдә юк булуга хәзер халәттә. Аллаһ Көръәндә Әнбия сүрәсенең 104 нче аятендә космосны ярата башлаган халәтенә кайтарачагын шулай белдергән:

***“Без күкне китап битләрен туплаган кебек туплаганыбыз көн. Элек ярата башлаганыбыз кебек яңадан аны иске халәтенә кайтарачакбыз. Бу Безнең өстебездәге бер вәгъдә. Әлбәттә, Без кылучылар”. (Әнбия сүрәсе, 104)***

Аять белән ябык галәм моделенә игътибар ителгән булу ихтималы югары. Моңа кадәр аңлатканнарыбыздан да күрелгәне кебек, фәнни күрсәткечләр дә космосның киредән кысыла алувы ихтималының югары икәнлеген күрсәтер. Шулай ки, хәтта материализм фикерен яклаучылар да ия булынган нәтиҗәләрнең кискенлеге каршысында яңа берәр кире кагу чарасы таба алмаганнар.

Чикаго Университеты Астрономия булеме Башлыгы Шерман элек галәмнең ябык булганлыгы фикеренең фәлсәфи һәм дини нигезләргә таянганын, ләкин хәзерге вакытта бу модельнең дөреслеген күрсәткән күп кенә теоретик һәм эксперементаль дәлилләр табылганлыгын белдерә .

Әйе, космосыбыз 15 миллиард ел киңәя бирә, фәкать чыккан нәтиҗәгә күрә, Аллаһ Катында заманы билгеле булган бер көндә, бөек ихтимал ки, тарту көче киңәюгә хаким булачак һәм киңәю тукталачак. Ашкан тыгызлыктан һәм ябык булган галәмдә тарту көче хаким хәленә килгәч, һәрнәрсә үз эченә омтыла башлаячак. Һәрнәрсә кире артка хәрәкәт иткәндә, ул заманга хәтле суынып киңәйгән космос тараеп җылына башлаячак, бөтен галактик системалар тизлек белән бер-беренә якынлашачак.

Бу модельгә күрә , бер көнне тарту көче галактикаларның киңәювен туктатачак һәм шул заманнан соң, бара-бара арткан бер рәвештә, галактикалар бер-берсенә таба хәрәкәт итә башлаячак. Галәмдә көчле бәрелүләр булачак, дәү күк җисемнәре бер-берсенең эченә керә, берләшә башлаячак. Ай, Кояш, Дөнья, бөтен планеталар һәм йолдызлар берләшәчәк, бара-бара кысылган һәм тарайган космос, яшәгән бу процес соңында тик бер ноктада тупланып юк булачак. Бөтен галәмнең системасы асты өскә китереләчәк. Дөнья орбитасында барлыкка киләчәк кечкенә генә бер кузгалуның бөтен җанлыларның янувына яки туңувына сәбәп булачагын, атмосферадагы кечкенә генә бер тишелүнең җанлыларга ни кадәр негатив тәэсир итәчәген, Дөньяның 23,27 янтаю градусында кечкенә генә үзгәреш булувы белән ел фасылларының булмаячагын беләбез. Шулай итеп, нечкә пропорцияләр белән корылган

тәртип системасының космосның кысылу процессына кергәнендә ни кадәр нигатив тәэсир алачагын исәпләү һич тә авыр түгел.

Аллаһ Көръәндә Кыямәт Көнендә Ай белән Кояшның берләшәчәген белдергән. Бу аятьләрдә ябык галәм моделена ишарәт итү ихтималы бар. Кысылу тормышка ашса, билгеле бер заман эчендә Дөньяның, Кояш системасындагы башка планеталарның , Айның һәм Кояшның бер-берсе белән берләшәчәге бик булачак нәрсәләрдән.

Тагын Көръәндә **“йолдызлрның урыннарыннан кузгалып түгеләчәге”** белдерелгән. (Тәквир сүрәсе,2). Бу аять тә шулай ук ябык галәм моделенә ишарәт итә ала. Чөнки бу ихтималда да йолдызлар үзләре ия булган орбиталарыннан чыгып бер урынга киләчәк. Кирегә таба тарайган космоста вакыт үлчәмнәре дә киресенчә булачак. Бу хәлдә, җир йөзендә күрелүве ихтимал булган вакыйгалар белән кара тишеккә керү стадиясендә күтелгән ихтималлы вакыйгаларның охшаш була алулары күренә. Чөнки һәрнәрсә кирегә таба хәрәкәт иткәндә, җирнең тарту көче дә киресенчә булыр, җир авырлыкларын тышка атар. Ни кадәр дәвам итәчәге билгеле булмаган процесс эчендә, Аллаһ Кыямәткә хас буларак Көръәндә тасвир иткән вакыйгалар тормышка ашар.

Кыска буларак шуны әйтә алабыз: ябык галәм моделе тормышка ашканда бөтен космос, тагын да алданрак белдергәнебезчә, тик бер ноктада берләшеп юк булачак.

Киңәйгән галәм моделе дә космосның котылышы димәк түгел. Бу модельның тормышка ашувы космосның башка вакыйгалар аша юк булачагын аңлата. Космос яратылган мизгеленнән алып дәвамлы буларак үзенең тыгызлыгын арттырган һәм җылылыгы абсолют нульгә бик якынайган. Галәмнең әлеге җылылыгы – 270 градус, бу җылылык абсолют нульдән бары 3 градуска гына югарырак. Җанлылар яшәеше өчен кирәк булган җылылык – 270 градус. Җылылыкның бу минуслы микъдардан 1 градуска аз яки 1 градуска күп булувы бөтен җанлыларның үлемен аңлата.[1] Космос киңәювен дәвам иткән саен бу температураның

үзгәрешсез калу ихтималы юк. Җылылык кимегәндә яки күтәрелгәндә кешелек һәлак булачак.

Соңгы вакытта үткәрелгән эзләнүләрдәге ачышлар ябык галәм моделенең тормышка ашу ихтималын уртага сала. Ләкин, галимнәр ясаган детальле эзләнүләр нәтиҗәсендә бердәм буларак кабул ителгән нәтиҗә: бу модельләрнең кайсысы тагын да чынга ашырлык булса булсын, космосның соңын үзгәртмиячәк. Ике модель аркылы да космос үләчәк, фәкать бу үлем төрле формаларда тормышка ашачак. Үткән бүлемнәрдә детальле буларак аңлатылганча, һәр ике модель дә Кыямәтне китерәчәк . Әмма, моның белән бергә Дөньяның соңын китерә алачак башка сәбәпләр дә бар. Боларның берсе Кояш гомеренең тәмамлануvы. Әлбәттә, һәрнәрсәнең иң дөресен Аллаһ белә.

### Кояш гомеренең тәмамлануvы

Беленгәнчә, космостан күк җисемнәре туар һәм билгеле бер заманнан соң үләр. Кояшыбызның да шундый чикле гомере бар. Космос ябык яки ачык модельнең берсе аркылы соңын табувыннан алда, Кояш үзенең гомерен темамлау ихтималы бар һәм актуаль. Кояш гомеренең тәмамлануvы исә, әлбәттә, Дөньяның да үлүвен аңлата. Исәпләргә карата, 5 миллиард яшендә булган Кояш һәр секунд саен 546 миллион тонна гидрогенны 560 тонна геллиумга әйләндереп, кире калучы миллион тонна мадәне энергиягә әверер.[11]

Кояшта гидрогенның янып бетү процессы башлангач, Дөньяның соңы килгән булачак. Бу процес вакытында мәркәз кысымнарында җыелма хәлендә булган гидрогенн урнына гелиум арта башлаячак, хәзерге вакытта 20 миллион градус булган Кояшның мәркәзе 100 миллион градуска күтәреләчәк. Шулай итеп , Кояшның мәркәзе бик кызган ялкынсу хәленә җитеп , тирә ягы да дәвам иткән саен шешүче тышкы кысымнардан формалашкан бер манзараны булдырып, Кояш та сары урынына кызыл төске керәчәк. Шулай итеп Кояш кызыл бер җисемгә әвереләчәк.

Галимнәр бу процесстан соң иң элек булачакларны шулай күрә: Дөньядагы яшәешнең җан тамыры булган Кояш, бик купкә зураеп шешәр

һәм тирәсендәге киң аланны биләп алыр. Соңрак тирәсендә булган планеталарга ут һәм ялкын ата башлар. Тышкы йөзе хәзергедән тагын да эссерәк булмавына карамастан, зурлыгы буенча бик эреләшкән өчен, якында булган планеталар бик күп иттереп тәэссирләнерл. Элек Меркурий, аннан соң венера Кояшның нурларыннан эрер.

Еш-еш белдергәнебезчә, җир йөзендә җанлылар яшәешенең дәвамы барытик космоста бар булган бик күп тигезлек-пропорцияләр саклануына бәйле. Үрнәге, Дөнья Кояшка хәзерге еракльгыннан бераз тагын да якын булувы бөтен җанлы тормышының янып пешүве өчен җитәрле. Шул сәбәпле, Кояш шешә башлагач, әле Дөньяга җиткәнче, Дөньядагы система бу үзгәрешләрдән бик артыгы белән тәэсирләнәчәк. Кояш Меркурий һәм Венераны яккан процесс вакытында, Дөньяның да , әлбәттә, бөтен тәртип – пропорцияләре бозылган булачак. Бу халәттә Дөньядагы яшәештән сүз итүве мөмкин түгел. Бер вакыттан соң Кояш тараткан бу җыелма нурлар аркылы башта океаннардагы сулар ашкан эсселектән парланачак, таулар, ташлар бер мизгелдә эреп газ хәленә киләчәк. Бөтен Дөнья күз ачып йомганчы үткән кыска бер вакыт эчендә янып, бетеп кулга сыярлык микъдардагы тузан хәлендә галәмгә таралачак. Бу Дөньябызның соңы. Галимнәр бу нәтиҗәгә Кояш зурлыгындагы йолдызлар өстендә үткәрелгән эзләнүләр, күзәтүләр аркылы ирешкән. Бездән еракта булган күп кенә йолдыз тасвир кылганыбыз кызыл гигантка әверелә. Кызыл гигантның үз тирәсенә ясалган тәэсире сәбәпле галәмдә һәр мизгел саен масштаблы вакыйгалар яшәлә.[12]

Башка галим Кояштагы энергиянең азалувына шулай ишарәт итә:

***“Кояшка килгәндә, билгеле гел кәефле-кәефле янувын дәвам итмәячәк. Елдан елга ягулык резервы азала, шулай ки, соңында суыначак һәм туңачак. Шундый симптомлы Кояш уты аны барытик чикле заманага хәтле генә тотып кала алачак, ул бетмәс энергиягә ия түгел”.*** [13]

Бу халәт бетү белән нәтиҗәләнә алырлык ихтималларның тик берсе генә. Бу вакыйгаларның табигый нәтиҗәсендә Кояштан киләчәк

булган һәлакәт - качу мөмкинлеге булмаган бер соң. Ләкин үткәрелгән эзләнүләр Дөньяның соңын хәзерли алачак тагын да бик күп фактлар булганлыгын күрсәтте.

### Күк ташлары

Беленгәнчә, космоста һәр мизгел хәрәкәт хәлендә булган эрелеваклы миллионнарча күк ташлары бар. Боларның берәр планета яки йолдызга бәрелүве нәтиҗәсендә барлыкка киләчәк тәэсир күк ташының зурлыгына күрә үзгәрә.

Галимнәр белдергәнчә, һәр елны 10 миллион тоннадан артык күк ташы Дөньяга төшә, ләкин атмосфера кергәч , ышкылу тәэсиреннән Дөнья йөзенә төшкәнче күбесе көлгә әверелә. Башкача әйткәндә, атмосфераның саклаучы функциясе сәбәпле Дөньябыз һәркөн яшәлә алган һәлакәтләрдән саклана. Әммма, алдагы бүлемнәрдә тагын да детальле буларак аңлатылачагына күрә, күк ташлары арасында Дөньядагы яшәешкә соң китерә алырлык зурлыктагылары да бар.

Шулай ки, элегрәк Дөньяга төшкән кайбер күк ташлары Дөньяның геологик һәм экологик торышында мөһим үзгәрешләргә сәбәп булганлыгы беленә.

Боларның берсе 20 нче гасыр башында Себердәге Тунгускага төшкән, 60 чакрым диамында булувы исәпләгән күк ташы. Бу күк ташы 2000 чакрымлык урманны юк иткән һәм Хирасимага атылган атом бомбасыннан мең кат артык шартлауга сәбәп булган. Әйтергә кирәк, бу территориядә һичкемнең дә яшәмәве көн кебек ачык булган һәлакәтне булдырмый калган. Исәпләүләргә күрә, шул ук таш мисал буларак Эйфель манарасы түбәсенә төшсә иде, ун миллион кешенең юк булувына сәбәп булачак иде[1] .

Дөньяга тирәнтен буларак тәэсир итә алырлык һәлакәт ихтималларының ни дәрәҗәдә бөек була алганлыгын күрсәткән Тунгус астероедының Дөньяга бәрелүве белән барлыкка килгәннәр шулай искә алына:

***“1908 нче елның 30нчы июне. Иртәнең иртә сәгатьләрендә Урта Себер күгендә күзәтелә торган олы ялкын йомгагы күренде.***

***Офыкта, ул кагылгын урында, бөек шартлау булды. 2000 чакрым урман территориясен җир белән бер кылды, меңнәрчә агачларны якты. Җир шарының тирәсен ике тапкыр әйләнгән атмосферик шок ятатты. Аның артыннан ике көн эчендә атмосферага шундый вак тузан таралды ки, вакыйга урыныннан 10.000 чакрым озаклыкка булган Лондон урамнарына төшкән яктылыкта газета авыр укыла ала иде".[1]***

Ул көннең дәһшәтен яшәгән кешеләр тарафыннан бирелгән бу һәлакәтнең ачыклаулары безгә күпмедер дәрәҗәдә булачак һәлакәтләрне күзаллар өчен ярдәм итә:

***"Өемнең өй алды баскычында идем. Иртәнге аш заманы иде. Төнъякка карый идем. Бервакыт күк йөзе икегә буленде... Һәм урманның төнъяк булемендәге күк утлар эчендә иде. Ул вакыт күлмәгемнең бер тарафы яна башлаган кебек бер эсселек хис иттем үземдә.... Ул вакытта күлмәгемне салып атырга теләдем, әмма ул мизгелдә күктә бер көчле тавыш купты. Өй алды бакчасыннан берничә м ераграк җирдә егылган булганымны абайладым. Күпмегәдер хушымнан яздым. Хатыным чабып килеп мине виллага күчерде. Көчле тавыш артыннан күктән яуган ташлар тавышлары кебек яки пуля тавышлары кебек тавышлар килде. Җир тетрәде. Җиргә егылган вакытымда өстемә таш төшүвеннән курыкканым өчен башымны кулларым белән капладым. Ул вакытны күк ярыгында, кайнаган сыман җил, шартлаган туптан чыккан кебек төтен өлешләре исте. Җил искәндә туфракның өстендә дә эз калдыра иде".[1]***

Калганы, киләчәктәге дәү күк ташларының кая төшәчәге билгесез. Галимнәргә күрә, "Тунгус астероеды" зурлыгында булган астероидлар Дөньяга һәр ике йөз елда бер бәрелә. Бу да шундый бер һәлакәтнең ни дәрәҗәдә якын булганлыгын күрсәтә. Өстәвенә, алда киләчәк күк ташы бәреләчәк урынның яшәү мәркәзе булмавы өчен дә бер сәбәп юк. Тормышка ашачак бу бәрелешнең тәэсире ни дәрәҗәдә булачагын хәзерге көндә галимнәрне хафага сала:

***"Әгәр бүген шундый бер бәрелеш булса, ул мизгелдәге паника***

***сәбәпле берәр атом бомбасы шартлавы дип кабул ителүве мөмкин. Кометаның бәрелү тәэсире һәм ялкын йомгагы бер мегатонлы төш бомбасы шартлавының бөтен тәэсирләрен барлыкка китерә ала. Моның эченә гөмбә сыман күтәрелгән болыт та керә. Ләкин, шундый аерма белән ки, гамма нурларына һәм радиактив атылмаларга сәбәп булмаячак.”[1]***

Бу масштабтагы массаның берәр шәһәргә төшүве миллионнарча кешенең үлүвен аңлата. Диңгезгә төшү ихтималы да шундый ук зурлыктагы януны үз эчендә саклый.. Астероидның массасы һәм тизлеге диңгез өстендәге дәү дулкыннарга сәбәп булачак һәм барлыкка килгән цунамилар диңгез яр буйларындагы яшәеш территорияләрен юк итәчәк. Тагын да уйландырганы, биргәнебез үрнәктән тагын да зуррак астероидларның һәм кометаларның Дөньяга бәрелү ихтималының бигрәк тә югары булувы. Тагын да зуррак бәрелешнең берәр материкны бөтенләй юк итүве һәм атмосфераны да бөтенлеге белән агу белән тутыруы кача алмаслык бер соң буларак карала. Моның бер ихтимал була алуы гына, бөтен Дөньяга тәэсир итәчәк һәлакәт булувы турында уйлану гына да җитәрлек дәрәҗәдә өркетүче. Күк ташларына каршы торачак чара эзләнелүвенә карамастан, бүгенгә кадәр табылган һәр методларның җитәрле түгел икәнлеген галимнәр һәр форсатта белдертеп килә.

## Күк ташлары һәм кометалар белән бәйле ихтималлар

Галимнәр космаста табылган күк ташларының Дөньяга бәрелү ихитмалларының көн үткән саен тагын да көчәюевен белдертә. Белфостагы Квинз университетыннан астроном Алан Фитзилманз Дөньяга бәрелү юнәлешендә хәрәкәт итүче зур күк ташлары барлыгы турында ачык дәлилләр булганлыгын белдерткән һәм төшенчәләрен: **“Боларның безгә бәрелүләрен көтәбез. Бәреләчәкләрен беләбез. Бу барытик вакыт месьәләсе”, -** дип ачыклаган.[1]

Һәр елны Дөнья атмосферасына кергән 10.000 тоннадан артык күк ташы атмосферабыз сәбәпле безнең хәбәребез дә булмаган хәлдә эри. Ләкин, бу күк ташларның атмосферада эремәячәк кадәр зурлыкта булганнары да бар.

Вальтер Альвадез “T. Rex and Creftor of Doom” (“Т. Рэкс һәм Кыямәт Көненең Яратучысы”) исемле китабында комета яки берәр күк ташының Дөнья атмосферасына керү вакытында була алырлык вакыйгаларны шулай аңлата:

***“Комета пычрак боздан формалашкан шар һәм ул Кояшның җылылыгы сәбәпле парланып газларын ата. Һәм Кыямәт Көнен тетри-тетри яктылык сипкән берәр йолдыз хәбәр итә ала. Бу йолдыз хәтта көндез дә күреләчәк, кичне дә яп-якты кылачак. Бу вакыйгага комета урынына берәр астероид та сәбәпче була ала”*** [1]

Галимнәр тарафыннан моннан 65 миллион ел элек Дөньяга бик тә зур җисемнең төшүве исбат ителде (иң бөек ихтимал буенча бу җисемнең комета икәнлеге фараз кылына) һәм бу күк җисеменең җир йөзендәге бик зур үзгәрешләргә сәбәпче булганлыгын белдерделәр. Моннан соң һәм тагын да элегрәк төшкәнлеге исбат ителгән башка күп кенә күк җисемнәренә таянып, Дөньяга шундый берәр җисемнең бәрелүве нәтиҗәсендә барлыкка килә алачак ихтимал вакыйгалар фараз кылына..

Берәр кометаның бәрелүвеннән алда хәрәкәтеннән таралган энергия 100 миллиард мегатонлык ТНТга тигез. Бу микъдар кометаның 1 секунд эчендә парга әйләнүвенә һәм 40 чакрым тирәнлектәге кое барлыкка китерүвенә сәбәп була. Чагыштыру ясасак, бер гидроген бомбасы ни бары 1 мегатон ТНТдыр һәм “Суык сугыш” заманында Дөньяда бу төр кораллардан 10.000 данә бар иде.

Кометаның көче исә, Дөньяның бөтен корал саклау ханәләрендә булган кораллардан тагын да артыграк шартлауга тигез.

Көръәндә Кыямәт Көнендә бик көчле тетрәүләр булачагы, һәрнәрсәнең җир белән тигезләнәчәге, диңгезләрнең ташачагы белдерелгән. Комета яки зур күк ташының Дөньяга бәрелү ихтималы, Көръәндә булган бу вакыйгаларның берәр-берәр яшәләчәгенә сәбәпче була ала. Сисмик дулкыннар сәбәпле диңгез астында дәү ишелүләр формалаша, моның нәтиҗәсе дә цунамиләр (дәү дулкыннар). Элекке заманнарда барлыкка килгән сисмик дулкыннар аркылы барлыкка килгән

цунамиләр шул хәтле зур булганнар ки, галимнәр бу цунамиләрнең диңгез төбендә каналлар ачканын белдерә.

Шулай ук, үткәрелгән эзләнүләр бер вакытларры Мексика култыгы ярларына бәрелгән бер җисемнең тәэсире аркылы бик тә бөек цунамиларның барлыкка килгәнен уртага куйды. Флоридага юнәлгән цунами тагын да бөеклеген арттырып, яр буйларында бөек куркынычлык тудырган һәм урманнарны юк иткән. Бүген бәлки кешеләрнең купчелеге шиксез каршыланачак үлем һәм Кыямәтне акылларына да китермичә яши бирә. Югыйсә, Дөньяга шундый берәр һәлакәтнең төрле-төрле юллар аркылы килмәве өчен һичбер сәбәп тә юк. Үрнәге, югарыда аңлатканыбыз вакыйгадан бер көн алда туфрак соңгы дәрәҗә уңышлы булган хәлдә, бәрелешү барлыкка килеп берничә сәгать үткәч, Мексика һәм Америка туфракларының купчелеге тәмам буларак уңышка яраксыз калган.[2]

Аллаһ безгә 14 гасыр элек Кыямәт Көнендә “күкнең зәгыйф булачагын” (Хакка сүрәсе, 16), “металл кебек эриячәген” (Мәариҗ сүрәсе, 8) белдергән. Бу вакыйгалар кометаның Дөньяга бәрелүве яки дәү берәр күк ташының җир йөзенә төшүве нәтиҗәсендә барлыкка киләчәк манзара белән бик охшаш.

“The Last Three Minutes” (“Соңгы өч минут”) исемле китабында Паул Дэвис Дөньяга бәреләчәк кометаның тәэсирен аңлатканда, күк йөзе югарылыкларыннан бик зур бер яктылык нурының күкләрне яндыра башлаячагын һәм металл кебек эретәчәген белдерә. Китапның шул ук бүлемендә Паул Дэвис космос эчендә барлыкка килгән вакум сәбәпле кайнаган газның өермә формалаштырачагын белдерә. Бу ачыклау Рахман сүрәсендә булган бер аять белән бик охшашлыклар күрсәтә:

***Соңыннан күк ярылып, май кебек эрегән кып кызыл бер гөл булган вакыт. (Рахман сүрәсе, 37)***

Күкнең эреп агувы, эрегән май яки эрегән металл кебек кызган сыекчаны хәтерләтә. Шулай ук, шундый халәттә күкнең кызган һәм яктылык бирү хәленә киләчәге, ягъни кызган һәм кызгыл төскә керәчәге беленә. Паул Девис белдергәнчә, ул көнне кайнаган газ өермәгә әверелергә

мөмкин. Мондый нәрсәнең кып-кызыл гөлгә ни дәрәҗәдә охшаш булачагы ачык.

Аллаһ Үзенең Катында билгеләгән бер заманда кешеләрне Кыямәт Көне белән каршылаштырачак һәм Көрьәндә белдерелгән бөтен вакыйгаларны бер-берәр тормышка ашырачак. Ләкин, аңлатылганнардан да күрелгәне кебек, Кыямәтне барлыкка китергән вакыйгаларның бу сәбәпләренең берсе яки бөтенесе белән берүк вакытта булачагы зур ихтималлар дәрәҗәсендә.

Моңа охшаш вакыйгалар үткәндә дә булган. Һәм күк ташлары һәм кометалар Дөньябызга кайвакыт локаль, кайвакытта да бик киң аланнарга таралган зарарлар биргәннәр. Алдагы очрашуның ни заман булачагын барытик Бөек Раббыбыз Аллаһ кына белә.

Галимнәр 2028нче елда Дөньяның бик якыныннан үтәчәк күк ташының океанга төшү ихтималында, Америка һәм Аурупаның сулар астында калачагын, җиргә төшсә, тагын да зуррак һәлакәтләрнең яшәләчәген белдергәннәр. Күк ташының атмосферага керүве җир тетрәүләренә һәм янартау шартлауларына юл ачачак, барлыкка килгән тузан болытлары да Дөньяны караңгылыкта калдырачак. Астрономнар шундый күк ташының хәтта Дөньяга якынаювын гына да, бик тә бөек куркыныч барлыкка китерәчәгенә игътибар итәләр.[21]

Шулай ук, галимнәр 1993 нче елны Дөньябызның бик якынынан үткән Свифт-Тютл исемендәге бер комета турында сүз йөртә. Бу комета 2126 елны тагын көтелә. Ясалган хисаплар бу кометаның Дөньяга бәрелү ихтималын бик тә югары булганлыгын, ни бары ике атналык бер дистанция белән Дөньяны үтәчәген уртага салган. Бу бик тә якын дистанция. Һәм күп кенә галим бу якын дистанция сәбәпле бик борчыла. Бу җисемнәрнең орбиталарындагы тәртипсезлекләр Кояш Системасы эчендә дәвамлы трафик барлыкка килүгә сәбәп була. Бу да әлбәттә һәм Дөнья һәм дә башка планеталарга дәвамлы янау булганлыгын аңлата. Галимнәргә карата , иртә яки соң да булса Свифт-Тютл яки аның кебек берәр күк җисеме Дөньяга бәреләчәк. Бу объектларның кайберләре бөтен Дөньядагы атом коралларыннан тагын да күбрәк зарар китерәчәк

дәрәҗәдә. Ни бары бу вакыйганың ни заман булачагы гына билгеле түгел.

Паул Дэвис: **“Комета бәрелгәннән соң кешелек тарихында күтелмәгән һәм үрнәге булмаган соң барлыкка киләчәк”, -** диеп теманың әһәмиятенә басым ясый һәм **“барлыкка киләчәк бәрелешнең кешелекне юк итә алачагын”** сөйли. [22]

“The Last Three Minutes” исемле китабында бу темага бик урын бирүче Паул Дэвис, 21 нче август 2126 елны Свифт-Тюттлның Дөньяга бәреләчәген һәм ул көннең Дөньяның соңгы көне булачагына басым ясый. Язучының аңлатканнары белән Көръәндә Кыямәт Көнендә булачак вакыйгалар бер-берсенә бик якын. Паул Дэвис ул көнне шулай тасвирлый:

**“21 август,2126 .**

Соңгы Көн

***Комета кечкенә башы белән көчле харап итүче көчен саклый кебек. Дөньяның өстенә 1 секунд сәгатенә 40.000 миль тизлек белән 10 триллион тонлы боз һәм кыя массалары якыная. Тавыш тизлегеннән 70 мең тапкыр артыграк бәрелеш барлыкка киләчәк.***

***... Диңгез дәрәҗәсеннән алып (нуль дәрәҗәдән алып) күк йөзе ярылып ачылыр. Меңнәрчә килом кубындагы һава шартлаячак. Бер шәһәр киңлегендәге сап-сары ялкын 15 секунд эчендә Дөньяга төшә башлар. Планета, ягъни Дөнья 10 мең җир тетрәвенә тотылган кебек селкенә башлар. Хәрәкәт итүче һава дулкыны Дөнья өстендәге һәрнәрсәне себереп ташлар, бөтен корылмаларны тип-тигез итәр. Бәрелеш тәэсире аркылы барлыкка килгән кратерга Дөнья эчендәге нәрсәләр түгелә башлар. Эрегән кыялардан формалашкан дивар дулкынланып , авыр хәрәкәтләр белән чайкала башлар.***

***Кратер эчендә триллионнарча тонн кыя парга әйләнер. Бер өлеше һавага чәчрәр һәм күпчелеге космоска таба атылыр. ... Һаман бер өлеше йөзләрчә, хәтта меңнәрчә миль ераклыктан материкның яртысына иңәр өчен югарыда. Астагы һәрнәрсәгә бөек юк булу***

***китерәчәк. Эрегән атылмаларның бер өлеше океанга агып, цунамиларның барлыкка килүвенә сәбәп булыр. Тузанлы атылмалар атмосферага таралып һәм Дөньяның тирәсен каплап, кояш яктылыгы ирешүвенә комачаулар. Кояш яктылыгы урынына миллиардларча метиоридның яктылыгы таралыр. Бу яктылык югары температурасы белән җирне яндырыр.”*** [23]

Бу беленгәннәр, шиксез, һич тә ерак түгел. Моңа сәбәп булачак бары бер комета гына һәм шундый кометаның ни заман Дөньяга бәреләчәге билгеле түгел. Кыямәт, кешеләр ни кадәр кабул итәргә теләмәсәләр дә, каршыларына һич тә ерак булмаган ихтималлар аркылы чыга ала. Көръәндә бу мөһим хакыйкатъ турында хабәр бирелә. Аятьтә белдерелгәнчә, шиксез булган Кыямәт сәгате бара-бара кешеләргә якынлашып килә.

***“Күкләрнең һәм җирнең гаебенә (беленмәгәненә) Аллаһ ия. (Кыямәт) Сәгатенең әмере дә барытик (тизлек белән) күз ачып йому кебек яки тагын да якын. Шиксез, Аллаһ һәрнәрсәгә көч җиткерүче. (Нахл сүрәсе, 77).***

## Космостагы кара коелар

Бүген күп кенә галактикаларның мәркәзендә дәү массалы кара коеларның булганлыгы фаразлана. Ия булганнары куркыныч тарту аланнары белән тирәләрендә булган һәрнәрсәне йотучы бу космик дәүләр, үзләре җитештергән нурларны да хәтта кире тартырлар. Тирәләрендәге булган һәрнәрсәне йоткан саен тарту көчләре артыр. Үзләреннән кат-кат зуррак йолдызларны, планеталарны, кечкенәрәк кара коеларны, хәтта галактикаларны да тарта алалар. Бу сәбәпле кара кое бара-бара шешәр, инде тагын да киңрәк аланга тәэсир итеп, тирәсендә булган һәрнәрсәне йотар.

Дөнья космостагы иксез-чиксез бушлык эчендә тизлек белән хәрәкәт итә. Шуның өчен, Дөньяның бу соңсыз бушлык эчендә шундый берәр кара кое тәэсирендә эләгүве бик ихтимал.

**Кара кое ихтималы**

Кара кое һәрнәрсәне эченә тартучы, бик тә тыгыз булган барлык. Кара коеларның тарту көчләре бик югары. Шул сәбәпле, кара коеларның тарту аланнарына кергән һәркайсы берәр җисемнең бу тарту көченнән кача алу ихтималы юк.

Кара кое тузан суырткычның шлангы кебек тирәсендә булган һәрнәрсәне эченә тарта. Тоннарча авырлыктагы массаларга ия булган планеталар һәм аларның юлдашлары, күк ташлары, хәтта йолдызлар да кара коеның тарту көченә каршы тора алмый. Бер тапкыр кара коеның тарту аланына кергәннән соң, инде һич тә кире кайту юлы юк.

Нигә кара кое үз эченә кергән һәрнәрсәне тартыр ?

Беленгәнчә, һәр җисемнең билгеле тарту көче бар. Үрнәк буларак Дөньяның тарту көчен китерә алабыз. Берәр ташны һавага аткан булсагыз, таш үзенең ату тизлегенә бәйле булып бераз күтәрелгәннән соң, җирнең тарту көче сәбәбеннән кире җиргә төшәр. Берәр җисемнең Дөньяның тарту көченнән котылувы өчен билгеле тизлектән зуррак булувы кирәк ки, бу тизлеккә “качу тизлеге” диелә. Үрнәге, берәр ракетаның бераз күтәрелгәннән соң кире төшмәве өчен качу тизлеге белән хәрәкәт итүве кирәкле. Дөньяның качу тизлеге секундына 11.2 чакрым. Шуның өчен ракетаның космоска китә алувы секундына 11.2 чакрым тизлек белән хәрәкәт итүвенә бәйле.

Кара коенын качу тизлеге яктылык тизлегеннән дә артыграк. Кара коеның тарту аланына кергән берәр җисемнең аның тарту көченнән котыла алувы өчен яктылык тизлегеннән артыграк тизлек белән кара коедан ерагаювы кирәк. Ләкин, һичбер җисем дә яктылык тизлеген аша алмый һәм шул сәбәпле кара коеның тарту аланыннан да котыла алмаслык дәрәҗәдә. Шулай ки, секундына 300 000 чакрым югары тизлек белән хәрәкәт иткән яктылык өлешчәләре дә хәтта, кара коеның тарту көченә каршы тора алмыйлар. Шуның өчен, хәтта яктылыкны да йотучы бу күк

җисемнәре гел караңгылыкта. Космоста искиткеч тизлек белән хәрәкәт иткән Дөньябызның бер көнне шундый берәр кара коеның тарту аланына кермәве өчен дә һич сәбәп юк.

Өстәвенә, Америкалы астраномнар Кояш системабыз аның эчендә урын алган безнең галактикабызның мәркәзендә дә, һәрберсе Кояш зурлыгындагы миллионнарча йолдызны йота алырлык һәм әле дә актив булган ике данә кара кое тапканнарын ачыкладылар.

“Америка Астраномия Җәмгыятенең” еллык җыелышында ачыкланган гыйльми рапортларга карата, кара коеларның берсе галактикабызның нәкъ мәркәзендә, Дөньядан 26 000 яктылык елы, ягъни 9.6 триллион чакрым ераклыкта урнашкан. “Sagittarius A” (A-Star) исеме бирелгән кара кое каплаган күләм безнең Кояш системасы зурлыгында, ләкин массасы миллионнарча тапкыр тагын да артык. Хисапларга карата, 2.6 миллиард Кояш массасына тигез булган бу кара кое тирәсендәге йолдызларны секундына 965 чакрым тизлек белән узенә таба тарта. Шиксез, бу бик мөһим алга барыш һәм шулай ук бөек куркыныч та. Галактикабызның нәкъ менә уртасында шундый куркынычлыкның бар булувы, Дөньяга янаган кара кое куркынычлыгын нинди масштабларда булганлыгын күрсәтә.

Дөньядан 40 000 яктылык елы ераклыгындагы башка диск рәвешендәге “Old Faithful” исемле икенче кара кое күпке зуррак. Бу кара кое тирәсендәге йолдызларны,туя алмаган җанвар кебек, дәвамлы буларак йота бара.

A-Starның секундына 965 чакрым кебек югары бер тизлек белән тирәсендәге йолдызларны тартувы, бу кара коеның бу йолдызларны йотканнан соң тарту көченең тагын да артачагын күрсәтә. Шулай итеп, тирәсендә булган җисемнәрне тагын да артыграк тизлек белән тарта башлап, мондый процессның ахырында инана алмаслык тарту көченә ия булачак.

# КЫЯМӘТ КӨНЕ

Элегрәк аңлатканыбызга күрә, кара коелар яктылык өлешчәләрен дә йотарлар. Шул сәбәпле иң алдынгы телескоплар аларны якынайтканда да күренмиләр, беленмиләр. Шулай итеп табылулары һәм барлыкларыннан имин була алу өчен күп кенә эзләнүләрнең һәм үлчәмнәрнең ясалувы кирәк. Галимнәр тапкан кара коеларның барлыкларын төрле ихтималлар аркылы үлчәмнәр исбат иткән. Хәзерге вакыттагы эзләнүләрнең җитәрсезлеге сәбәбеннән барлыклары исбатланмаган тагын күп кенә кара коелар бар булувы ихтималы бик тә көввәтле.

Шулай ки, бүген күп кенә галим Кояшның бер ише булганын һәм бу йолдызның соңыннан кара коега әйләнгән була алувын билгелиләр.Бу исәпнең сәбәбе дә, галактикабызның бөтен йолдызларның икеле, өчле, бишле группалар хәлендә булувында. Кояшның ялгыз йолдыз булувы күп кенә галимне аның ише булып, соңыннан кара коега әйләнгән булу ихтималы турында уйландыра. Бу ихтималны көчләндергән дәлилләр азымсынмаслык кадәр күп. Бу теория бүген җентекләнә, фәкать Кояшның Дөньябыздан нибары 150 миллион ераклыкта гына булганы турында уйлансак, мондый ихтималның Дөньябыз өчен ни дәрәҗәдә бөек куркынычны аңлатканы ачык килеш уртада. Кычкасы, безнең хәбәребез булмаган бер мизгелдә Дөньябызның һәркайсы берәр кара коеның тарту аланына кермәве өчен һичбер сәбәп тә юк.

Бүген күп кенә галим Дөньяның ихтимал буларак кара коелар тарафыннан йотылган рзвештә юк булачагын исәпли. Дөнья хәтта мондый берәр кара коеның эченә кермәсә дә, кара коеның эчендә булганыбыз системаның якыныннан узувы гына да көввәтле һәлакәтләр ихтималы. Берәр кара кое сиздермичә генә Кояш системасына якынлаша башлаганда ниләр булыр !

Мондый күк җисеменең эчендә булганыбыз системаның якыныннан үтүве күп планеталарның орбиталарыннан чыгувына сәбәп була ала. Әлбәттә, моңа охшаш күп кенә вакыйга нәтиҗәсендә Дөньядагы бик күп пропорцияләрнең асты-өскә киләчәк. Йөзләрчә, меңнәрчә астероид мондый тарту көченнән тәэсирләнә ала. Болардан кара коега үзләре тартылганнар була алганы кебек, тартудан тәэсирләнгән йөзләрчә яки меңнәрчә күк җисемнәре Дөнья өстенә төшә ала.

## Галактикаларның бәрелүве

Бүген космоста безнеке кебек тагын 200гә якын галактика барлыгы һәм һәр галактиканың төзелешендә дә Кояшыбыз кебек 200 миллиард Кояш булганлыгы исәпләнә. Бу дәү күк җисемнәренең һичберсе дә тик буларак урыннарында тормыйлар. Һәммәсе дә үзтирәли әйләнә һәм дә билгеле юнәлештә хәрәкәт кыла. Мәсъәлән Дөнья эчендә булган галактиканың хәрәкәте сәбәпле “Solap Apex” исеме бирелгән орбита буенча “Вега” йолдызына таба бик тә югары тизлек белән хәрәкәт итә. Башка галактикалар да шундый рәвештә хәрәкәт итә. Өстәвенә, хәзерге вакытта космоста бөек бәрелешләр һәм дәү шартлаулар була. Дөньябыздагы кешеләрнең бу вакыйгалардан хәтта хәбәрләре дә юк.

Мисал өчен Америкадагы Хаббле телескопы Дөньядан 63 миллион яктылык елы ераклыгындагы урында булган бәрелешне фотога төшергән. NASAга җибәрелгән фотографияләрне җентекләгән галимнәр фотографияләрдә ике галактиканың бер-берсе белән бәрелешкәнен белдергәннәр. Бик җентекле һәм ачык буларак күренгән бу бәрелеш нәтиҗәсендә яңа күк җисемнәре, шул ук вакытта да килломлар буенча тирә якка таралган гидроген газы болытлары барлыкка килгән. Мондый берәр бәрелешнең Дөньяга якын урыннарда булган очрагында, бәлки шуның белән Дөньяның соңын билгеләүче сәбәпләрнең берсе тормышка ашкан булачак.

Өстәвенә, галимнәр Дөньябызны үз эченә алган галактикабызны да ихтималлы рәвештә шундый бер соң көткәнен белдерткәннәр. Бу тема белән бәйле хәбәрләрнең берсе шундый:

***“Астрофизикчылар Дөньябызның җитди һәм якын проблемалары булганлыгы турында сөйлиләр. Боларның берсе, булачак супернова шартлавы (супернова: бик якты хәлгә килеп, кайвакыт көндез дә күрелә алган йолдыз). Бу шартлауның кайда һәм кайчан булачагын әлегә ачык уртага салынган исбатлаулар биктә якты киләчәккә ишарәт итә һәм бик тә тынычландыручылардан түгел. Галимнәргә карата, Дөньядан якынча 430 яктылык елы ераклыкта булган дәү һәм кызыл төстәге “Betelguise” йолдызы***

***шартларга әзер хәлдә. Галимнәр белдерүве буенча, бу төр йолдызлар (гипернова), кара коеларның берләшүве яки бу кара коеларның нитрат йолдызлары белән берләшүләре нәтиҗәсендә формалашалар. Ләкин , беркем дә бу куркыныч бомбаларның космоста ничек таралган булуларын яки берәрсенең Дөньяга якынаювын да, соңыбызның ни булачагын да белми.” [2]***

Көрьәндә ул көнне Дөньяда көчле тетрәүләр булачагы, кешеләрнең бөек дәһшәт яшәячәге, Кояшның, Айның, йолдызларның каралачагы, һәрнәрсәнең тизлек белән юк булачагы белдерелгән. Шундый ихтималлы берәр бәрелеш нәтиҗәсендә бөтен бу санап үтелгәннәрнең бер мизгелдә тормышка ашкан вакытта, барытик Дөньяның гына түгел, ә бөтен Галактикабызның да моннан тәэсирләнәчәге ачык хакыйкать.

Күрелгәне кебек, ясалган гыйльми эзләнүләр дә безгә Аллаһ Көрьәндә вәгъдә иткән Кыямәтнең шиксез буларак бер көнне киләчәген күрсәтә. Көрьәндә белдерелгән рәвешле, җанлы-җансыз һәр барлык кебек Дөнья да бер көнне юк булачак һәм Аллаһ күкләрне һәм җирне юк иткәннән соң башка күк һәм җир яратачак. Әмма, Аллаһның моның өчен бер сәбәпкә дә ихтияҗы юк. Болар ни бары Дөньяның физик буларак та үлеменең була алачагын ачыклау өчен аңлатылган. Ләкин , шиксез, Аллаһ теләсә бүген яки дә иртәгә һичбер шартлау, бәрелеш һ.б. нәрсәләр булмастан Кыямәтне башлата ала.

Алда санап киткән ихтималлар җанлылыкның юк булувын китерә алырлык күп кенә башка ихтималларның барытик берничәсе генә. Дөньяның бу сәбәпләрнең берәрсе белән каршылашувы ихтимал дәрәҗәсендә. Ясалган эзләнүләр боларның була алувына ишарәт итә.

Космосны бара-бара киңәюве нәтиҗәсендә дә аерым бер үлем көтә. Кешеләрнең күпчелеге бу ихтималларны үзләреннән ерак күргәнлекләреннән яки болар турында уйлануны үзләреннән соң килүче нәселләргә калдыруны сайлаганлыкларыннан, бу һәлакәт

ихтималлары аларны борчуга салмас . Ләкин, Дөньяның юк булувы өчен болардан тагын да якынрак ихтималлар бар. Саналган бөтен ихтималлар арасында кайсысының Кыямәтне китерәчәген, кайсысының тагын да алданрак булачагын исә, шиксез, барытик Аллаһ белә. Кешеләр ни кадәр үзләреннән ерак күрсәләр дә, ясалган эзләнүләр һәм күз белән күрелгән һәлакәтләрнең артканлыгы бөтен боларның якынлыгын күрсәтә. Иң мөһиме дә, бөтен боларның булувы барытик Аллаһның рөхсәтенә һәм карамагына бәйле. Һәм әлбәттә, Аллаһ бөтен беленгән сәбәплардән тыш һич көтелмәгән һәм беленмәгән берәр сәбәп аркылы яки сәбәпсез буларак та Кыямәтне булдыра ала. Аллаһ бер аятьтә шулай боера:

***Ул күкләрне һәм җирне чыннан да Яратучыдыр. Ул "бул" дигән көнне (һәрнәрсә) булыр, Аның сүзе хак. Сурга өрелгән көнне хакимият Аныкы. Ул беленмәгәнне һәм шаһит була алынганны да белүче. Ул хөкем һәм хичакрымәт иясе, хәбәрдар булучы. (Әнъам сүрәсе, 73)***

Киләчәк бүлемнәрдә галимнәр тарафыннан шиксез буларак күрелгән ихтималлар һәм Көръәндә аңлатылган Кыямәт арасындагы охшашлыклар җентекләнәчәк.

**Аллах һәрнәрсәгә көч җиткерүче**

Галәм соңының ничек булачагы еллар буенча кешеләрнең акылын борчыган бер сорау. Кешеләрнең акылына бик күп сәбәпләр, була алырлык нәрсәләр килә ала, әмма Аллаһ теләгән вакытта мондый вакыйганың һичбер сәбәбе булмаган килеш, бер мизгелдә була алачагын онытмаска кирәк. Гыйльми эзләнүләр нәтиҗәсендә уртага чыккан ихтималлар, алар турында уйлануыбыз, барысы да ул Көн килгәнче Аллаһка юнәлүвебез өчен хәтерләтүче ролен уйныйлар. Аллаһ ни заман һәҗ ни рәвештә теләсә, ул авырлыклы көнне булдырачак. Иман иткәннәр Кыямәт Көненең Аллаһ Катында билгеләнгән бер вакыт булачагына шиксез буларак инаналар. Көръәндә Аллаһның һәрнәрсәгә көч җиткергәнлеге шулай ачыклана:

***...үзләренә вәгъдә иткәнебез нәрсәне аларга күрсәтербез ки, Без чыннан да алар өстеннән хаким итүчеләр. (Зухруф сүрәсе,42)***

Беленгәнчә, бүген булган тәртипнең бозылувы һәм Дөньядага җанлылыкның юк булувы өчен сансыз сәбәпләр бар. Өстәвенә, бу сәбәпләр заман үткән саен тагын да арта, җитди масштабларга кадәр зурая бара. Дөнья тизлек белән аның өчен билгеләнгән бетүгә таба хәрәкәт итә һәм моның өчен күп галәмәтләр бар. Кешеләрнең күбчелеге күрмәскә тырышса да, Кыямәт Көне тизлек белән якынлаша. Көръәндә бу хакыйкатькә шулай ишарәт итеlә:

***Шиксез, Кыямәт Сәгате якынлашып килә. Һәркем тырышканлыкларының каршылыгын алувы өчен. Аның хабәрен яшерәчәчакрымен. (Та-һа сүрәсе, 15)***

Бик күп галим барытик гыйльми билгеләр һәм эзләнүләргә генә таянып, шиксез буларак космосның бер көнне юк булачагында берләшә. Газета, журнал һәм телевизор кебек күп кенә информация тарату чаралары еш кына галимнәр эзләнүләренең нәтиҗәләреннән үрнәкләр бирәләр. Хакыйкатьне белгән бу кешеләр, Дөньябызга дүрт яктан якынлашучы һәлакәтләрне туктату һәм шулай итеп космосның үлемен соңландыру ниятеннән бөтен мөмкинлекләрне җентеклиләр, бу темалар белән бәйле җитди эзләнүләр үткәрәләр. Җентекләнүче башка нәрсә – бу ихтималларның тормышка ашканлыгында Дөньябызда барлыкка киләчәк физик үзгәрешләр һәм бу үзгәрешләрнең яшәешкә ничек тәэсир итүве. Үткәрелгән эзләнүләр нәтиҗәсендә уртага чыккан билгеләр һәм Аллаһ тарафыннан Көръәндә ул көндә булачагы белдерелгән вакыйгалар арасында бик күп яктан охшашлыклар бар икәнлеге күренде.

# КОСМОСНЫҢ ҮЛЕМЕ АРТЫННАН

КЫЯМӘТ Көнендә хакыйкать бөтен кешеләр тарафыннан күреләчәк. Инкяр итүче кеше тарафыннан киләчәгенә һич тә инанылмаган, хәтта бу инанмавы аркасында дәвамлы буларак кире кагылган һәм тормышы буенча аның турында уйланудан качылган Ахирәт хакыйкате белән хәзер инде ул кара-каршы. Дөньядагы ялгышының нәтиҗәсен күрә, кире кайту чаралары эзли, әмма берни дә булдыра алмый. Дәһшәтле соң белән каршылашып, кылганнарының үкенечен бөтен ачысы белән хис итә. Аларның бу психологик халәтләре безгә Коръәндә җентекле буларак аңлатылган.

Кыямәт Көнендә кешеләр «теләсәләр дә, теләмәсәләр дә» Аллаһ Коръәндә белдергән вакыйгалар белән каршылашканнар. Сурга өрелгәннән соң һич күрелмәгән вакыйгалар булып алган, җир һәм күк тар-мар ителгән, космос эчендәге җанлылар белән бергә юк булган. Һәрнәрсә юк булып, бөтен вакыйгалар булып беткәннән соң Аллаһ күкләрне, җирне һәм кешеләрне яңадан яратыр. Әлбәттә күкләрне, җирләрне һәм бөтен галәмнәрне яраткан Аллаһ, алар кебекләрне яңадан да ярата алырлык көчкә ия. Аятьләрдә бу хакыйкатьләр шулай белдерелә:

***Күрмиләрме? Күкләрне һәм җирне яраткан Аллаһ, аларга охшаш булганнарны да яратуга көче җитәр. һәм алар өчен үзендә шик булмаган бер вакыт (Әҗәл) кылган. Золым кылганнар исә, бары тик инкяр итүләре белән каршылык***

***курсәттеләр. (Исра сүрәсе, 99)***

***Алар күрмиләрме ки, күкләрне һәм җирне яраткан һәм аларны яратудан арымаган (Аллаһ), үлеләрне дә терелтер өчен көч җиткерер. Юк, чыннан да Ул һәрнәрсәгә көч җиткерүче. (Ахкаф сүрәсе, 33)***

Кыямәт Көнендә яшәләчәк (булачак) вакыйгалар нәкъ Аллаһ Коръәндә белдергәнчә - җирнең башка җиргә, күкләрнең башка күкләргә әверелүве булачак. Кешеләр Аллаһның хозурына чыгарылачак, Аның каршысында Дөнья тормышы буенча (дөньялыкта) кылганнарының хисабын бирәчәкләр.

***Җирнең башка җиргә, күкләрнең дә (башка күкләргә) әверелдергән көнне. Алар бер булган, каһһар булган Аллаһның хозурына чыга(рыла)чаклар. (Ибраһим сүрәсе, 48)***

Коръәндә бу авыр көн «Дин көне», «Хисап һәм Җәза көне», «Ахирәт көне» буларак исемләнә. Бу көнне яңадан яратылган күк һәм җир инде мәңгелек тормыш урыннары. Кешеләрнең бөтенесе дә яңа яратылыш белән киредән тереләчәк. Ул көнне инкяр иткәннәр белән иман иткәннәр бер-берсеннән бөтенләй аерылачаклар, мәңгелек йортларына ирештереләчәкләр. Инкар итүчеләр белән бергә һәркемне дә бу көн көтә бирә.

Иман иткән һәм Дөньядагы тормышлары буенча Ахирәт тормышына хәзерләнгән мөэминнәр, бүген яшәләчәк булганнарны алданрак Коръәндә үзләренә аңлатылган рәвештә табарлар.

Аллаһ тарафыннан үзләренә вәгъдә ителгәннәргә кавышуның рәхәтен яшәрләр. Инкяр итучеләр исә, тасвирланмас курку, үкенеч һәм борчылу эчендә. Дөнья тормышлары буенча теләк белән Аллаһ китергән системага каршы сугышкан вакытларында белдермәскә тырышсалар да, ялгыш кылганнарын белә иделәр. Алар тарафыннан онытылган бу хакыйкать инде каршыларында. Дөньяда туктамыйча «йә бу сөйләнгәннәр дөрес булса» дип уйландырып, бөек борчылу һәм курку яшәткән, шиккә салган хакыйкать белән хәзер

кара-каршы алар. Соңсыз (мәңгелек) тормыш буенча яшәләчәк, һич тә туктатыла алмаячак һәм үзләрен калдырмаячак бөек газапның беренче минутларын яши башлаганнар. Бакара сүрәсенең 28нче аятендә шулай диелгән:

***Ничек ки Аллаһны инкяр итәсез? Югыйсә үле булган хәлегездә сезне Ул терелтте, соңыннан сезне яңадан үтерәчәк, яңадан терелтәчәк һәм соңыннан Аңа кайтачаксыз. (Бакара сүрәсе, 28)***

## СУРГА ИКЕНЧЕ ТАПКЫР ӨРҮ ҺӘМ ДИН (ТЕРЕЛҮ) КӨНЕ

***Үзләренә гыйлем һәм иман бирелгәннәр исә диделәр ки: « Ант ки, сез Аллаһның Китабында (язылган вакыт буенча) терелү көненә кадәр яшәдегез; менә бу терелү көне. Ләкин сез белми идегез." Инде ул көнне золым кылганнарның акланулары да файда китермәячәк, (Аллаһтан) ризалык теләкләре дә кабул ителмәячәк. (Рум сүрәсе, 56-57)***

Тарих буенча яшәгән кешеләр Аллаһның һәм Ахирәтнең барлыгы белән уярылганнар, Аллаһ аларга җибәргән илчеләр аркылы хак булган дингә чакырылганнар. Ләкин Коръәндә белдерелгән буенча, кешеләрнең әз бер өлешеннән тыш, күпчелеге иман итмәгән, Аллаһ һәм илчеләренә каршы чыкканнар. Бу кешеләр улемнәреннән сон яңадан tереләчәкләрен көчле буларак инкяр иткәннәр. Коръәндә бу кешеләрнең инкяр итүләре шушы аятьләрдә хәбәр бирелгән.

***Бөтен булган антлары белән: «Үлгәнне Аллаһ терелтмәс», - дип ант иттеләр. Юк, бу Аның өстендә булган хак вәгъдә, ләкин кешеләрнең күбесе белмәсләр. Хаккында ихтилаф (төрле караш, фикер) иткәннәре нәрсәне аларга ачыклавы һәм инкяр итүчеләрнең үзләренең ялганчы булган икәнлекләрен белүләре өчен терелтәчәк. (Нәхел сүрәсе, 38-39)***

***“Әгәр сезнен кебек бер кешегә буйсынсагыз, ант ки, сез чыннан да хәсрәткә таб булганнардан булырсыз. Ул үлгәнегез, туфрак һәм сөяк хәленә килгән заманыгызда сезнең шиксез буларак (яңадан терелтелеп) чыгарылувыгызны вәгъдә итәме? Ерак, сезгә вәгъдә ителгән нәрсә ерак…Ул (бөтен хакыйкать), бары тик безнең (яшәгәнебез бу) дөнья тормышыбыздан гыйбарәт. Үлербез һәм яшәрбез, без терелтеләчәкләр тугел». (Мүэминүн сүрәсе 34-37)***

Инкяр итүләренең асыл сәбәбе – дөнья тормышын яшәләчәк бердәнбер тормыш буларак күрүләре. Бу ялгыш мантыкның аларга үлем белән юк булу фикерен акыллылык буларак күрсәтуве бик кызык. Яңадан терелүне дә бу сәбәптән кабул итмәсләр, Аллаһ Коръәндә хәбәр биргән вакыйгаларны һәм Хисап Көнен кире кагырлар. Югыйсә, бөтен җанлыларның һәм Дөньяның бер соң бар, яшәеш үлем белән соңлана. Киредән терелүне инкяр иткән колларга, алар Дөньяда булганнары хәлдә, Аллаһ Коръәндә шундый үрнәкләр китерә:

***Узенең яратылышын онытып, Безгә бер үрнәк китерде, диде ки: “Черегән, бозылган бу сөякләрне кем терелтәчәк?” Әйт ки:“Аларны беренче тапкыр яратып инша итуче терелтәчәк. Ул һәр яратылышны белер”. Ул сезгә яшел агачтан ут кылучы, сез дә аны ягасыз. Күкләрне һәм җирне яратучы аларга охшашларны яратуга көч җиткеруче тугелме? Әлбәттә (шулай), Ул – яратучы, белүче. Берәр нәрсәне теләгән заманда Аның әмере бары тик: “Бул”, - диюве, ул да шунда ук барлыкка килер. Һәр нәрсәнең хакимияте (хөкемдарлыгы һәм мөлкәте) кулында булган (Аллаһ) ни Бөек. Сез Аңа кайтарылачаксыз. (Йәсин сүрәсе, 78 - 83)***

***Аның могъҗизаларының берсе дә, син чынлап җир йөзен сулган, муенын салган һәм коп-коры буларак күрүвең. Әмма, Без аның өстенә суны иңдергән заманыбызда тишелер һәм кабарыр. Шиксез, аларны терелткән үлеләрне дә әлбәт терелтуче. Чөнки***

***Ул һәр нәрсәгә көч җиткерүче. (Фуссиләт сүрәсе, 39)***

Кешенең яратылышы яңадан тереләчәген күрсәтүче иң мөһим дәлилләрдән. Кеше тик бер спермадан камил җанлы буларак барлыкка килгән. Тик бер клетканың заман эчендә, кешенең һичнинди катнашувы булмастан, уйлый алган, күрә алган, акыллы барлык хәленә килүве бер башка терелешнең дә бик ачык галәмәте. Кешене юктан бар иткән Аллаһ, аның корыган сөякләрен туплап яңадан терелтүгә дә көче җитүче. Бу яратылуны мөһимсенмәгән кешеләр үзләренең барлыкка китерелгәннәренә игътибар итмичә, шайтаннан килгән кыюлык белән үзләрен терелешкә карата каршы куялар. Бу бөек бер кыюлык. Кеше моның аркылы Аллаһ каршындагы бөек җаваплылыкны да үз өстенә алган була. Ахирәттә исә, дөньяда ялганлаган бу хакыйкатьне каршысында ап-ачык буларак күрәчәк. Кыямәт Көне артыннан кешеләр аларга элегрәк Кыямәт вакытының килгәнлеген хәбәр биргән Сурның тавышын тагын бер тапкыр ишетәчәкләр. Инде бу мизгел кешеләрнең каберләреннән тышка чыгып, яңадан терелгәннәре мизгел. Бөтен кешеләр соңсыз (мәңгелек) бер тормыш башлау өчен аякка басканнар, көтәләр. Бу хәл аятьтә шулай тасвирлана:

***Сурга өрелде, болай итеп, Аллаһ теләгәннәрдән башка, күкләрдә һәм җирдә булганнар бәрелеп егылды. Соңыннан тагын бер тапкыр аңа өрелде, инде алар аякка баскан килеш күзәтәләр. (Зумәр сүрәсе, 68)***

## ДИН КӨНЕНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Аллаһ Катында җирнең, күкнең һәм кешенең яратылышы ни кадаәр җиңел булса, Кыямәт Көненең тормышка ашувы да бу кадәр җиңел булачак. Коръәндә Хисап һәм Җәза көненең булачагы «шиксез» һәм «әлбәттә» сүзләре белән китерелә. Шөбһәсезлекне белдергән бу сүзләр инанганнарның Ахирәткә карата булган

куркуларын һәм дөньядагы тырышлыклыран арттырган вакытта, инкяр итүчеләрнең Кыямәт турындагы шик һәм инкярларына да иң ачык буларак җавап бирә.

Үткән дәверләр дә булган кебек, бүгенге көндә дә динне инкяр иткән яки хак диннән аерылып, йолалардан торган ялгыш дин буенча яшәгән кешеләр җәмгыятьнең бөек бер өлешен формалаштыра. Югыйсә, нормаль анализ ясауга ия булган, уйлый алган берәр кешенең Ахирәт Көненә ихтимал бирмәвенең мантык ягыннан һичнинди таянычы да юк. Фәнни бөтен күрсәткечләр дә безгә дөнья соңының якынлашканын хәбәр бирә. Моңа карамастан, кешеләрнең бу хакыйкатьне күрмәүләренең сәбәбе, Аллаһны кирәгенчә танымаулары, белмәүләре, хакыйкый юл күрсәтуче булган Коръәннән тайпылулары һәм шулай итеп Хөкем Көнендә биреләчәк хисап турында уйланмаулары. Аллаһ куркувы белән хәрәкәт иткән мөэминнәр, тизлек белән якынлашкан бу соңны ачык буларак белгән хәлдә, нәфесләрен юл күрсәтуче иткән кешеләр бу бөек хакыйкатьне күрмәуне хуплый. Бит, Аллаһ Коръәндә кешеләргә бу хакыйкать турында шулай хәбәр бирә.

***Әйт ки: «Аллаһ сезне терелтә, соңыннан сезне үтерә, соңыннан да, үзендә һичбер шик булмаган Кыямәт Көнендә, Ул сезне бер арага китереп туплый. Ләкин кешеләрнең күпчелеге белмәс». (Җасия сүрәсе, 26)***

Дөнья тормышлары буенча бик күп тапкыр дингә чакырылганнары хәлдә, дөреслекне күрмәүне сайлаганнар үзләрен көтуче дәһшәтле соңны бары тик Дин Конендә тулаем буларак аңлый алачаклар. Дөнья тормышлары буенча инкяр ителгән һәрнәрсәне каршыларында тапкан кешеләр, ничаклы буш бер уен эчендә булганлыкларын ул көнне бөтен ачыклык белән күрәчәкләр:

***Ант ки, син моңа хәтле гафләт эчендә идең. Менә Без дә синең өстендәге пәрдәне ачып күтәрдек. Инде бүген карашларың кискен. (Каф сүрәсе,22)***

Кешеләрнең бу бөек Көнгә төшенә алмауларының сәбәбе – нәфесләренең юнәлтүләренә һәм үз фикерләренә бик артык ышанып, үз мәнфәгать һәм теләкләренә бәйле булулары һәм бу «гафләт» пәрдәсен күтәрә алачак хакыйкатьләрдән вөҗданнарын сукырайтып качулары. Бит, Коръәндә Аллаһ дөньяга юнәлгән, нәфесенә оеган, вөҗданын тыңламаган кешеләрдә аңлаешларының юк булганлыгы, Коръәндә үткән шарт белән әйткәндә, йөрәкләренең бикләнәчәге, шул сәбәпле дөреслекне күреп аера алмаячакларын белдерелгән. Югыйсә, инде Аллаһның барлыгына, бөеклегенә һәм вәгъдә иткәннәренә үзләре дә ачык рәвештә шаһитлар.

Берәр кеше Кыяматкә һәм ул көнне яшәләчәк вакыйгаларга тик бер мизгелгә генә инанса, хәтта бу ихтималның «була алачагын» бары тик бер секунд кына уйлаган булса да, яшәячәк куркувын тасвирлау бик тә авыр булачак. Моны иң баштан инкяр итү, хәтта акылына да китермәү, Ахирәтнең барлыгына ихтимал бирмәү, күпчелек кешеләрнең алдануына сәбәп була. Үзләрен биләп алган бу алдану сәбәбеннән «юк булу» куркынычлыгын да һич уйламаганлыкларыннан, Кыямәт Көненә һәм Ахирәткә инану урынына бу фикерне кабул итү аларга тагын да җиңелрәк күренә. Бу- шайтанның методы. Төрле методлар аркылы кешеләрне уйланудан ераклаштырыр һәм һич тә ирешә алмаячак өстенлек теләге һәм мал арттыру хисе белән игътибарларын алыр. Бу кешеләрнең Ахирәткә карата гафләт эчендә булуларының иң асыл сәбәбе. Ахирәттә каршылашылган хакыйкатьләр дә үзләренә үкенеч һәм кылларны тырпайтучы курку китертәчәк. Кешеләргә алдан хәбәр бирелгән хакыйкать бөтен ачыклыгы белән уртада. Инде Хисап Көненнән качу юк. Бу инкярчылар өчен чыннан да авыр көн. Аятьтә бу хакыйкать шулай хәбәр ителә:

***Муеннарын чакыручыга таба сузган хәлдә кяферләр диярләр ки: «Бу – авыр бер көн!» (Камәр сүрәсе,8)***

## ҮЛЕЛӘРНЕҢ КАБЕРЛӘРДӘН ЧЫГУЛАРЫ

***Сурга өрелде, болай итеп Аллаһ теләгәннәрдән башка күкләрдә һәм җирдә булганнар бәрелеп егылды. Соңыннан тагын бер тапкыр аңа өрелде, инде алар аякка баскан килеш күзәтәләр. (Зүмәр сүрәсе, 68)***

Аятьтә дә белдерелгәне кебек, һәрнәрсә булып беткәннән соң Сур тавышы икенче тапкыр ишетелер. Бу икенче тавыш белән каберләрдә булганнар тышка чыгарылыр. Ул Көнне Раббыбыз әмеренә каршы тора алачак яки бу әмерне әкренәйтә алачак һичбер көч яки кеше юк. Ул көнне туфрак астында булган кешеләр, дөнья тормышлары буенча еш-еш ишеткән, фәкать күбесенең инкяр иткән терелешне каршыларында табарлар һәм туфрактан чыгарылырлар. Коръәндә бу мизгелне аңлатучы аятьләрнең берсе шундый:

***Күкнең һәм җирнең Аның әмере белән (хәрәкәттән тукталып, булган җирендә яки бу тәртип эчендә) торувы ды Аның могъҗизаларыннан. Соңыннан сезне җирдән (туфрак астыннан) бер (тапкыр) чакыру белән чакырганы вакыт. Шунда ук сез (бер күрерсез ки,) чыгарылгансыз» (Рум сүрәсе, 25)***

Сурга икенче тапкыр өрелү белән берлектә дөнья башлаганыннан бирле яшәгән бөтен кешеләр терелгән булачак. Инде беренче өрелудә инкярчыларда күрелгән шашкынлыкны курку һәм үкенеч алмаштырган. Чөнки бу көнне инде соңсызга хәтле яшәләчәк кебек тоелган һәм планнар корылган дөньяда түгелләр һәм һәркем башына киләчәкләрен ачыклык белән аңлаган. Бу кешеләр арсында, хәзерге вакытта дөньяда яшәгән бөтен кешеләр белән берлектә, әлбәттә, сез дә булачаксыз. Бу хакыйкать Коръәндә шулай белдерелә:

***«Без череп таралган сөякләр булганыбыз заманмы?» Диярләр ки: «Ул хәлдә бу бер зарарлы кайтарылу!». Югыйсә, бу бары тик бер кычкыру кына. Бер курерсең ки, алар җирнең өстендәдер. (Назиат сүрәсе, 11-14)***

Кешеләр дөньяның мәңге буларак бар булачагын уйлап хәрәкәт итәрләр. Бу яшәешләре буенча дәвам иткән иң бөек хаталарның берсе. Кешеләрнең дөньяга бу дәрәҗәдә бәйләнгән булуларының төп сәбәпләренең берсе дә - Аллаһ җир йөзендә бар иткән бу могъҗизалы системаның үзеннән - үзе эшли алачагын исәпләүләре һәм берәр көнне соңы булачагын ихтимал итеп күрмәуләре. Югыйсә, хәзерге ситуация үзләренә вәгъдә ителгән хакыйкатьләрне бик ачык рәвештә күзләре алдына куя. Инкяр итүчеләр исәпләгән кебек үлем белән һәр нәрсә бетмәгән, бөтенләй киресенчә, ахыры булмаган мәңгелек тормыш башланган.

Дөнья тормышлары буенча Аллаһ үзләрен чакырган хак динне ялганлаган һәм үлемнең бер соң, бер юк булу (юкка чыгу) булганлыгын яклаган инкярчеләр, һич көтелмәгән бер мизгелдә аларны туфрактан чыгарган бу тавыш сәбәпле бөек дәһшәт эчендәләр. Әле гамәл дәфтәрләре үзләренә бирелмәгән һәм башларына киләчәкләрне бөтенләй яшәмәгән хәлдә булган инкярчеләр, «ах – вахлар » белән җирләреннән калкачаклар. Бу каршылашканнары Көн, асылында дөнья тормышлары буенча алар тарафыннан беленгән бер көн. Ясин сүрәсенең 52нче аятендә кешеләр яшәгән бу курку вакыты шулай аңлатыла:

***Дигәннәр иде ки: «Ах – вах, йокыга калдырылганыбыз җирдән безне кем терелтеп торгызды?» Бу Рахман булган (Аллаһ) ның вәгъдә иткәне. «(Димәк ки) җибәрелгән илчеләр дөрес сөйләгәннәр». (Ясин сүрәсе,52)***

Инде бик соңга калынган, дөньядагы яшәеш ни ләззәт, ни дә рәхәтлек биргән, бу мизгелгә кадәр кылынган һәрнәрсә алар өчен бары тик бу авырлыклы Көнне хәзерләгән.

## БЕР ЧАКЫРУЧЫГА ТАБА ЮНӘЛЕРЛӘР

***Ул көнне үзеннән тайпылу мөмкинчелеге булмаган чакыручыга иярәчәкләр. Рахман (булган Аллаһ) ка каршы тавышлар***

***кысылган. Инде бер гырылдаудан башка бер нәрсә дә ишетмәссең. (Таһа сүрәсе, 108)***

Кешеләр туфрак астыннан чыгарылганнан соң аларны чакыручы тавышка таба юнәлеп чаба башларлар. Бу чабу чакырылган җиргә барып җиткәнче дәвам итәр. Бу чакыру элек булган һичбер чакыруларга охшаш түгел. Мөэминнәр иминле һәм хозурлы килүләренә кирелек буларак, инкярчылар туплану җиренә алыначак каршылыкны хис итеп, бу көннең **"авырлыклы көн икәнен аңлаган хәлдә киләчәкләр"** (Камәр сүрәсе, 8). Инде туплану заманы. Моны туктата алулары өчен һичбер чаралары юк. Меңнәрчә еллар яшәгән бөтен кешеләр бер арада тупланачаклар. Бу зур туплылык Аллаһка баш игән буларак, шашкынлык эчендә тизлек белән хәрәкәт итә, үзләренә киләчәк газапларны көтә. Ни качу, ни кире кайту мөмкин түгел, үкенечләре дә аларга файда бирмәячәк. Курку бөтен минлекләрен яулаган. Аятьләрдә ул көнне яшәләчәк дәһшәт шулай тасвир ителә:

***Каберләреннән чапкан кебек чыгарылачаклары көн. Нәкъ алар утыртылган бер нәрсәгә юнәлгән кебекләр. Күзләре «куркудан һәм дәһшәттән төшенке», йөзләрен дә түбәнчелек каплаган. Менә бу үзләренә вәгъдә ителгән (Кыямәт һәм газап) көне. (Мәариҗ сүрәсе, 43-44).***

Дөньяда булганнарында аларга килгән авырулардан качкан, ни үзләренең, ни дә аталарының кире терелүләренә инанмаган бу кешеләргә Коръәндә Аллаһның биргән җавабы шундый:

***«Без үлгәнебез, туфрак һәм сөяк булганыбыз вакыт чыннан безне терелтеләчәкләрме? Яки элеккеге аталарыбызны да мы?» Әйт ки: «Әйе, өстәвенә башларыгызны игән кемсәләр буларак терелтеләчәксез.» (Саффат сүрәсе, 16-18)***

Дөньяда Аллаһның чикләрен танымаган, Аллаһка итәгать итмәгән һәм тәкәбберләнгән инкярчылар бу аятьләрдә аңлатылганы кебек, бик итәгатьле һәм баш иючән. Ни булып беткәнен сораштырмыйча, һичнинди шартсыз чакыручыга җавап бирәчәкләр. Үз ихтиярлары белән хәрәкәт итүләре мөмкин түгел. Алар Аллаһка тәслим булган, теләсәләр

дә, теләмәсәләр дә Аның бирәчәк хөкеменә баш игәннәр. Чөнки Ахирәт турында һич уйламыйча, нәфесләре өчен яшәгән дөнья тормышы тәмамланган инде. Аллаһ каршында ни кадәр гаҗиз булганннарын һәм Аллаһ газабының катылыгын һәм дөреслеген ачык буларак аңлаганнар:

***Алайса син алардан йөзеңне бор. Ул чакыручының «ни танылган, ни күрелгән нәрсәгә» чакырачагы көнне…(Камәр сүрәсе, 6)***

Кеше Аллаһка итәгать итүдән һәм Аңа баш июдән башка һичбер чарасы булмаганын аңлаган. Барыбер киресенчә теләсә дә эшли алмас. Хәтта теләмәячәк тә…

Инде бу көн Аллаһ бөтен кешеләргә вәгъдә иткән, инкярчылар өчен соң дәрәҗәдәге газаплы бер көн. Каберләрдән чыгуның өркетүче булувы һәм Туплану Көненең дәһшәте бәхәссез. Кешеләр үзләреннән алда дөньядагы яшәешләрен тәмамлаган кешеләрнең дә бу хакыйкать белән каршылашканнарына, Аллаһ вәгъдәсенең дөрес булганлыгына мондый бер көнне шаһит булганнар. Әмма, бөтен нәрсә өчен соңга калынган инде. Инде үзгәртелә алырлык һичбер нәрсә юк. Мондый бер көннән беркем дә котылмаячак.

## <u>КАБЕРЛӘРДӘН ЧЫГУ САРАНЧАЛАРНЫҢ ТАРАЛУВЫ КЕБЕК</u>

***Ахирәткә инанмаганнарның начар үрнәкләре бар, иң гүзәл үрнәкләргә исә Аллаһ ия. Ул көч иясе, хөкем һәм хичакрымәт иясе. (Нәхл сүрәсе, 60)***

Аятьтә дә белдертелгәне кебек, Аллаһның биргән һәр үрнәге аңлатылырга теләнгән хәләтне иң төгәл һәм иң гүзәл рәвештә тасвир итәр. Шул сәбәпле, Коръәндә һәрбер аятьнең «бөек камиллелеккә ирешкән хичакрымәт» булганлыгы белдерелгән. Коръәндә ясалган һәр тасвир, менә бу сәбәп аркылы, Кыямәт Көнендә булачакларны һәм кешеләрнең хәлләрен акылларыбызда җанландырувыбызны мөмкинчелек итә. Һичшиксез, Аллаһның вәгъдәсе хак һәм бөтен бу үрнәкләр һәм тасвирлаулар тормышка ашачак. Үрнәге, Камәр сүрәсендә Дин Көнендә туфрактан чыккан кешеләр

саранчаларның таралуларына охшатыла:

***Күзләре «түбәнчелек һәм дәһшәттән төшенке буларак», «таралган» саранчалар сыман» каберләреннән чыгарлар. (Камәр сүрәсе, 7)***

Әлбәттә, Аллаһ күрсәткән бу охшашлык башка аятьләрдә дә булганы кебек, ул мизгелнең акылларда җанландыра алынувы өчен иң гүзәл чагыштырмаларның берсе. Чөнки саранчаның таралувы дөньядагы башка бөтен хайваннарныкыннан тагын да аермалы.

Күчмә саранчалар бик күп саранчалардан торган көтүләр рәвешендә хәрәкәт итеп, үтелгән территорияләргә бик каты зарар салыр. Кайбер саранча көтүләренең киңлеге 1,5 чакрым, озынлыгы 80 чакрым, буйлары исә 25 метр. Һәм бу көтүләрнең эчендә якынча 40 млрд саранча бар. Һаваның агышы тиз булганда саранча көтүләре 200-500 метр биеклектә очар һәм саранчалар очканларында бер-берсенә бик якын булыр. Миллиардларча саранча бер арага килеп, чакрымнарча озынлыктагы һәм киңлектәге кап-кара яңгыр болыты сыман манзараны барлыкка китерерләр.

Көненә 80-100 чакрым үтә алган күчмә саранчалар, кирәк булганда су комачаулыкларын да ашып, тизлек белән максатларына ирешерләр. Ирешелгән җирләрендә болыт өеме хасил итәрләр. Миллионнарга җитүче саннары белән бер мизгелдә барлыкка килеп, ирешелгән территорияне каплап алырлар, хәтта тупланма хәлендә таралырлар.

Аятьләрдән аңлашылганча, кешеләрнең туфрактан чыгувы да бу рәвештә булачак. Сурның тавышын ишеткән миллиардларча кеше, нәкъ саранчалар кебек бер мизгелдә туфрак өстендә пәйда булачак, бергә чакыручының тавышына таба чаба башлаячак. Кешеләрнең аларны чакырган тавышны ишетер-ишетмәс туфрактан чыгулары Рум сүрәсендә шулай аңлатыла:

***Күкнең һәм җирнең Аның әмере белән (хәрәкәттән***

***туктальп, булган җирендә яки бу тәртип эчендә) торувы да Аның могъҗизаларыннан. Соңыннан сезне җирдән (туфрак астыннан) бер (тапкыр) чакыру белән чакырганы вакыт. Шунда ук сез (бер күрерсез ки,) чыгарылгансыз. (Рум сүрәсе, 25)***

Дөньяның бар булганыннан алып яшәгән бөтен кешеләрнең бер мизгелдә туфрак астыннан чыгарылып, бер урында тупланулары чыннын да шаккатырырлык бер манзара. Мондый бер көнне бер арага килгән миллиардларча кешеләр алар өчен билгеләнгән хөкемне көтәләр һәм моны һич тә туктата алмыйлар.

## БАШЛАРЫ КҮТӘРЕЛГӘН КИЛЕШ ТИК БЕР ҖИРГӘ ТАБА ЧАБАРЛАР

Ул көнне инкярчылар башлары күтәрелгән, күзләре тик бер ноктага юнәлгән килеш, гипноз булган кебек чабачаклар. Бары тик Аллаһ теләгәнчә хәрәкәт итеп, чакыру ясалган җиргә таба юнәлгәннәр. Аллаһ вәгъдәсе кирәктергәнчә, иминлек эчендә булган мөэминнәрдән башка һәркем куркуга бирелгән:

***Һәм аларның һәммәсе Кыямәт Көнне Аңа "яп-ялгыз,тик буларак" киләчәкләр. Иман иткәннәргә һәм изге гамәлләр кылганнарга исә, Рахман (булган Аллаһ)тан сөю булачак. (Мәрьям сүрәсе, 95-96)***

Дөньяда булган вакытларында инкяр эчендә булганнар курку һәм шашкынлык эчендә чапкан заманнарында, ни үзләренә, ни дә башкаларга карый алачаклар.

Хәтта карау аларның акылларына да килмәс. Дин Көнендә ни малларның, ни балаларның, дөньяга юнәлгән теләкләрнең бер кыйммәте дә юк. Һәркем шартсыз буларак итәгать хәлендә. Тик бер яраган нәрсә- ул да иман. Аллаһ инкяр иткәннәрнең ул вакыттагы хәлләрен шулай тасвир кыла:

***(Әй Мөхәммәд), Аллаһны һич золым итүчеләрнең кылганнарыннан хәбәрсез дип санама, аларга бары тик күзләрнең дәһшәте билгеле булачак бер көнгә хәтле вакыт бирә. Башларын күтәреп чабарлар, күзләре үзләренә кире кайтмас. Йөрәкләре бум-буш (сыман). (Ибрахим сүрәсе, 42-43)***

***Хәзер инкяр итүчеләргә ни була ки, муеннарын сиңа сузып чабалар. Уң яктан һәм сул яктан бүлемнәр хәлендә. Аларның һәрбере нигъмәтләр белән әйләндерелгән җәннәткә керәчәген ме саный, исәп итә? (Мәариҗ сүрәсе, 36-38)***

Инкярчылар үзләрен коткара алулары өчен бер хәрәкәт тә кылмаячак, хәтта бу акылларыннан да кичмәс. Йөрәкләре бум-буш, үзләренә соң килгәнлеген беләләр. Кешеләрнең хисап бирүләре өчен каберләреннән чыгып чабулары Раббыбыз хозурында бер тәртиптә тупланулары белән соңланыр. Аллаһ Коръәндә бу туплану вакытын инкярчыларга шулай белдерә:

***Алар синең Раббыңа чират-чират китерелгәннәр. Ант булсын, сезне беренче тапкыр яратканыбыз кебек Безгә килгән булдыгыз. Юк, сез Безнең сезгә бер кавышу заманы билгеләмәгәнебезне санаган идегез түгелме? (Кәһар сүрәсе, 48)***

Бу кешеләрнең күпчелеге мондый кавышу вакытының киләчәгенә һич инанмыйлар иде. Югыйсә, үзләрен һәрьяктан кушаткан ул Бөек Көн тормышка ашкан. Инде һичбер чаралары юк.

## КЕШЕЛӘРНЕҢ ХИСАП ӨЧЕН ТУПЛАНУЛАРЫ

Бу вакыт кяферләр тарафыннан гомерләре буенча качылган, белмәмешкә салынган, мөэминнәрнең исә хәзерләнеп көткәннәре хисап вакыты. Бүген һәрнәрсә Аллаһның көче һәм сыйфатлары кирәктергәнчә яратылган. Хисап булувы өчен рух һәм фәрештәләр сафлар хәлендә тезелгән. Ул көндә кешеләр арасында гаделлек белән хөкем ителәчәк һәм сөйләшәчәк кеше бары тик дөреслекне генә сөйли алачак:

***Рух һәм фәрештәләр сафлар хәлендә торачак көн. Рахманнан үзләренә рөхсәт бирелгәннәрдән башка булганнар сөйләшмәсләр. (Сөйләшәчәк булучы да,) дөреслекне сөйләячәк. (Нәбә сүрәсе, 38)***

Көръндә белдерелгәнчә, Ахирәттә Аллаһ колларына иң соңгы дәрәҗәдәге Бөеклеген курсәтәчәк. Ул көнне Аллаһ тәхетен сигез фәрештә ташый:

***Фәрештә(ләр) исә аның тирәсендә. Ул көнне Раббыңнын тәхетен сигез (фәрештә) ташыр. Сез ул көнне китереләчәксез. Сезнең һичбер качырганыгыз серле булып калмаячак. (Хакка сүрәсе, 17-18)***

Ул көнне туфрак астыннан чыккан бөтен кешеләр дулкын – дулкын Аллаһ хозурына килерләр.

***Шиксез, ул хөкем көне билгеләнгән бер вакыт. Сурга өреләчәк көнне инде сез дулкын – дулкын киләчәксез. (Нәбә сүрәсе, 17-18)***

Коръәндә мөэминнәрнең ул көнне йөзләреннән нур киләчәге һәм аларның Раббыбызга карап торганлыклары белдерелгән. Инкяр иткәннәр исә, оятларыннан хәтта башларын да күтәрмәсләр. Инкярчыларның ул вакыттагы хәлләрен бер аять шулай белдерә:

***(Инде бөтен) Йөзләр Тере, Үзеннән Үзе гел бар булганның алдында иелеп тора биргән һәм үзенә золым йөкләнгән дә юк булып киткән. (Та-һа сүрәсе, 111)***

Хәзерге вакытта дөньяда миллиардларча кеше яши. Бу санга хәзергегә хәтле яшәгән һәм киләчәктәге яшәячәк кешеләрнең дә санын кушсак, Мәхшәр (терелү) көнендә каберләрдән чыгып тупланачак кешеләр җыелмасы һәм моның барлыкка китерәчәге шаккаттырырлык манзара хаккында фикер итә алабыз. Кешеләр бер арада тупланачак һәм бер-берсен, кылганнарын, булып беткәннәрне ачыклык белән күреп аңлый алачаклар. Чөнки ул көнне, Каф сүрәсендә белдерелгәне кебек, карашлар кискен булачак:

***Ант булсын, син монардан гафләт эчендә идең. Менә Без дә синең өстеңдәге пәрдәне ачып күтәрдек. Инде бүген карашларың кискен. (Каф сүрәсе, 22)***

Кешенең гомере буе танып белгән бөтен кешеләре анда. Танылган, танылмаган, бай, ярлы һәркеше, кыскасы, Кыямәт Көнендә кадәр яшәп үлгән бөтен кешеләр, араларында һичбер аерма булмастан, Аллаһ хозурында тупланырлар. Әмма, мондый бер көндә ни казанганнары шөһрәтләреннән, ни дә ия булганнары ихтирам һәм игътибар ителүләреннән һичбер эз дә калмаган иде. Ул көнне бары тик мөэминнәр үкенмәячәк. Берәр дәвердә үзенең эзен калдырган, дөнья тарихында үзләре турында бик күп сөйләнелгән булса да, иман итмәгән өчен бөтен кешеләр Аллаһ хозурында үкенеч һәм көчле газап, курку эчендә булачаклар. Кешеләр тарафыннан дөньяда өстен һәм мәшһүр күрелгән кешеләр, президентлар, җырчылар, сәнгатьчеләр, байлар, кыскасы, һәркем бертөрле куркуны яшәячәк. Бернинди дөньядагы өстенлекләр булмастан, һәркем бертөрле халәттә булачак. Дөньяда кешеләрне аерган акча һәм дәрәҗә, кешеләр бер арада тупланганнары бу көнне һичбер нәрсә аңлатмаячак, хәйран итүче дә, хәйран ителгән дә бер халәттә булачак. Коръәндә Дин Көнендә кешеләрнең Аллаһ хозурында тупланачагын белдергән аятьләрнең кайберләре шулай:

***Ул көнне аларның барысын бер арага туплаячакбыз… (Юныс сүрәсе, 28)***

***Әйт ки: «Аллаһ сезне терелтә, соңыннан сезне үтерә, аннан соң үзендә һичбер шик булмаган Кыямәт Көнендә, Ул сезне бер арага китереп туплаячак.» Ләкин кешеләрнең күбесе белмәс. (Җасия сүрәсе, 26)***

Ул көнне дөньяда ия булган дәрәҗәнең һәм малның һичбер әһәмияте юк. Һичкем башкасының ризалыгы артыннан чапмаячак, һичкем дә башкасына рия күрсәтмәс яки аның алдында горурлана алырлык хәлдә түгел. Нәселлеләр, байлар, әфәнделәр, идарәчеләр яки гади кешеләр бертөрле хисап белән кара-каршы калачаклар. Өстенлек Аллаһка булган якынлыкка күрә. Бөтен кешеләр, Аллаһның ризалыгын казану өчен

кылынган эшләрдән тыш, һичбер башка эшләрнең әһәмияте булмаганлыгын, ия булынган һәрнәрсәнең бердәнбер хуҗасы Аллаһ булганлыгын бик ачык рәвештә аңлаганнар. Ләкин хакыйкатьләр белән каршылашкан инкярчыларның инде кире кайтып кылганнарын төзәтү мөмкинчелекләре юк. Коръәндә бу вакыйга шулай аңлатыла:

***Шулай итеп сурга өрелгәндә, инде ул көнне араларында нәселләр (яки нәсел бәйлекләре) юк һәм (өстенлек сәбәбе буларак нәселдәнлекне яки бер-берсенең хәлләрен) сораштырмаслар да. (Мөәмин сүрәсе, 101)***

## ХИСАП ВАКЫТЫ

Коръәндә кеше тормышының чын мәгънәсе шулай ачыклана:

***Әй кеше, чынлыкта син һич тукталмыйча Раббыңа карата тырышлык кылып торасың, соңыннан Аңа барачаксың. (Иншикак сүрәсе, 6)***

Кешеләр тормышында әһәмиятле саналган билгеле этаплар, вакыйгалар бар. Яхшы берәр университетка керү, диплом алу, өйләнү, балалы булу кебекләр… Бу һәм моңа охшаш планнары булган, кешеләр максатларына ирешәчәк вакытка хәтле көннәрен саный-саный, аны алдан билгеләп хәрәкәт итәрләр. Гомерләрендә бары тик бу максат бар һәм нибары шуның өчен яшәгәннәрен дә белгертүдән тартынмаслар. Югыйсә, кеше Аллаһка коллык итү өчен яратылган. Никадәр үзе кабул итәргә теләмәсә дә, бу яратылувының асыл максаты. Чынлыкта моны белер. Әмма китапның башында да аңлатканыбыз кебек, аның тарафыннан һич бетмәячәк дип исәп кылынган дөнья тормышында бу хакыйкатьне онытырга тырышып яшәр. Кыскасы, моны бөтенләй күрмәскә тырышыр. Гомере буе ни эшләсә дә, күрсәткән бөтен тырышлыклар нәтиҗәсендә барачак соңгы ноктасы Аллаһ хозуры һәм ул вакыттагы хисап. Бу хисап Мәхшәр Көнендә тормышка ашачак.

Дөнья тормышында үткән һәр көнебез безне ул Мәхшәр Көненә

тагын да якынлаштыра. Үткән һәр сәгать, һәр минут, һәтта һәр секунд үлемгә, яңадан терелүгә һәм хисапка таба атылган яңа бер адым. Моны туктатырлык чара юк. Бөтен кешеләр бу юлдан үтәчәкләр. Аллаһ Коръәндә шулай боера:

***Шиксез, алар Безгә кайтачаклар, соңыннан аларны хисапка тартачакбыз. (Гашия сүрәсе, 25-26)***

Ул вакыт килгәндә инде һәрнәрсә соңына ирешер. Бу этапта кире кайту соң яки кылганнарны төзәтү мөмкинчелеге дә юк. Вөҗданнары күрсәткән хакыйкатьне күрмәскә тырышканнарның яшәгән паникасы һәм шашкынлыгы тагын да элек һич хис ителмәгән масштабларда. Барлыгы һәм берлеге һичбер шиккә сәбәп булмаган дәрәҗәдә ачык булган Аллаһны, дөньяда инкяр итәчәк кадәр залим булган бу кешеләр, алданрак һич көтелмәгән, ише күрелмәгән бер газап белән җәзаланачаклар. Чөнки Хак Китапны (Көръәнне) ирештерүче, аңлатучы илчеләр тарафыннан кисәтелгәннәр һәм ничек яшәргә кирәклегенә кагылган һәр яктан хәбәрдар ителгәннәр. Аларга дөньяда аңлатылганнар турында уйланып, нәтиҗә алыначак кадәр бер вакыт та бирелгән. Аллаһ Коръәндә: ***«Сезгә дөньяда үгет алучының үгет ала алачагы кадәр бер вакыт бирелмәдеме?» (Фатыр сүрәсе, 37)*** аяте аркылы бу хакыйкатьне белдергән.

Инде бирелгән вакыт беткән, хисап вакыты килгән. Кеше гомере буе эштә, өйдә, уку йортында, күңел ачканда һәркайда булса булсын, бөтен кылганнарына Аллаһ шаһит. Кешегә «муен тамырыннан» тагын да якынрак булган Аллаһ һәркемнең һәр мизгелен күзәтә. Дөньялык тормышта һәркем кем тарафыннан яратылганын, яратылыш максатын, кылувы кирәккәннәрне һәм Аллаһка кайтыралачагын өйрәнгән. Бу хакыйкатьне белгән килеш үз-үзләрен алдауны сайлаганнар. Шиксез, бу бөек бер хата, бөек бер кыюлык һәм дә бу шайтани кыюлык, әлбәттә, каршылыксыз калмаячак. Ул авыр көндә һәркемгә кылганнары һәм кылмаганнары берәр-берәр хәбәр биреләчәк:

***Аллаһ һәммәсен терелтәчәк көн. Аларга ниләр кылганнарын хәбәр бирәчәк. Аллаһ аларны (кылганнарын берәр-берәр) сынаган,***

***алар исә аны онытканнар. Аллаһ һәрнәрсәгә шаһит булучы. (Мужәдәлә сүрәсе, 6)***

***Ул көнне кешеләр гамәлләре аларга күрсәтелсен дип булем-булем чабып чыгарлар. Инде кем зәррә (тузан бөртеге кадәр иң кечкенә өлешчә) авырлыгындагы яхшылык эшләсә, аны күрер. Инде кем зәррә авырлыгындагы берәр шәр (начарлык) эшләсә, аны күрер». (Зәлзәлә сүрәсе, 6-8)***

Аллаһ Коръәндә***: «...сез яхшылык ниятеннән ни кылсагыз, Аллаһ аны белер. Азык хәзерләгез, шиксез, азыкның иң хәерлесе-тәкъва(Аллаһтан курку)...» (Бакара, 147)*** дип кешеләрне хисап вакыты өчен хәзерлек кылырга чакырган. Вөжданын кулланган, Аллаһның чакырувына җавап биргәннәр өчен ул көнне һичбер курку һәм хәсрәт юк. Инкяр иткәннәр исә, төзәтелүве булмаган бер үкенеч яшәрләр. Дөньядагы гамәлләре Ахирәттә аларга хәтерләтергән вакытта, яшәлгән үкенечләре Коръәндә шул рәвештә аңлатыла:

***... ул көнне Җәһәннәм дә китерелгән. Кеше ул көнне уйланып хәтерләр, ләкин (бу) хәтерләүдән аңа ни файда? Дияр ки: «Әгәр тормышым өчен (алданрак бер нәрсәләр) хәзерләгән булса идем». Инде ул көнне һичкем (Аллаһның) бирәчәк газабы кебек газапландырмас. (Фәҗер сүрәсе, 23-25)***

## ҺИЧКЕМГӘ ХАКСЫЗЛЫК ИТЕЛМӘС

***Җир Раббыңның нуры белән яктырды, (урта җиргә) китап куелды, пәйгамбәрләр һәм шаһитлар китерелде. һәм araларында хаклык белән хөкем бирелде, алар хаксызлык ителмәс. (Зүмәр сүрәсе, 69)***

Кылынган һәр гамәлдән соралачак буласы бу көннең бөеклеге Аллаһның бөеклегенә, чиксез гаделлегенә, Җәббар (теләген бернигә дә карамастан кылган), Каһһар (каһәрләгән) һәм Мунтакыйм (үч алган) сыйфатларына килешкән рәвештә булачак. Дөньяда булганы кебек,

Ахирәттә дә гамәлләрдән соралып җәзаландырылу, Аллаһның гаделлеге аркылы кимчелексез күреләчәк. Ул көнне корылачак «сиземле үлчәүләр» белән һәркем хак иткәненең каршылыгын алачак. Коръәндә корылачак “хассас “ (бик нечкә) үлчәүләр турында шулай хәбәр бирелә:

***Без исә Кыямәт Көненә хас сиземле үлчәүләр куярбыз да, инде һичбер нәфес һичбер нәрсә аркылы хаксызлык ителмәс. Бер горчица (хардал) данәсе кадәр булса да аңа (үлчәүгә) китерербез. Хисап күрүчеләр буларак Без җитәрбез. (Әнбия сүрәсе, 47)***

Дөньялык тормышында кылынган һәр гамәл, хәтта иң кечкенә үзенчәлекләренә дә калмастан, бу үлчәүләргә куелыр. Бу үлчәүнең угы соңсыз газапка яки мәңгелек котылуга һәм сәгадәткә алып барачак карарны билгеләр. Кылган яхшылыклары, изгелекләре авыр килгән кешеләр Җәннәткә китәчәк, җиңел килгәннәр исә куркыныч газап белән газапландырылачак, Җәһәннәмгә атылачак. Аятьләрдә шулай боерыла:

**Менә кемнең үлчәүләре авыр баса, инде ул хуш булыначак бер тормыш иясе. Кемнең үлчәүләре җиңел калса, инде аның анасы да (соңгы тукталышы) «һавия» (упкын). Аның ни булганын (асылын) сиңа ни белдерде? Ул кызган бер ут. (Кариа сүрәсе, 6-11)**

## ХИСАП УРЫНЫНА БЕР КУУЧЫ ҺӘМ БЕР ШАҺИТ БЕЛӘН КИЛЕНЕР

Хисап көнне сорау алынган вакытта һәр кешенең янында булачак ике фәрештә турында Коръәндә шулай хәбәр бирелә:

***(Инде) һәрбер нәфес янында бер куучы һәм шаһит белән килгән. (Каф сүрәсе, 21)***

Дин Көнендә һәрьяк Аллаһның нуры белән яктырыр. Бу бөек мәхкамәдә таныклык кылачак илчеләр һәм шаһитләр хәзер кылыныр. Дөньяда Аллаһка коллык итү кирәклеген кешеләргә хәтерләткән һәм аларны үгетләгән пәйгамбәрләр һәм башка шаһитлар Хисап Көнендә

сораштырылачак кешеләрнең янында. Бу шаһитлар хаклык белән хөкем бирәчәкләр. Хисап Көнендә, чынлыкта Аллаһка коллык итү кирәклеген белгән хәлендә, белмәгәнен яклый алачак беркем дә булмаячак.

Ул көнне һич кемнең дә Аллаһ хозурында була торып, кылганнарын инкяр итү форсаты һәм мөмкинчелеге юк. Кылган барлык яхшылыклары һәм начарлыклары уртага чыгарылган. Хәтта дөреслекләрне инкяр итсә дә, шаһитлар гадел булачаклар һәм аны гаепләячәкләр. Һәр өммәт Раббыбыз хозурына тәртип эчендә, үзенең имамы һәм китабы белән киләчәк. Адәм пәйгамбәрдән алып Кыяматкә хәтле яшәгән бөтен өммәтләрнең бер арада җыелган хәлдә, булачак сорау алудагы тәртип һәм хисаптагы нечкәлек безгә Аллаһның бөек акылга ия булганлыгын һәм чиксез гаделлеген күрсәтер. Аллаһ гаделлекне бер аятьтә шулай хәбәр бирә:

***Ул көнне син һәр өммәтне тезләнгән (яки тупланган) килеш күрерсең. Һәр өммәт узенең китабына чакырылыр. «Буген кылганнарыгызга каршылык күрәчәксез.» (Җасия сүрәсе, 28)***

## КОЛАКЛАРЫ, КҮЗЛӘРЕ ҺӘМ ТИРЕЛӘРЕ ШАҺИТЛЕК ИТӘР

Ул көнне гөнаһ кылучыларның начарлыкларына шаһит булганнар да анда хәзер булып торырлар. Мөэминнәрнең язучы фәрештәләр һәм Аллаһ рөхсәт иткән шаһитлары булган хәлдә, инкярчыларның аларга каршы шаһит итәчәк һич көтелмәгән шаһитлары да бар. Болар, хәтта кешенең үзен яп-ялгыз санаган вакытында да, Аллаһның аны һәръяклап кушатып алганлыгына иң ачык дәлилләрдән. Инкярчыларга каршы шаһитлык кылачаклар арасына аларның ишету, күрү хисләре һәм тиреләре дә кушылган. Һәрберсе Аллаһның рөхсәте белән сөйләшер һәм әйтелергә тиеш булганнарны кимчелексез ирештереп, үзләренең шаһит булганлыкларын белдерерләр. Гомерләре буе кулланылган, үзләренеке дип саналган органнарның да хәтта, кешегә каршы шаһитлык кылулары ул көнне яшәләчәк психологик җимерелүне тагын да арттырыр. Коръәндә моны аңлатучы аятьләр шул рәвешле:

***Аллаһ дошманнарының бер арага китерелеп тупланачак көннәрендә. Менә алар утка бүлемнәр хәлендә таратылырлар. Соңыннан анда барылган вакытта ишетү, күрү (хисләре) һәм тиреләре аларга каршы шаһитлек итәчәкләр. Үзләренең тиреләренә әйттеләр ки: «Нигә безгә каршы шаһитлык кылдыгыз?» Диделәр ки: «Һәркемгә тел биреп сөйләштерүче Аллаһ безне сөйләштерде. Сезне беренче тапкыр Ул яратты һәм Аңа кайтарыласыз. Сез ишету, күрү (хисләрегезне) һәм тиреләрегезне сезгә каршы шаһитлык итүләреннән сакланмадыгыз. Киресенчә, кылганнарыгызның күпчелеген Аллаһ белми дип санный идегез. Менә бу сезнең исәбегез, Раббыгыз хаккында булган уйлавыгыз сезне хәлакәткә китерде. Шулай итеп, хәсрәткә тап булганнар кебек иртәләдегез». Хәзер, әгәр сабыр итә алсалар да, инде аларның тукталу урыны – ут. Һәм әгәр алар хуш булуга (дөньяга) кайтырга теләсәләр дә, инде хуш булачаклардан түгелләр. (Фуссиләт сүрәсе, 19-24)***

Кеше кылган һәрнәрсәсе өчен акыллы ачыклау ысулы таба алувы мөмкин. Хәтта моңа үзен ышандыра да ала. Бу ачыклауларның һәрвакыт акылга сыярлык нәрсәләр булувы да шарт түгел. Ул вакытта теләнгән тик бер нәрсә, ачыклаулар белән каршы тарафны яки үз-үзен ышандыру. Башкача аңлатканда, ышанырга теләгән нәрсәгә ышанып һәм аны яклар өчен аңлатмалар эзләр. Ясаган ачыклаулары да бу мантыкка таяна. Бәлки дә бу сәбәптән, хәтта Аллаһның барлыгын да инкяр итә алувы өчен китергән дәлилләре, үзенә яраклы күрелгән һәм боларга таянып үткән тормышында инанганнарга каршы карарлы көрәш алып барган. Әмма, бу ачыклауларның һәм аңлатмаларның һичбере Хисап Көнендә яраклы түгел.

Ул көнне горурлык һәм ышаныч белән якланылган ачыкламаларның яраклы булмаганлыгын күрәчәк, аңа каршы шаһитлек кылган органнары каршысында яшерәчәк бернәрсәнең дә калмаганлыгын аңлаячак. Һичкем күрмәгән дип исәпләгән нәрсәләре, яшерен кылган эшләре берәр-берәр уртага куелачак, гәүдәсе моны белдерәчәк.

## ЯП-ЯЛГЫЗ ХИСАП БИРӘЧӘКЛӘР

Бу көннең башка бер үзенчәлеге дә, дөньяда һәм Ахирәттә якыннарыннан гел ярдәм көтүчеләрнең, моның киресе буларак, хисапка «ялгыз буларак» тартылулары. Шулай итеп, инкярчылар Аллаһтан тыш башкасыннан нидер көтүнең ни дәрәҗәдә мәгънәсез икәнлеген күрәчәкләр һәм кылынган ялгышларының каршылыгын да алачаклар. Һәр кешенең ялгыз башына хисапка тартылачагы Коръән аятьләрендә белдерелгән:

***Һәм аларның һәммәсе Кыямәт Көне Аңа «япа-ялгыз» киләчәкләр. (Мәръям сүрәсе, 95)***

Монда әз генә тукталып, бу хакыйкать турында детальле буларак уйлану кирәк. Ялгыз калу кешеләрнең дөньялык тормышындагы иң теләнмәгән, бигрәк тә авыр заманнарда аларны куркыткан нәрсәләрнең берсе. Ялгыз килеш калу, хәтта дөнья шартларында булса да, кешеләр өчен булган иң каты газапларның берсе. Югыйсә, Ахирәт Көнендә эш яп-ялгыз калу белән генә бетми. Асыл булганы, берәр инкярченең золым кылганын белүве сәбәпле, бик каты курку хис иттергән хисап заманы белән каршылашувы. Үзенә ышана алырлык, ярдәм итәрлек беркем дә аның янында юк. Хәтта якынлык һәм мәрхәмәтлелекләренә нык итеп ышанылган гаиләсе дә аны танымас. Өстәвенә, һәрнәрсә аңа каршы. Аның гәүдәсе, кылган гамәлләре аңа каршы ачыклаулар кыла башлаган. Кыскасы, бу ялгызлык – җиңел генә аңлатыл алмаслык бер ялгызлык.

Ялганчы иляһлардан һәм дуслардан ярдәм көткәннәре кебек, кяферләрнең башка бер хатасы - дөньяда яшерен кылган гөнаһларының һәм начарлыкларының Хисап Көнендә уртага чыкмаячак дип санаулары. Югыйсә, Аллаһ аларның дөньлыкта кылган яшерен һәр хәрәкәтенә һәм сүзләренә шаһит. Бу хакыкать аятьләрдә шулай хәбәр ителә:

***Сез ул көнне китереләчәксез. Сезнең һичбер серегез яшерен калмаячак.(Хакка сүрәсе,18)***

***Һәрбер нәфескә кылганының каршылыгы тулысынча***

***биределде. Ул – аларның кылганнарын тагын да яхшырак белүче.(Зүмәр сүрәсе,70)***

Инде инкярчыларның бөтен гөнаһлары уртада. Гомере буе гаиләсенә, хәтта иң якын дустына да ялган сөйләгән, аларны алдаткан, үзенең мәнфәгатьләре өчен һичбер нәрсә алдында туктамаган, Аллаһ илчеләрен ялганлаган, алар аңлаткан һәрнәрсәне кире каккан һәм иң соңында, боларның беркайчан да булмаячагын һәм бөтенләй онытылачак дип санаган кешеләр ул көнне яп- ялгыз хисап бирәчәкләр. Бөтен серләре фаш булган бу кешеләрнең халәте Тарык сүрәсендә шулай аңлатыла:

**Серләр уртага чыгарылачак көнне аның көче дә, ярдәмчесе дә юк. (Тарык сүрәсе,9-10)**

## УЛ КӨННЕ ДУСЛЫК, ТУГАНЛЫК ҺӘМ ЯКЫНЛЫК ЮК

Кешенең ул көнне үзеннән башкасы турында кайгыртырлык ни хәле,ни дә мөмкинлеге бар. Хәтта дөньяда булган вакытында якын күрелгән һәм аңа ышанылган гаиләсе турында да уйламас. Яшәлгән вакыйгаларның дәһшәте сәбәпле бары тик үзен генә кайгыртыр. Дөньяви тормышта да иң күп мактанылган, нәсел агачлары хәзерләнелгән, шәҗәрәләре табылган аталары, туганнары һәм балалары белән булган бәйлеге инде купкан:

***Шулай итеп Сурга өрелгәндә. Ул көнне араларында нәселләр (яки нәсел бәйлекләре) юк һәм (өстенлек сәбәбе буларак нәселдәнлекне яки бер – берсенең хәлләрен) сораштырмаслар да. (Мөэминин сүрәсе,101)***

Дөньяда якыннарының малын, дәрәҗәсен һәм дистәгән бөек бер көч дип санап, аларга сыенганнарның ышанычлы калъгалары җир белән бер булган. Өстенлекне һәм көчне аталарыннан килгән дәрәҗәдә яки матдиатта эзләгәннәр, дин әхлагыннан ерак бер тормыш яшәп бер керем казануларын исәпләгәннәр, хәтта моны өстенлек дип белүче кешеләр кылынылган хатаны аңлаганнар. Бүген бары тик иманның кыйммәте бар.

Дөньяви тормышта дуслыкның барлыкка килүве яки давам итүве өчен иң мөһим, таралган шартларның берсе кешенең каршындагы кешедән алачак мәнфәгате. Мәнфәгате исә, киләчәген имин итә алу, киләчәктә файда китерерлек иттереп хәзердән капиталын кирәгенчә куллану, акча, игътибар, ихтирам, тирәсендәге кешеләрне казану максатын ташый. Югыйсә, Хисап Көнендә бер кемнең дә ләззәт, хисләр һәм шәһвәт артыннан чабачак хәле калмаганлыктан, бөтен иске дуслар бер мизгелдә онытылыр. Корьәндә бу хакыйкать шулай белдерелер:

***(Мондый бер көндә) һичбер якын дус һичбер башка якын дустын сорамас.(Мәариҗ сүрәсе, 10)***

Дин Көнендә булган курку шул кадәр бөек ки, һәркем кем булса булсын, бу куркыныч газаптан котыла алувы өчен бөтен ия булганнарыннан ваз кичәр. Бернәрсәсен дә кызганмыйча ия булган байлыкларына һич әһәмият бирмәс. Хәтта үзенеке генә түгел, дөньядагы бөтен байлыклар аныкы булса да, һәммәсен фидья (каршылык) буларак бирергә теләр. Бик каты иттереп кулында тотылган барлык малы инде аның өчен һичбер мәгънә ташымас. Аллаһ юлында саранлык күрсәтеп бирмәгән малларын, күзен дә йоммыйча фида итәр. Әмма, инде бик соңга калынган. Аннан теләнелгәне: күз ачып йомганчы үтәчәк кыска дөньяви тормышында Аллаһ аңа биргән нигъмәтләрне Аллаһ юлында куллану булган хәлдә, ул бу авыр көнне күрмәмешкә салышкан, хәтта үлгәннән соң да дөньяда калган әсәрләре аркылы исеменең хәтерләнәчәген, шөһрәтенең дәвам итәчәген өмет иткән. Коръәндә аларның бу чишелешсез халәтләре шулай аңлатылган:

***Әгәр җир йөзендә булганнарның бөтенесе һәм моның белән бергә бер каты тагын залимнәрнеке булган булса иде, Кыямәт Көнендә ул начар газаптан (котылу нияте белән) чыннан да боларны фидья буларак бирер иде. Югыйсә, алар тарафыннан һич хисап ителмәгән нәрсәләр Аллаһтан үзләре өчен ачыкка чыгарылган. (Зүмәр сүрәсе, 47)***

***Ибраһим диде ки: «Чыннан да сез Аллаһны калдырып, дөнья***

***тормышында арагызда бер сөю бәйләнеше булган потларны иляһлар иттегез. Соңыннан Кыямәт Көнендә бер-берегезне инкяр итеп танымаячак һәм бер-берегезгә ләгънәт итәчәксез. Сезнең калачак урыныгыз ут һәм һичбер ярдәмчегез юк.» (Әнкәбүт сүрәсе, 25)***

Дөньяда булган вакытларында бик күп ялгышларга шаһит булуларына карамастан, инкярчыларның һичбере дә дуслыкларының ялган булу хакыйкатен кабул итергә теләмәс. Күп кенә кешеләр арасында булган дуслык һәм сөю «башкаларыннан аермалы». Югыйсә, гел бертөрле хата кылганнар, тугрылыкны хәтта дөньяда булган вакытларында да һичбер заман яшәмәгәннәр. Өстәвенә, ул көнне күренгән газаптан котылыр өчен ясалган тәкъдимнәр инкяр итүчеләрнең дуслыкка булган карашларын фаш итәчәк. Ул көнне, аларга дөньядагы вакытларында бик каты бәйлелекләре булуга карамастан, гаиләләрен һәм дусларын котылу фидьясы буларак тәкъдим итәрләр. Коръәндә бу хакыйкать шулай хәбәр ителә:

***(Мондый көндә) һичбер якын дус бер башка якын дустын сорамас. Алар бер-берсенә күрсәтелер. Бер гаепле-гөнаһлы ул көннең газабына каршылык итеп улларын фидья (фида) буларак бирергә теләр, үзенең хатыны һәм кардәшен һәм узен саклаган кавемне дә. җир йөзендә булганнарның барчасын (бирсә дә), соңыннан котылса. Юк, (һичберсе кабул ителмәс). Дөреслектә ул (Җәһәннәм) чытыр-чытыр янучы булган ут. (Мәариҗ сүрәсе, 10-15)***

Махшәр Көнендә инкярчылар тарафыннан ясалган бу фидья тәкъдиме аларның чын холыкларының беленүве ягыннан бик тә әһәмиятле. Дөньядагы иң якын мөнәсәбәтләрнең файда китерми һәм кешеләрнең мәнфәгатьләренә каршы килә башланганнан соң бөтен кыйммәте югалувы тагын бер кат расланды. Югыйсә, боларның барысы да буш тырышлык. Аллаһ кешеләрне бу малларга бары тик аларны имтихан итәр өчен генә варисчы кылган һәм бу малларга билгеле чикле заман билгеләгән. Бу вакыт тамамланганнан соң боларны фидья итеп бирергә теләүләре, инкярчылар аңлаешында булган бозыклыкны тагын бер кат күрсәтәчәк.

## ГАМӘЛ ДӘФТӘРЛӘРЕНЕҢ БИРЕЛҮВЕ

Кешенең дөнья тормышы буенча кылган һәрнәрсәсе уң һәм сул ягындагы фәрештәләре тарафыннан теркәлеп бара. Хисап вакыты өчен хәзерләнгән дәфтәрләр Дин Көнендә кешеләргә бирелер. Кеше кылганнарының һичберсен дә кире кага алмас, чөнки яшәгән һәр мизгел гамәл дәфтәренә язылган. Һәркем үзенең дәфтәреннән Ахирәт өченниләр хәзерләгәнен өйрәнер. Мөэминнәр дәфтәрләрен уң кулларына, кяферләр исә сул кулларына алырлар. Беркемгә дә зәррә (атом кадәр) кадәр хаксызлык та кылынмаган һәм горчица (хардал) данәсе кадәр гамәлнеңдә дә хисап ителүгән вакытында мөэминнәр белән кяферләрнең үз-үзен тотышлары бик аермалы булачак. Аллаһ аятьләрдә шулай боера:

***Сез ул көнне китереләчәксез, сезнең һичбер качырганыгыз серле булып калмаячак. Китабы уң кулына бирелгән әйтер ки: «Алыгыз китабымны, укыгыз. Чөнки мин чыннан да хисабыма ирешәчәгемне исәпләгән (белгән) идем». Инде ул хуш бер тормыш эчендә. Югары бер җәннәттә. Җыелачак (җимеш һәм ише булмаган уңыш)лары бик якын. Киредә калган көннәрдә, алда хәзер кылганнарыгызга каршылык буларак рәхәтлек белән ашагыз һәм эчегез. (Хакка сүрәсе, 18-24)***

Мөэминнәрнең сөенечләре һәм илһамлануларына каршылыклы буларак, кяферләр каһәрләүче бер оят һәм курку хис итәрләр. Кяферләрнең дәфтәрләре сул кулларына бирелер. Иң кечкенәсеннән алып иң зурысына кадәр һичбер эш теркәлмичә калмаган, фәрештәләр кирәктергәнчә язылган бу дәфтәр Аллаһ хупламаган эшләр белән тулы. Бу хакыйкать каршысында инкяр иткәннәрнең курку һәм шашкынлыклары аятьтә белдерелгән:

***(Алларына) Китап куелган, инде гаепле-гөнаһлыларның анарда булганнар сәбәпле дәһшәт белән куркуга бирелгәннәрен күрерсең. Диярләр ки: «Үкенечләр безгә, бу китапка ни булган ки, кечкенәне, бөекне калдырмыйча һәрнәрсәне санап белдерә». Кылганнарын (алларында) хәзер хәлдә тапканнар. Раббың һичкемгә дә золым итмәс. ( Кәһф сүрәсе, 49)***

Аллаһтан курыкмау, Аңа ширк кылу, Аңа гыйбадәт кылган күренеп, Аннан башкаларны разый итәргә тырышу, ялган, зина, отышлы уеннар һәм башка бик күп гөнаһлар бу дәфтәргә язылган. Аллаһны кирәгенчә белмәгәнлекләренрән, инкярчылар риялы әхлак белән дөньяда теләгәнчә яшәячәкләрен һәм теләнелгән гыйбадәтләрне генә кылуны бер гафу ителү чарасы буларак кулланачакларын саныйлар. Менә шулай Аллаһка гыйбадәт итмәгән яки иткән кебек күренгән һәркемне Хисап Көнендә курку тулы шашкынлык көтә. Чөнки гамәл дәфтәрләрендә ниятләре дә кертелгән. Хак ителгән каршылыкны алган инкярчыларның чарасызлык тулы үкенечләре әйткәннәреннән ачык буларак билгеле булыр. Коръәндә бу кешеләрнең ул вакыттагы дәһшәтләре шулай белдерелә:

***Китабы сул кулына бирелгән исә, ул да дияр ки:«Эх, миңа китабым бирелмәсә иде. Хисабымны һич белмәсә идем. Эх, ул (үлем һәрнәрсәне) туктатып бетерсә иде. Малым миңа һичбер файда бирмәде. Көч һәм кодрәтем юк булып китте.»(Хакка сүрәсе, 25-29)***

Аллаһка һәм Ахирәткә һичшиксез инанган, гомере буена хисап заманы өчен хәзерләнгән мөэминнәр белән Ахирәтне оныткан, Аллаһтан һәм мөэминнәрдән йөз боручы сул яктагы кешеләр арасындагы аерма тагын бер башка аятьтә шул рәвештә аңлатыла:

***Кемнең китабы арттан бирелә, ул да һәлакны (юк булуны) чакырачак, азгын, ялкынлы утка керәчәк. Чөнки ул дөньяда якыннары арасында сөенечле иде. Дөреслектә ул (Раббысына) тагын кайтмаячагын санады. Юк, чыннан да Раббысы үзен бик яхшы күрә иде. (Иншикак сүрәсе, 10-15)***

## УЛ КӨННЕ КЕШЕЛӘР СЫЙНЫФЛАРГА АЕРЫЛЫР

Аллаһтан кирәгенчә курыккан, сакланган һәм дөньяда Аның ризалыгы кирәктергәнчә яшәгәннәрнең көтелгән вакытлары килгән. Инанганнар Раббыбыз тарафыннан аларга вәгъдә ителгәннәргә

кавышуның бөек дулкынлануывын яшиләр. Кяферләр исә, тормышлары буенча яшәнелмәгән кадәр бөек, тасвирсыз бер дәһшәт эчендәләр. Иман иткәннәрдән тыш, бу дәһшәтне яшәмәячәк һичкем дә юк. Мөэминнәр белән кяферләрнең арасы аерылыр. Коръәндә бу көннең бер Аеру Көне дә булганлыгы шулай белдерелә:

***Бу сез ялганлаган (мөэминне кяфердән, хаклыны хаксыздан) аеру көне. (Саффат сүрәсе, 21)***

Коръәндә ул көнне кешеләрнең сыйныфларга аерылувы белдерелер. «Асхабульмәймәнәһ»升 буларак исемләндерелгән мөэминнәр бер группа. «**Асхабульмәшәмәһ**» исә, кяферләрдән торучы мөэминнәрдән аерылган группаны тәшкил итә. Болардан тыш мөэминнәр арасында Аллаһка якынлык һәм Аллаһ юлында күрсәтелгән тырышлык сәбәпле иң алгы сафларга үткәннәр бар ки, Коръәндә бу кешеләр «ярышып алга үтүчеләр» буларак исемләндерелә:

***Ул көнне йөзләр нурланып яктырылачак. Раббыларына карап торыр. Ул көнне шундый йөзләр бар ки, каралган, ачы карашлы. Аңа билне бөктерүче эшләр кылыначагын аңлата. (Кыямәт сүрәсе, 22-25)***

***Менә ул Асхабульмәймәнәһ, ни (котлыдыр ул) асхабульмәймәнәһ. Асхабульмәшәмәһ, ни (хәерсез һәм бәхетсез ул) асхабульмәшәмәһ . Ярышып алга үтүчеләр дә, алга үткән алдынгылар. Менә алар якынлаштырылган булучылар. (Вакиа сүрәсе, 8-11)***

## ҖӘҺӘННӘМНЕҢ КҮРСӘТЕЛҮВЕ

Ул көнне һәркем Аллаһка дөньяда кылганнарыннан хисап бирер. Җәһәннәмгә керeләчәген аңлап, курку эчендә булганнар, бик кыска бер гомерне мәңгелек бер тормышка алмаштырудан килгән соңсыз үкенеч эчендә. Алар үзләренә газапның кагылмаячагын, Кыямәт Көненең булмаячагын һәм Аллаһ аларны җәзаландырмаячагын санап, сүздә рәхәт

тормыш яшәгән вакытларында, Аллаһ аларны урап кушаткан һәм һич уйланылмаган вакытта тотып алган. Инде һәрнәрсә беткән һәм һәркемнең барачак урыны билгеле. Ләкин кешеләр шунда ук бер-берсеннән аерылмаслар. Мөэминнәр җәннәткә алып барылудан алда, аларга да кяферләр белән берлектә Җәһәннәм күрсәтелер. Ул көнне мөэмин яки кяфер булган бөтен кешеләр Җәһәннәм тирәсендә тез чүгәчәкләр. Һәркем Җәһәннәмнең курку салучы угылдавын ишетәчәк һәм эчендәге кылларны тырпайтырлык манзараларга шаһит булачак. Ләкин, соңыннан мөэминнәр коткарылачак һәм кяферләр тезләре өстендә чиккән килеш анда калдырылачак. Аятьләрдә бу хакыйкать шулай хәбәр ителә:

***Кеше әйтә ки: «Мин үлгәннән соң чыннан да тере буларак чыгарылачакмынмы?» Кеше, алдан һичбер нәрсә булмаган хәлдә, чыннан да Безнең аны яраткан булганыбыз турында (һич)уйланмый мы? Раббыңа ант булсын, Без аларны да, шайтаннарны да һичшиксез хәшер (кубарылу) итәчәкбез, соңыннан аларны Җәһәннәм тирәсендә тезләре өстендә чүккән килеш кылдырачакбыз. Соңыннан һәрбер группадан Рахман (булган Аллаһка) га каршы азгынлык күрсәтү буенча иң көчле булганына күрә аерачакбыз. Соңыннан Без аңа (Җәһәннәмгә) керүгә кемнәрнең иң лаек булганын тагын да яхшырак белербез. Сездән аңа кермәячәк һичкем юк. Бу Раббыңның каты буларак өстенә алган бер карары. Соңыннан такъва ияләрен коткарырбыз һәм золым кылганнарны тезләре өстендә чүккән килеш калдырырбыз. (Мәрьям сүрәсе, 66-72)***

Әлбәтә, мөэминнәргә Җәһәннәмнең күрсәтелүвендә бик күп хикмәт бар. Җәһәннәмнең хәлен якыннан күргән мөэминнәр Аллаһ тарафыннан аларга бирелгән иманның ни кадәр бөек бер аермалык һәм гүзәллек булганын аңларлар. Җәһәннәм шул кадәр дәһшәт бирүчедер ки, ул газаптан котылу кеше өчен тасвирсыз бәхет һәм шөкергә васиլә булган нәрсәләрдән. Мөэминнәр Җәһәннәмне күрү аркылы чагыштырма ясау мөмкинлегенә ия булырлар. Шулай итеп, үз эчендә кешегә биреләчәк иң гүзәл нигъмәтләрне булындыручы, мәңге калыначак җәннәтнең кыйммәтен тагын да яхшырак аңларлар. Чөнки нигъмәтнең кыйммәте барытик чагыштыру аркылы гына аңлашыла. Гүзәллекләр ягы җәннәт

нигъмәтләрнең кыйммәте, Аллаһ тарафыннан золым иткәннәргә биреләчәк каршылык күренгәч, тагын да яхшырак аңлашылыр. Имтихан ителү өчен килгәнебез дөньяның яратылу хикмәтләренең берсе дә - мәгариф. Кешеләр монда дөресне һәм ялганны, гүзәлне һәм ямьсезне, яхшыны һәм начарны берәр-берәр күреп һәм чагыштырып өйрәнерләр. Дөньда бу үзенчәлеккә ия булуның юлы тик акыл, вөҗдан һәм иң мөһиме дә, Аллаһ куркусы аркылы үтәр.

Кыямәт, яратылганнарның иң хәерлеләре булган мөэминнәр (Бәйинә сүрәсе, 7) белән яратылганнарның иң начарлары булган (Бәйинә сүрәсе, 6) инкярчыларның бер-берләреннән мәңгегә аерылу вакыты. Аерма Көне Көръәндә шулай белдерелә:

***Һәм рәсүлләр дә (шаһитлык өчен)билгеле бер вакытта китерелгәне заман. (Бу) кайсы көн өчен соңга калдырылган иде? (Мөэминне мөшриктән, хаклыкны хаксыздан) Аеру көне өчен. Бу аерма көнен сиңа кем белдерде? Ул көнне ялганлаганнарның вай хәленә. Без алдагыларны һәлак итмәдек ме? Соңыннан алардан соң килүчеләрне аларның эзеннән йөретәчәкбез. Менә Без гаепле-гөнаһлыларга болай эшлибез. Ул көнне ялганлаганнарның вай хәленә. (Мүрсәләт сүрәсе, 11-19)***

Бу Аерылу Көне үлем белән башлар, терелеш һәм хисап белән дәвам итәр һәм кешеләрнең мәңгелек йортларына юлланувы белән соңланыр. Каф сүрәсендә кяферләрнең һәм мөэминнәрнең мәңгелек йортларына таба кылынган юлчылыклары шулай аңлатыла:

***Ул үлем исереклеге бер хакыйкать буларак килеп тә, (кешегә): «Менә бу синең бер як сайлап качканың нәрсә», — (диелгәне заман да). Сурга да өрелгәндер. Менә бу кисәтүнең (тормышка ашкан) көнедер. (Инде) һәрбер нәфес янында бер куучы һәм бер шаһит белән килгән. Ант булсын, монардан гафләт эчендә идең. Менә Без дә синең өстеңдәге пәрдәне ачып күтәрдек. Инде бүген карашларың кискен. Аның якыны булган(һәм яныннан аерылмаган фәрештә) диде ки: «Менә бу янымда, хәзер халәттә булган нәрсә.» Сез икегез(әй фәрештәләр), һәр кирене,шөкерсезне атыгыз***

***Җәһәннәмнең эченә. Яхшыга комачау булганны, һөҗүмче шикчене. Ки, ул Аллаһ белән бергә башка бер иляһ таныды. Инде икегез аны иң каты газап эченә атыгыз.» Аның якын дусты юлдан яздыручы диде ки: «Раббыбыз, мин аны котыртып аздырдым. Әмма, үзе (хактан) ерак бер тайпылу эчендә иде.» (Аллаһ боерыр): «Минем хозурымда бәхәсләшеп тормагыз. Мин сезгә тагын да алданрак «каты бер уяру» җибәргән идем. Хозурымда сүз үзгәреш күрмәс һәм Мин колларыма золым итүче түгел.» Ул көнне Җәһәннәмгә диячәкбез: «Тулдың мы?» Ул да: «Тагын артыгы бармы?»-диячәк. Җәннәт тә такъвалар өчен озакта түгел, (ул көнне) якынлаштырылган .Бу сезгә вәгъдә ителгән, (күңелдән Аллаһка) юнәлгән, Рахманга каршы «эче тетрәп курку тойган» һәм «эчтән Аллаһка юнәлгән» йөрәк белән килгән өчен. Аңа: «хушлык һәм исәнлек (сәләм белән) кер!» диеләчәк. Бу соңсызлыкның көне. (Каф сүрәсе, 19-34)***

# ҮЛЕМ БЕЛӘН БАШЛАНГАН АСЫЛ ТОРМЫШ

Уртача 60-70 ел кыска бер гомерне Ислам хөкемнәре кушканча үткәргән мөэминнәр белән нәфесләренең теләкләре артыннан чабып, Аллаһны һәм Дин Көнен оныткан кяферләрнең каршылык буларак алачак нәрсәләре бик аермалы. Фәрештәләр мөэминнәрнең җаннарын гүзәллек белән алган хәлдә, кяферләрнең җаннарын авырлык белән чыгарырлар. Фәрештәләр мөэминнәргә сәлам биреп, аларны Җәннәт белән шатландырырлар. Аятьләрдә белдерелгәнчә, рухлары гәүдәләреннән йомшаклык белән алыныр. Инанган һәркеше качышы булмаганынлыгын белгән һәм шул сәбәпле тормышы буенча хәзерлек кылган мәңгелек тормышның керү ишеге дип саналган үлем белән каршылашкан. Инкярчылар исә, тормышлары буенча үзеннән качылган, барлыгы беленгән хәлдә, күрмәскә тырышылган үлем белән көчле тетрәнүләр эчендә каршылашырлар. Зәбанилар (Аллаһның газаплаучы фәрештәләре) кулларын аларга таба сузарлар, йөзләренә һәм аркаларына сугып, рухларын иң каты ачылар чиктереп тартып алырлар һәм аларны түбән итүче, яндыручы газапка җибәрерләр. Бер аятьтә шулай әйтелә:

***Фәрештәләрне аларның йөзләренә һәм аркаларына сугып: “Яндыручы газапны татыгыз!”, - дип, ул инкяр иткәннәрнең җаннарын алганда күрсә идең. (Әнфал Сүрәсе, 50)***

Мөэминнәр гомерләре буенча бу көн өчен хәзерләнгәннәр һәм Аллаһка Дин Көнендә аларны түбән төшермәве өчен дога кылганнар.

Али-Имран сүрәсенең 194 аятендә мөэминнәрнең бу догалары турында шулай хәбәр бирелә:

***“Раббыбыз, илчеләреңә вәгъдә иткәннәреңне безгә бир, Кыямәт көнендә безне хур һәм түбән кылма. Шиксез, Син вәгъдәңне бозмаучылардан.” (Али-Имран, 194)***

**Дин Көнендә яшәләчәкләр мөэминнәрдә Аллаһка карата куркуларын арттырыр. Ләкин, Аллаһ мөэминнәрне ул авыр көннең шәрреннән (зыяныннан) саклыячагын аятендә шулай белдерә:**

***“Чөнки без хәсрәтләндерүче авыр бер көн сәбәпле Раббыбыздан куркабыз.” Инде Аллаһ аларны мондый көннең шәрреннән саклаган һәм аларга нурлы бер яктылык һәм бер сөенеч биргән. (Инсан сүрәсе, 10-11)***

Аятьтә дә күренгәнчә, Аллаһтан курыккан һәм Ахирәт Көне өчен хәзерлек кылган мөэминнәр , кылынган хәзерлекнең каршылыгы буларак, Дин Көнендә булачак авырлыклардан сакланачаклар. Читен газап исә инкярчыларны көтә бирә.

## ДИН КӨНЕНДӘ МӨЭМИННӘРНЕҢ ХАЛӘТЕ

### <u>ФИЗИК ХАЛӘТЛӘРЕ</u>

***Ул көнне мөэмин ирләр белән мөэмин хатыннарның нурларын алларыннан һәм уңнарыннан хәрәкәт иткән килеш күрерсең. “Бүген сезнең шатлылыгыз эчендә мәңге калучылар (булганыгыз), астыннан елгалар аккан Җәннәтләрдер.” Менә бу – “бөек котылу һәм бәхет.” (Хадид сүрәсе, 12)***

***Дин көнендәге куркуга каршылык буларак, бөек бер иминлек эчендә булган мөэминнәрнең йөзләре көтелгән каршылыкны алуның иминлеге һәм шатлыгы белән нурланган: алар бәхет эчендә. (Абәсә сүрәсе, 39).***

Коръәндә мөэминнәр белән кяферләрнең йөзләре арасындагы аерма шулай аңлатыла:

***Гүзәллек кылганнарга тагын да гүзәле һәм артыгы бар. Аларның йөзләрен бер караңгылык та, түбәнчелек тә биләмәс. Менә алар - Җәннәтнең халкы; анда мәңге калачаклар. Начарлыкларны казанганнар исә, һәрбер начарлыкларның каршылыгы шундый ук булачак. Боларны түбәнчелек биләп алган. Аларны Аллаһтан (коткарачак) һичбер саклаучы юк. Аларның йөзләре караңгы кичәнең өлешләренә төренгән сыман. Менә болар – ут халкы; анда мәңге калачаклар. (Юныс сүрәсе, 26-27).***

Инкярчылар исә, иман иткәннәргә ялваралар. Дөньялыкта аларга каршы көрәшүләренә карамастан, хәзер аларның нурларыннан телиләр.

Бу нурның мәгънәсе – яктылык, иминлек һәм сөенеч. Бары тик Җәннәтне хак иткән кешеләрдә генә бар булган бу нурдан, инкярчылар никадәр теләсәләр дә, файдалана алмаячаклар. Бу нурның сәбәбе – дөньяда кылынган яхшы эшләр булганлыктан, һичбер изге гамәле булмаган инкярчының аңа ия булувы мөмкин түгел. Шул сәбәпле, мөэминнәр тарафыннан аларга “дөньяга кайтыгыз да, берәр нур эзләп табарга тырышыгыз” җавабы бирелер. Коръәндә бу тема белән бәйле булган шундый аять бар:

***Ул көнне мөнафыйкъ ирләр белән мөнафыйкъ хатыннар иман иткәннәргә әйтерләр ки: “(Ни булыр) безгә бер карагыз, сезнең нурыгызны бераз алып файдаланыйк.”.Аларга: “Кире (дөньяга) кайтыгыз да, берәр нур эзләп табарга тырышыгыз”, - диелер. Болар әйтелгәндә араларында ишеге булган дивар кырылыр; аның эчендә рәхмәт, тышкы ягында газап бар. (Хадид сүрәсе, 13)***

***Мөэминнәр дөньяда Аллаһ ризасы өчен күрсәтелгән тырышлыкларының каршылыгын алганнар. Бу тырышлыкларыннан да разыйлар. (Гашия сүрәсе, 9)***

Аллаһ аларга бөтен кылганнары өчен иң яхшы рәвештә каршылык биргән. Һәм алар тарафыннан көтелгән һәм өмет ителгән дә бу.

Шуңа күрә Аллаһка шөкер итәләр:

***“Безгә биргән вәгъдәсендә тугры калган һәм безне бу җиргә мирасчы кылган Аллаһка хәмед (шөкер) булсын ки, Җәннәттә теләгән җиребездә кала алабыз”, - диярләр. (Зүмәр сүрәсе, 74)***

## МӨЭМИННӘР АЛАЧАК КАРШЫЛЫК

***Инкяр итүчеләргә дөнья томышы тартучан кылынды (бизәлде). Алар кайбер иман иткәннәрдән көлерләр. Югыйсә, куркып сакланганнар кыямәт көнендә алардан өстен. Аллаһ теләгәненә хисапсыз ризык бирер. (Бакара сүрәсе, 212)***

Аятьтә дә күрелгәне кебек, күрмәгән хәлләрендә Раббыбыздын курку эчендә булган һәм Кыямәт Сәгатен эчләре тетрәп көткән мөэминнәр, ул көнне Аллаһ тарафыннан сакланган булачаклар. Мөэминнәрне Дин Көнендә иминлек эчендә булулары белән шатландыручы бер башка аять шундый:

***...Ул Көнне Аллаһ пәйгамбәрне һәм аның белән берлектә иман иткәннәрне түбәнчелеккә төшермәячәк. Нурлары алларыннан һәм уң якларыннан хәрәкәт итәр. Диярләр ки: “Раббыбыз нурыбызны бөтен кыл (тулыландыр), безне кичер. Шиксез, Син һәрнәрсәгә көч җиткерүче.” (Тахрим сүрәсе, 8)***

Инкяр иткәннәр ише күрелмәгән бер түбәнчелек эчендә булган вакытта, мөэминнәр Дин Көнендә һичбер курку тоймас. Аллаһ тарафыннан аларга вәгъдә ителгәнчә, кавышуның сөенечен һәм шатлыгын тоярлар. Уң яктан дәфтәрләрен алып, хозур эчендә Җәннәткә алып барылачак вакытны көтәрләр. Аллаһ аларга дөньяда һәм Ахирәттә һичбер нигъмәтне тыймаган, бөтенләй киресенчә, соңсыз нигъмәтләр белән җавап биргән, җаннарын гүзәллек белән алган һәм Дин Көнендә дә аларны саклаган. Араф Сүрәсенең 32 нче аятендә Аллаһ бөтен нигъмәтләрне мөэминнәргә бүләк иткәнлеген шулай белдерә:

***Әйт ки: “Аллаһ коллары өчен чыгарган зиннәтләрне***

***(матурлыкларны) һәм пакъ ризыкларны кем хәрам кылган?" Әйт ки: "Болар дөнья тормышында иман иткәннәр өчен, кыямәт көне исә бары тик аларныкы." Белгән бер туплылык өчен аятьләрне шулай бирәр-бирәр ачыкларбыз. (Араф сүрәсе, 32).***

***Хисап заманы бетеп, уты азгынлашып кызган Җәһәннәм үзләренә күрсәтелгәннән соң мөәминнәр Җәннәткә алып барылачак: Раббыларыннан куркып сакланганнар да Җәннәткә төркем-төркем алып барылдылар. Соңында анда киленгән заман, ишекләре ачылды һәм аларга (Җәннәтнең) сакчылары диделәр ки: "Сәлам сезгә, хуш һәм ару килдегез! Мәңге калучылар буларак анда керегез!" (Зүмәр сүрәсе, 73)***

Коръәндә мөэминнәр тарафыннан соңсыз Ахирәт тормышында алыначак бүләкләр детальле буларак аңлатылган. Тур сүрәсендә Мәңгелек Йортның нигъмәтләре болай санап үтелә:

***Һичшиксез, тәкъвалар җәннәтләрдә һәм нигъмәт эчендә. Раббыларының биргәннәре белән "Сөенечле һәм шат". Раббылары үзләрен "азгын янучы Җәһәннәмнең" газабыннан саклаган. Кылганнарыгыз сәбәпле ләззәтләнеп ашагыз һәм эчегез. Җентекләп төзелгән тәхетләр өстендә сөялгәннәр. Һәм Без аларны эре болан күзле хурилар белән өйләндергәнбез. Иман иткәннәр һәм иман итеп алар артыннан ияргән нәселләрне; Без аларның нәселләрен дә үзләренә куштык. Аларның гамәлләреннән һичбер нәрсәне кимсетмәдек. Һәр кеше - үзе казанганнарының әсире. Аларга теләнелгән җимешләрдән һәи иттән мул-мул бирдек. Анда бер-берсеннән кәсә алышырлар ки, анарда "ни буш, ни уйдырма сүзгә", ни гөнаһка этәрү юк. Алар өчен (хезмәт иткән) гыйльманнар (яшь егет хезмәтчеләр) тарафларын әйләнеп гизәрләр. (һәрберсе) перламутр савытта сакланган энҗе кебек чип-чиста, нурлы-нурлы. Бер-берсен сораштырырлар, әйттеләр ки: "Без чынлыкта элек гаиләбез (якын туганнарыбыз) эчендә хафаланып курка идек. Хәзер Аллаһ безгә мәрхәмәт кылды һәм эчкә үтеп яндыручы газаптан саклады. Шиксез, без моннан алда Аңа дога (коллык) итә идек. Чыннан да Ул – яхшылыгы күп, мәрхәмәте күп булучының нәкъ Үзе. (Тур сүрәсе, 17-***

*28)*

## КЯФЕРЛӘР АВЫР, МӨЭМИННӘР ҖИҢЕЛ ХИСАПКА ТАРТЫЛЫР

Дөньядагы тормышларында Аллаһ күрсәткән юлны ташлап, үзләренең теләк һәм хисләренә ияреп яки эчендә булган җәмгыятьләренең яңлыш кыйммәтлекләре һәм инанулары буенча яшәгән инкярчыларның хисабы бик тә авыр булачак. Ул көнне аларга карата ни бер кызгану, ни берәр шәфкать бар, ни дә газапларын җиңеләйтәчәк берәр көч... Моның иң бөек сәбәбе, аларга дөньяда булган вакытларында Аллаһның барлыгын хәтерләтүчеләр килүләренә карамастан, Аллаһ билгеләгән чикләрне бозулары һәм дөньяга кире кайтсалар да хәтта, кире бозылачак булулары. Бу Көръән аятьләре белән хәбәр ителүче ачык бер хакыйкать:

***Ут алдында туктатылганнарында аларны бер күрсә идең. Диярләр ки: "Эх, (дөньяга тагын бер) кире кайтарылса идек тә, Раббыбызның аятьләрен ялганламаса идек һәм мөэминнәрдән булса идек." Юк, элек яшеренгәннәр аларга ачыкланды. Әгәр (дөньяга) кире кайтарылсалар да, аларга тыелган нәрсәләргә, шиксез, кире кайтачаклар. Чөнки алар чыннан да кяферләр. (Әнгам сүрәсе, 27-28)***

Хисапларын биргән вакытларында аларны бер яктан кыздырылган Җәһәннәм көтәр. Бөтен кылынган гамәлләре һичбер кимчелексез исәпкә алынып, кылганнарының каршылыгын күрер өчен Җәһәннәмгә алып барылачаклар. Бер аятьтә бу бөек Хисап шулай аңлатыла:

***Сәхифәләр (гамәл дәфтәрләре) ачылган заман, күк тартып куптарылган заман, Җәһәннәм уты азгынча кыздырылган заман, Җәннәт тә якынлаштырылган заман. (Инде һәр) Нәфес ни хәзерләгәнен белеп өйрәнгән. (Тәквир сүрәсе, 10-14)***

Мөэминнәр өчен бик тә җиңел хисап булачагы Иншикак сүрәсендә болай белдерелгән:

***Әй кеше, чынлыкта син һич тукталмыйча Раббыңа карата***

***тырышлык кылып торасың. Соңында Аңа барачаксың. Инде кемнең китабы уң ягыннан бирелсә, аңардан җиңел хисап (сораштыру) белән сорау алыначак. Һәм ул якыннарына сөенеч эчендә кайткан булачак. (Иншикак сүрәсе, 6-9)***

Мөэминнәр дөньядагы тормышларын аларны яраткан һәм дөреслеккә юнәлткән Раббыбыз теләгән рәвештә яшәгәннәр. Гөнаһларын исә, соңсыз мәрхәмәт иясе булучы Аллаһ гафу итәчәк. Аллаһ күп кенә аятьләрендә иман итеп, изге гамәл кылганнарның гөнаһларын яхшылыкларга әверәчәген, ярлыкаячагын белдерә. Ул көнне Раббыбыз вәгъдә иткәннәргә кавышкан мөэминнәргә Аллаһ шулай боера:

***Әй мутмаин (тынычлык тапкан) нәфес, Раббыңа риза итүче һәм риза булган килеш кайт. Инде колларым арасына кер. Җәннәтемә кер. (Фәҗр сүрәсе, 27-30)***

Шулай итеп мөэминнәр, аларга Аллаһ тарафыннан бирелгән фазыйләт һәм яхшылык сәбәпле соңсыз ут газабыннан котылырлар һәм Раббыбызның чиксез нигъмәтләре белән тулы булган Җәннәткә кавышырлар. Үзенә: “Җәннәткә кер”, - диелгән мөэминнең җавабы Коръәндә шулай хәбәр ителә:

***(Алар да) диделәр ки: “Безгә биргән вәгъдәсендә тугры калган һәм безне бу җиргә мирасчы кылган Аллаһка хәмед (шөкер) булсын ки, Җәннәттә теләгән җиребездә кала алабыз. (Изге) гамәлләр кылганнарның әҗере ни гүзәл!” (Зүмәр сүрәсе, 74)***

## ДИН КӨНЕНДӘ ИНКЯРЧЫЛАРНЫҢ ХАЛӘТЕ

### ФИЗИК ХАЛӘТЛӘРЕ

Дин Көнендә кешеләр яңа бер яратылуга ия булачаклар. Шуңа күрә, мөэминнәрнең йөзләре иман нурын һәм гүзәллеген ташыган вакытта, кяферләр “ямьсезләндерелгәннәр”:

***Бу дөнья тормышында алар артыннан ләгънәт йөреттек. Кыямәт Көнендә исә алар ямьсезләндерелгән булучылар. (Касас сүрәсе, 42)***

Тагын бик күп аятьләрдә ул көнне инкярчыларның йөзләрен тузан, түбәнчелек һәм каралык каплаганлыгы, йөзләренең кап-кара булганлыгы белдерелгән:

***Һәм ул көнне шундый йөзләр дә бар ки, өстенә тузан утырган. Бер караңгылык төреп каплаган. Тәкәбберләнгәннәр өчен Җәһәннәмдә калыр урын юкмы? (Зүмәр сүрәсе, 60)***

Йөзләрдәге бу физик яктан булган ямьсезләнү метафизик бер халәт. Аллаһ теләгәнчә яшәп, намуслы бер тормышны хуп күрмәгән бу кешеләр, нәфесләренә ияргән вакытларында, асылында, түбәнчелеккә төшүне сайлаганнар. Нәфескә иярүнең, вөҗданга каршы килүнең ямьсезлеге һәм намуссызлыгы өсләрендә. Менә шул сәбәпле "түбәнсетелгәннәр" буларак Җәһәннәмгә сөрелгәннәр.

***Әгәр Без теләсә идек, аны моның белән күтәрер идек. Әмма, ул җиргә янтайды (яки җиргә кадалды), нәфесенә иярде. Аның халәте, өстенә килсәң телен асып сулаган, ялгыз калдырсаң телен асып сулаган эт халәте кебек. Менә аятьләребезне ялганлаган җәмгыятьнең халәте шулай. Инде хак хәбәрне аларга ирештер ки, уйлансыннар. (Араф сүрәсе, 176)***

Нәфеснең иң кечкенә теләкләренә дә бирелгән бу кешеләр, дөньядагы тәкәбберләнуләренең каршылыгын Ахирәттә түбәнсенү буларак алачаклар. Гашия сүрәсенең 2нче аятендә бары тик физик ямьсезлекләреннән генә түгел, шул ук вакытта түбәнсетелгән булуларыннан да сүз ителә:

***Ул көнне шундый йөзләр бар ки, "түбәнсетелгәннәр". (Гашия сүрәсе, 2)***

Кисәтүләргә карамастан, аятьләргә игътибар итмәгән, алар буенча яшәүне кирәк дип тапмаган һәм хәлләрен төзәтмәгән инкярчылар,

ул вакытта һич көтелмәгән түбәнчелекле һәм чарасыз халәткә төшүләренең шашкынлыгын яшәрләр. Аллаһның аятьләрен кире кагып, нәфесләренә күрә кәефле тормыш сайлаучылар Коръәндә белдерелгән газапны бу үз тормышлары аркылы хак итәрләр. Бу кешеләрнең Хисап Көнендә төшәчәк хәлләре бик тә авыр. Аллаһ, һичшиксез, хаклык белән хөкем итүве һәм гаделлеге сәбәпле вәгъдәсен үтиячәк. Аятьләрдә шулай боерыла:

***... Кыямәт көнне Без аларны йөзасты буларак сукырлар, телсезләр һәм саңгыраулар буларак хәшер итәрбез. Алар барачак урын Җәһәннәм, уты басыла башлаганда азгын ялкынын аларга арттырырбыз. (Исра сүрәсе, 97)***

***Ул да (шулай) дигән булыр: "Мин күрүчеләрдән берсе булган хәлдә, мине нигә сукыр буларак хәшер иттең, Раббым?". (Аллаһ та) әйтер ки: "Менә шулай сиңа аятьләребез килгән иде, фәкать син аларны оныттың, менә шулай син дә бүген онытылачаксың." (Таһа сүрәсе, 125-126)***

Коръәндә ул көнне түбәнчелек сәбәпле дә кяферләрнең күзләре төшенке булачагы шулай белдерелгән:

***Күзләре "түбәнчелек һәм дәһшәттән төшенке буларак", "таралган" саранчалар сыман каберләреннән чыгарлар. (Камәр сүрәсе, 7)***

Кяферләрнең сукыр һәм түбәнчелектән төшенке булган күзләре дә күренешләрендәге куркынычлыкны һәм җирәнгечлекне арттырыр. Түбәнчелекле караш һәм дәһшәт бирүче күренеш - ул көнне инкярчыларга бирелгән үзенчәлек. Аллаһ Та-һа сүрәсендә бу кешеләрне шулай тасвирлый:

***Сурга өреләчәк көн. Без гаепле-гөнаһларны ул көнне (йөзләре кара, күзләре) зәп-зәңгәрләнгән (кап-каты һәм сукыр) буларак туплаячакбыз. (Та-һа сүрәсе, 102)***

Тагын Коръәндә, Аллаһ җибәргән илчеләргә һәм аятьләренә

каршы тәкәбберләнгән бу кешеләрнең, Дин Көнендә борынларына тамга сугылачагы белдерелгән:

***Якында Без аның фил борынына тамга сугачакбыз. (Камәр сүрәсе, 16)***

Бу халәт, дөньяда булган вакытларында хаксыз рәвештә тәкәбберләнгән кешеләр өчен бөек түбәнчелек. Борыннарының фил борыны буларак тасвирлануы һәм борыннарына җирәнгечлекләрен арттыручы тамгаларның сугылувы, инкярчыларның Ахирәттәге ямьсезлекләре һәм төшкән түбәнчелекләре турында аңлату өчен җитә. Ахирәттә соңгы дәрәҗәдәге рәхәт урыннарда яшәгән мөэминнәргә каршылык буларак, инкярчылар дәвамлы түбәнчелекле бер тормыш башлаганнар инде. Мөэминнәр һәм кяферләр арасындагы бу аерма аятьләрдә шулай белдерелә:

***Ул көнне йөзләр нурланып яктыртылачак. Раббыларына карап торыр. Ул көнне шундый йөзләр бар ки, каралган, ачы карашлы. Аңа билне бөктерүче эшләр кылыначагын аңлата. (Кыямәт сүрәсе, 22-25)***

Качырга да, сакланырга да мөмкинчелекләре юк. Аллаһ Коръәндә, күренешләре белән шунда ук танылган кяферләрнең, маңгайларыннан һәм аякларыннан тотылып Җәһәннәмгә атылганнарын шулай белдергән:

***(Чөнки ул көнне) гаепле-гөнаһлылар йөзләреннән танылыр да, маңгайларыннан һәм аякларыннан тотылырлар. (Рахман сүрәсе, 41)***

## СӨЙЛӘШҮЛӘРЕНӘ РӨХСӘТ БИРЕЛМӘС

Инкярчылар ул көнне тормышларында булган һәм онытылган һәр хәрәкәтнең ачыкланачагын, фаш булачагын тасвирсыз шашкынлак һәм үкенеч белән каршыларлар. Коръәндә әйтелгән "әгәр" яки "үкенеч безгә" кебек сүзләре, ташыган үкенечләрнең, асылында, бер файдасы да

булмаганлыгын белгәннәрен күрсәтер. ***“Үкенеч безгә, әгәр Аллаһка итәгать итсә идек  һәм илчегә итәгать итсә идек” (Аһзап сүрәсе,66)*** диеп үкенгән бу кешеләрнең, шикаять һәм акланууларының инде һичбер яраклыгы юк. Ялваруларына, елауларына, ачы тулы кычкыруларына һәм ярдәм чакыруларына Аллаһтан биреләчәк каршылык шул рәвештә аңлатылган:

***Әйтелде ки: “Бу көнегез белән каршылашуны оныткангыгыз кебек, Без дә сезне бүген онытабыз.”(Җасия сүрәсе, 34)***

Боларга карамастан, сүз иткәнебез кешеләр Аллаһтан теләүләрен дәвам итәрләр. Бер өлеше Аллаһтан юк булуны теләр. Бер өлеше каршылашкан газабыннан котылувы өчен ия булганын фидья буларак бирергә теләр. Бер өлеше, дөньяга кире кайтып, кылганнарын төзәтергә теләрләр. Коръәндә бу кешеләрнең изге гамәлләр кылулары өчен дөньяга кире кайтарылу теләкләре шул рәвештә аңлатыла:

***Гаепле-гөнаһлыларны Раббылары хозурында башларын иеп: “Раббыбыз күрдек һәм ишеттек, хәзер безне (тагын бер тапкыр дөньяга) кире кайтар, изге берәр гамәл кылыйк, инде без чыннан да каты иттереп инанганнардан”, - (дип ялварган вакытларында) бер күрсәң. (Сәҗдә сүрәсе, 12)***

Бу ялварулары аларны кушатып алган куркыныч газаптан котыла алулары өчен. Югыйсә, дөньяга кире кайтарылсалар да хәтта, инкярчылар элеккеге үз тотышларын һич тә үзгәртмәячәген Аллаһ белдерә. Бу кешеләр өчен инде һичбер рәвештә котылу юк. Кяферләр үзләрен яраткан һәм яшәткән Аллаһка гыйсъян кылулары аркылы була алырлык иң олы җинаятьне кылганнар. Шул сәбәпле, Хисап Көнендә үзләрен яклауларына да рөхсәт бирелмәс. Аллаһ моны аятьләрдә шулай белдерә:

***Ул көнне ялганлаганнарның вай хәленә! Бу алар сөйләшмәячәк  бер көн. Һәм аларга акланууларын аңлатыр өчен рөхсәт бирелмәс. Ул көнне ялганлаганнарның вай хәленә! (Мүрсәләт сүрәсе, 34-37)***

Тагын Коръәндә Аллаһның инкярчыларның кылганнарына

каршылык итеп, Дин Көнендә бу кешеләр белән сөйләшмәячәге, аларны күзәтәчәге һәм арындырмаячагы (кичермәячәге) аңлатылган. Тема белән бәйле аятьләрнең кайберләре шундый:

***Аллаһ иңдергән Китаптан берәр нәрсәне мөһимсенмичә яшергәннәр һәм аның белән бәясе әз (берәр нәрсәне) сатып алганнар; аларның ашаганнары карыннарындагы уттан башкасы түгел. Аллаһ кыямәт көнендә алар белән сөйләшмәс һәм аларны арындырмас (кичермәс). Һәм алар өчен каты газап бар. (Бакара сүрәсе, 174)***

***Аллаһ солыхын һәм антларын әз бер бәягә каршылык итеп сатканнар... Менә алар. Алар өчен Ахирәттә һичбер пай (өлеш) юк. Кыямәт көнендә Аллаһ алар белән сөйләшмәс, аларны күзәтмәс һәм аларны арындырмас. Һәм алар өчен каты газап бар. (Али Имран сүрәсе, 77)***

***Дияр ки: "Аның эченә сеңегез һәм Минем белән сөйләшмәгез!" (Мүэминүн сүрәсе, 108)***

Кешеләр ачуын Аллаһның кяфер иткәннәргә карата булган ачуы белән чагыштырып булмый. Кеше никадәр ачуланса да, моның соңында бирелә алачак җәза чикле. Югыйсә, Аллаһның газабы тасвир ителмәячәк кадәр бөек. Газапның масштаблары кеше акылының һәм хыял көченең ирешә алмаячак дәрәҗәсендә. Коръәндә бу хакыйкатькә шулай ишарәт ителә:

***Шиксез, кяфер иткәннәргә дә (шулай) эндәшелер: "Аллаһның газаплавы, әлбәттә, сезнең үзегезнең нәфесләрегезгә булган газаплавыгыздан тагын да бөек. Чөнки сез иманга чакырылган вакытыгызда инкяр итә идегез." (Мөэмин сүрәсе, 10)***

## <u>КУРКУ ЭЧЕНДӘ БУЛУЛАРЫ</u>

Инкярчыларда мәңге дәвам иткәчәк курку һәм үкенечләре үлем

фәрештәләренең җаннарын алырга килүве белән башлар. Фәрештәләргә тотылганнан соң һичбер инкярчы качырга да тырышып карамас. Чөнки бу ахыргы тотып алыну һәм үлем белән берлектә мәңгелек тормыш ишегеннән керү ясалган инде.

Менә бу вакытта тасвирлана алмаган бер курку бөтен минлекләрен биләр һәм дөньяда булганда аларга белдергән газап хакыйкатенең беренче мизгелләренең башланганын аңларлар. Аллаһ Әнъам сүрәсендә шулаһ боера:

***...Син бу залимнәрне улемнең "каты тетрәнүләре" вакытында фәрештәләрнең аларга кулларын сузып: "Җаннарыгызны (бу бик газаплы тотылу аркылы) чыгарыгыз, бүген Аллаһка каршы хаксыз булганны сөйләгәнегез һәм Аның аятьләреннән тәкәбберләнеп (борылганыгыз) сәбәпле, түбәнсетүче бер газап белән каршылык күрәчәксез", - (дип әйткәннәрендә) бер күрсәң... (Әнам сүрәсе, 93)***

Дөньяда казанган бөтен байлыкларын артта калдырганнар. Ул көнне ия булган һичбер нәрсәләренең мәгънәсе юк. Казанганнар да, ышанылмаганнар да һичкемгә бер файда да китерми инде. Аятьтә белдергәнгә күрә, Аллаһ хозурында "яп-ялгызлар":

***Ант булсын, сезне беренче тапкыр яратканыбыз кебек, (бүген дә) "берәр-берәр, яп-ялгыз һәм ялангач (килеш)" Безгә килдегез һәм сезгә биргәннәребезне артта калдырдыгыз. Сез чыннан да ширек буларак санаган шәфәгатьчеләрегезне хәзер яныгызда күрмибез. Ант булсын, арагыздагы (мөнәсәбәтләр) бетеп өзелгән һәм хакларында заннар кылганнарыгыз сездән ерагайтылган. (Әнам сүрәсе, 94)***

Инкярчылар куллары һәм аяклары бәйләнгән сыман. Дөньяда бик яраткан, теләгән һәрнәрсәләрен эшләткән дип уйланылган, аларның теләкләре өчен кулланылган гәүдәләренә дә сүзләре үтмәс, хуҗа була алмаслар. Кылырга теләгәннәрен һичтөрле кыла алмаслар. Һәм Коръәндә бу кешеләрнең ул көнне сәҗдәгә чакырылачагы, фәкать хәтта сәҗдә

итәрлек тә көчләре булмаганлыгы белдерелгән:

***Аяк өстеннән (пәрдә) ачылачак һәм алар сәҗдәгә чакырылачак көн, инде көч җиткермәсләр. Күзләре “куркудан һәм дәһшәттән төшенке”, үзләрен дә түбәнчелек биләп кушаткан. Югыйсә, алар (алданрак) сау-сәламәт чакларында сәҗдәгә чакырыла иделәр. (Каләм сүрәсе, 42-43)***

Һәрнәрсәнең хуҗасы Аллаһ һәм һәрнәрсә Аның теләге белән була. Инкярчыларның сәҗдәгә чакырылуларының сәбәбе, дөнья томышлары буе моны кылмыйча калдырып баруларыннан, аларның газап һәм үкенеч хис итүләрен булдыру. Алданрак тәкәбберләнеп Аллаһка сәҗдә итүне кире каккан бу кешеләр, ул көнне теләгәннәре хәлдә моны кыла алмаячаклар. Инде хисап бирерләр һәм Җәһәннәмгә юлланырлар.

## <u>ҮКЕНЕЧ</u>

***Аллаһка кавышуны ялган санаганнар, дөресе, хәсрәткә тап булганнар. Шулай ки, сәгать (Кыямәт көне) көтмәгәндә аларга килгәч, гөнаһларын сыртларына йөкләп: “Анда (дөньяда) җавапсыз буларак кылганнарыбыз сәбәпле үкенеч безгә!”,– диярләр. Игътибар итегез, ул эшләп йөкләгәннәре никадәр начар. (Әнам сүрәсе, 31)***

Кеше яшәеше буе еш-еш үкенеч тояр. Кылганнарын төззәтү мөмкинчелеге дә бар. Әмма, нигәдер тәкәбберлеге сәбәпле һич тә төзәлергә тырышмый, дөреслеккә таба һичбер заман юнәлми. Чөнки үзен иң дөресне белүче дип исәпли, шул сәбәпле дә һәр үгеткә колакларын каплый. Әмма, ул көнне кеше дөньядагы бу үз тотышыннан бик каты үкенеч тоячак. Ләкин, тоелган бу үкенеч өчен инде берни кылып булмый. Инкярчылар ул көнне кылганнарын төзәтү өчен чыдый алмаслык теләк тоярлар. Аллаһка үзләрен дөньяга кире кайтарувы өчен ялварырлар. Дөньяда ия булган малларының, улларының, хатыннарының, йолаларының, берәр фундаменты булмаган килеш якланган фикерләренең ни дәрәҗәдә мәгънәсез һәм яраксыз булганын, бары тик Аллаһ өчен генә

кылынган эшләрнең кыйммәте булганын бөтен килеш аңларлар. Ләкин, бу аңлауның аларга инде бер файдасы да юк.

Араларыннан бер өлеше горурлыклары сәбәпле, хәтта шундый дәһшәтле вакытта да үкенечләрен яшерергә тырышырлар. Моны хәбәр итүче аятьтә шулай әйтелгән:

***Золым иткән һәр нәфес җир йөзендәгеләрнең бөтенесенә ия булса, шиксез, моны (газапка каршылык итеп) фидья буларак бирер иде. Алар газапны күргәч үкенечләрен яшерерләр, югыйсә, алар хаксыслык ителмичә, араларында гаделлек белән хөкем ителгәннәр. (Йунус сүрәсе, 54)***

Гаепләрен белүләренә карамастан, моны билгеле итмәсләр. Югыйсә, күрелгән каршылык бөтенләй хак ителгән рәвештә һәм Аллаһ гаделлегенең бер нәтиҗәсе. Аллаһ ул көнне иман иткәннәр белән инкяр иткәннәрне кискен рәвештә бер-берсеннән аерыр. Инкярчылар тарафыннан Җәһәннәмгә керүгә хәтле каршылашылган һәр вакыйга, тугры юлны калдырып, шайтанның юлын сайлаулары сәбәпле. Бу өркетүче каршылыкны чыннан да хак итәрләр:

***Кем берәр начарлык белән килсә, инде алар утка йөзләре түбән килеш атылыр (һәм аларга): "Кылганнарыгыздан башкасы белән җәзаландырыласызмы?" (диелер). (Нәмл сүрәсе, 90)***

Үкенечне булдыручы бик күп сәбәп бар. Газап белән каршылык күргәннәр яп-ялгызлар, хәтта үзләренең тиреләре дә аларга каршы шаһитлек кыла, ямьсезләнгәннәр һәм мәңгелек газапның дәһшәтен хис итәләр. Җәһәннәмне күргәннәр һәм нинди дәһшәт белән каршылашканнарын соңында аңлаганнар. Дөньяда үзләренә сукырларча бәйләнелгән һәм ышанылган ялган иляһлары инде берәр төшнең бетүве кебек юк булган. Алар шайтанның юлыннан бөек бер катылык белән барганнарына карамастан, шайтан да аларны яп-ялгыз калдырган. Шайтанның сүзләре Коръәндә шулай хәбәр ителә:

***Эш хөкемгә бәйләнеп беткәч, шайтан дияр ки: "Дөресе,***

***Аллаһ сезгә чын булган вәгъдәне вәгъдә итте, мин дә сезгә вәгъдәдә булдым, фәкать сезгә ялган сөйләдем. Минем сезгә карата мәҗбүр итүче берәр көчем юк иде, барытик сезне чакырдым, сез дә миңа җавап бирдегез. Алайса мине гаепләмәгез, сез үзегезне гаепләгез. Мин сезне коткарачак түгел, сез дә мине коткарачак түгел. Дөресе, элек миңа табынуыгызны да танымыйм." Хакыйкать шул ки, залимнәргә әрнетүче бер газап бар. (Ибраһим сүрәсе, 22)***

Мөэминнәр ул көнне инкярчылар төшкән бу чарасыз халәтне тамаша кылачаклар, яшәлгән түбәнчелекләре нәтиҗәсендә башларын игән кяферләр исә, оялу һәм үкенечтән мөэминнәргә бары тик күз очы белән генә карый алачаклар. Бу хакыйкать бер аятьтә шулай белдерелә:

***Аларны күрерсең; түбәнчелектән башларын игән бер хәлдә, аңа (утка) алып барылганнарында күз очы белән сиздермичә карарлар. Иман иткәннәр дә: "Чыннан да, хәсрәткә тап булучылар кыямәт көнне һәм үз нәфесләрен һәм якын туганнарын (яки янындагыларын) да хәсрәткә этәргәннәр", - диделәр. Хәбәрегез булсын, чыннан да, залимнәр калучы бер газап эчендә. (Шуара сүрәсе, 45)***

Ахирәттәге үкенеч, шиксез, дөньядагы үрнәкләре белән берәр чагыштыруга урын калдырмаячак дәрәҗәдә бөек. Кире кайту мөмкинчелеге булмау, чарасызлык үкенече яшәлә. Инде һичбер рәвештә үзгәртелмәячәк бер соңның килгәнен, моның авыр йөген җилкәләрендә хис итәрләр. Бу нәтиҗә һәм үкенеч бөек бер хатаның нәтиҗәсе. Бу кешеләр үзләрен яраткан һәм һәркайда да дөньяны бөтен нигъмәтләре белән берлектә әмерләренә, ихтиярларына биргән Аллаһны инкяр итүдә кыюлык күрсәткәннәр. Сайланылган бу инкяр юлы Ахирәттәге барылачак урынны билгеләгән. Бу урын – Җәһәннәм. Хәтта акылларына да китерергә теләнелмәгән һәртөрле хәсрәтнең, газапның, кайгының мәңге яшәләчәк урыны ул. Аллаһның газабы бөтен бөеклеге белән каршыларында инде.

## ҮЗЛӘРЕ АРАСЫНДА БӘХӘСЛӘШҮ

***Анда бер – берләре белән бәхәсләшеп диярләр ки: "Ант булсын Аллаһка, без чыннан да ап-ачык бер тайпылу эчендә булганбыз, чөнки сезне (ялганчы булганнарны) галәмнәрнең Раббысы белән тигез тота идек. Безне гаепле-гөнаһлардан башка тайпылдыручы булмады. Инде безнең өчен ни берәр шәфәгатьче бар, ни дә җандан якын дус. Безнең бер тапкыр тагын (дөньяга кайтувыбыз мөмкин) булса иде дә, иман иткәннәрдән булса идек." Чыннан да монарда бер галәмәт бар, әмма аларның күпчелеге иман иткәннәрдән түгел. (Шуара сүрәсе, 96-103)***

Инкярчылар ул көнне һич көтелмәгән бөек газап белән каршылашырлар. Халәтләре сәбәпле алар һәм үзләренә, һәм дә аларны Аллаһ юлыннан ераклаштырган кешеләргә карата бөек бер ачу тоярлар. Дөньяда булган вакытларында иң мөһим максатларыннан берсе дип саналган дәрәҗә һәм өстенлекләренең , ул көнне һичбер мәгънәсе калмаган.

Инкарчылар ул көнне үзләрен дөрес юлдан тайпылдырган лидерларына карата да бөек бер ачу тоярлар. Дөньядагы вакытларында артларыннан чабылган бу кешеләреннән качып ераклашырга тырышырлар . Үзләре артыннан иярелгән кешеләр белән ияргән кешеләр арасында ул көнне бәхәсләре аятьләрдә шулай аңлатыла:

***Шулай ки, (ул көнне ) үзләренә ияргән үзләренә иярелгәннәрдән ераклашып качканнар. (Инде) алар газапны күргәннәр һәм араларындагы бөтен бәйләнеш (һәм мөнәсәбәтләр) дә җимерелеп купкан. (Ул вакытта юнәлтелеп) ияргәннәр диярләр ки: "Әгәр безгә бер тапкыр (тагын дөньяга кайту) форсаты бирелсә иде, һичшиксез (хәзер) аларның бездән ерагайганнары кебек , без дә алардан ерагаер (аларны ялгыз калдырыр) идек." Шулай итеп Аллаһ аларга бөтен кылганнарын бөек туктатылмас хәсрәтләр белән күрсәтәчәк. Һәм алар уттан чыгачак түгел. (Бакара сүрәсе, 166-167)***

***Йөзләре утта әйләндереләчәк көнне дияр ки: “Үкенеч безгә, әгәр Аллаһка итагать итсә идек һәм Рәсүлгә итагать итсә идек.” Һәм әйттеләр ки: “Раббыбыз, чыннан да без хуҗаларыбызга һәм бөекләребезгә итагать иттек, шулай итеп алар безне юлдан тайпылдырган булдылар. Раббыбыз, аларга газаптан ике катын бир һәм бөек ләгънәт белән ләгънәт ит.” (Ахзап сүрәсе, 66-68)***

Аллаһ Көрьәндә дөньяда кешеләрне ялгыш юнәлдергән һәм Аллаһка иманудан ераклаштырган факторлар арасында “алда килүчеләрнең” факторына да ишарәт иткән. Аллаһ билгеләгән үлчәүләргә күрә түгел дә, кешеләр билгеләгәннәренә күрә “өстен” кабул ителгән бу кешеләр, аларга иярген кешеләргә бик нык тәэсир иткәннәр. Бу ияру нәтиҗәсендә кешеләр тарафыннан аларга уйланылмыйча бәйләнелгән лидерлар аларга дөньяның вакытлыча кыйммәтлекләре өчен яшәүне өйрәтә һәм буш тырышлыкларга этәреп, аларның игътибарын ала. Ләкин, ни үзләре, ни дә ияручеләр дөньяда эшләнгән хатаны аңлый алганнар. Аллаһка каршы килеп бер-берсен дистәкләгәннәр. Бу бөек ялгышу уртага чыккан көнне бер – берсен гаепли башларлар. Бу гаепләүләргә карамастан, һәр ике тараф та Җәһәннәмнән чыгарылмаячак.

Аллаһ үзләренә ияручеләрне дөрес юлдан тайпылдырган бу лидерларны Көрьәндә шулай тасвирлый:

***Без аларны утка чакыручы алдынгылар буларак кылдык, кыямәт көнне ярдәм күрмәсләр. Бу дөнья тормышында алар артыннан ләгънәт йөреттек. (Касас сүрәсе, 41-42)***

***Ул кыямәт көнне кавеменең идарәчесе булыр, шулай итеп аларны утка алып барган булыр. Соңында барганнары урын, ни кадәр начар урын. (Худ сүрәсе, 98)***

Ул көнне инкярчылар дөньяда бөек тугърылык белән бәйләнелгән лидерлары белән араларында көнчыгыш белән көнбатыш арасындагы кебек ераклык булувын теләячәкләр. Бу хакыйкат “Зухруф” сүрәсендә шулай хабәр ителә:

***Кем Рахман (булган Аллаһ)ны искә төшерүдән баш тартса, Без аның берәр шайтанга "кабыгы белән бәйләрбез", инде бу аның бер якын дусты. Чыннан да, болар (бу шайтаннар) аларны юлдан яздыра, алар исә үзләрен чыннан да дөрес юлда булганын санырлар. Соңында безгә килгән вакытта дияр ки: "Әгәр минем белән синең арада ике көнчыгыш (көнчыгыш белән көнбатыш) ераклыгы булса иде. Ни кадәр начар якын дус (икәнсең син)!" ( Бу сөйләнүләрегез) бүген сезгә бернинди файда да китермәс. Чөнки золым иттегез. Шиксез, газабыгыз да уртак. (Зухруф сүрәсе,36-39)***

Ул көнне кешеләр дөньяда бик яратылган, ышанылган, бөек бер теләк белән бәйле булган кешеләрнең бер өлешен танымаячаклар, бер өлеше инкар ителәчәк, хәтта аларны ләгънәт тә итәчәкләр. Аяттә шулай әйтелә:

***(Ибраһим) диде ки: "Чыннан да сез Аллаһны калдырып, дөнья тормышында арагызда бер сөю бәйләнеше булган потларны иляхлар иттегез. Соңыннан кыямәт көнендә берегез берегезне инкяр итеп танымаячак һәм берегез берегезне ләгънәт итәчәксез. Сезнең калачак урыныгыз ут һәм һичбер ярдәмчегез юк. (Анкәбут сүрәсе, 25)***

Аллаһны онытып, Анардан башкасын риза итәргә тырышып гомерләрен кичергән бу кешеләрнең Аллаһ хозурында бер-берсе белән бәхәсләшүләре Көрьәндә шул рәвештә аңлатыла:

***Сез икегез (әй фәрештәләр), һәр кирене, шөкерсезне атыгыз Җәһәннәмнең эченә. Яхшыга комачау булганны, һөҗүмче шикчене. Ки, ул Аллаһ белән бергә башка бер илях таныды. Инде икегез аны иң каты булган газап эченә атыгыз. Аның якын дусты (юлдан яздыручы) диде ки: "Раббыбыз, мин аны котыртып аздырдым. Әмма, үзе (хактан) ерак бер тайпылу эчендә иде." (Аллаһ боерыр) : "Минем хозурымда бәхәсләшеп тормагыз, Мин сезгә тагын да алданрак "каты бер уяру" җибәргән идем. Хозурымда сүз үзгәреш күрмәс һәм Мин колларга залим итүче түгел." (Каф сүрәсе, 24-29)***

Мөэминнәрне һәм алар барган дөп-дөрес юлны хуш күрмәгән бу кешеләр, Дин Көнендә мөэминнәрне үзләре янында күрмәгәч бик тә шашырырлар. Шашкынлыклары исә аятьләрдә шулай хабәр ителә:

***Һәм диярләр ки : "Безгә ни була ки, үзләрен начарлардан санаганыбыз адәмнәрне күрә алмыйбыз. Без аларны мәсхәрә итә идек. Югыйсә, карашларыбыз мы аларга ирешми?" Бу Җәһәннәм халкының бер-берсе белән бәхәсләшүве бер хакыйкать. (Сад сүрәсе, 62-64)***

Дөньяда араларындагы аңлашылмаучанлыклар һичбер заман бетмәгән, үз тормышларын үз куллары белән каралтканнар. Асылында, бер-берләренә кылынган бу золымга төшенәләр, моны аңлыйлар. Яшәгән урыннарында, хәтта якыннары арасында да рәхәт була алмаганнар. Моңа карамастан, араларындагы бәхәсләрдән берничек тә ваз кичмәсләр. Мөэминнәр дөньяда һәм Ахирәттә дә гел хозур эчендә булуларына карамастан, алар гел хозурсызлык һәм күңелсезлекләр кичерерләр. Шиксез, бу халәт яшәлгән һәм дәвамлы буларак яшәләчәк газап төрләреннән берсе. Һәм дүртъяклап газап татачаклар, һәм дә якыннары саналган кешеләр белән бәхәсләшәчәкләр.

**<u>Түбәнсетелерләр</u>**

Аллаһка каршы тәккәберләнүнең нәтиҗәсе— түбәнсетелү. Ахирәтнең барлыгына инанмаган кеше, Аллаһның ап-ачык барлыгын инкяр итеп уйланмыйча яшәвенең каршылыгын бик тә бәя түлиячәк. Югыйсә, аның дөнья тормышындагы халәте шул: Аллаһның газабына игътибар бирмәве, аның турында бер мизгелгә булса да уйланмавы. Дөньяда шайтанның солдатына әверелгән, аның алдавына бирелгән һәм имтиханнан гыйбарәт булган тормышны ниндидер буш максатлар өчен үткәргән. Хәтта, Аллаһка карата тәккәберләнү сыйфаты аны эшләнергә тиеш булмаган тагын башка хаталарга этәргән. Аллаһка каршы көрәшкән, Аллаһны инкяр итәр өчен алымнар эзләгән. Бу һичшиксез бөек бер хата һәм нәтиҗәсе Ахирәттәге куркыныч газап һәм бөек түбәнсетелү.

Инкярчылар әлбәттә хаксыз позициядә. Нигъмәтләргә, ризыкларга ничек ия булганнарын сораштырмыйча, күп кенә ләззәтләрне татуда аларның хаклары бар дип беләләр. Ләкин, Ахирәттә бу хаксыз тәккәберләнүнең каршылыгы бик тә бөек булачак. Аятьтә бу хакыйкать шулай аңлатыла:

***Инкяр иткәннәр утка алып барылган көнне ( аларга шулай әйтелер): "Сез дөнья тормышыгызда бөтен гүзәллекләрегезне һәм ләззәтләрегезне кулланып юк иттегез, алар белән яшәп ләззәтләндегез. Менә җир йөзендә хаксыз итеп бөекләнүвегез (тәккәберләнүвегез) һәм тайпылышта булувыгыз сәбәпле бүген түбәнсетүче газап белән җәзаландыралачаксыз." (Аһкаф сүрәсе, 20).***

Дөньяга юнәлгән бер тырышлык эчендә гомерләрен кичергән һәм Ахирәтне һич тә уйламаган бу кешеләр, Кыямәт Көнендә дә, соңыннан да түбәнсетеләчәкләр. Аллаһ бу хакыйкатьне аятьләрдә шул рәвештә белдергән:

***(Һәрьякны таралган буларак кушатучы) кыямәтнең хәбәре сиңа килде ме? Ул көнне шундый йөзләр бар ки, "түбәнсетелгәннәр." Тырышкан да бушына арыган. (Гашия сүрәсе, 1-3).***

***Соңыннан (Аллаһ) кыямәт көне аларны түбәнсетәчәк һәм диячәк ки: "Хакында (мөэминнәргә каршы) дошманлык кылганыгыз ширекләрем (миңа ширек кылганнарыгыз) кайда соң? " Үзләренә гыйлем бирелгәннәр диделәр ки: "Бүген чыннан да кяферләргә түбәнчелек һәм начарлык." (Нәхл сүрәсе, 27).***

***Кыямәт көнне газап аңа кат-кат арттырылыр һәм эчендә түбәнсетелгән буларак нигезле килеш калыр. (Фуркан сүрәсе, 69).***

Аллаһка каршы көрәшләрен яман кыюлык белән дәвам иткән кешеләр Хисап Көнен мөһимсенмәгәннәр. Аллаһ аларга хәзерләгән тозактан хәбәрсез яшәгәннәр. Югыйсә, бу тозак ише, охшашы күрелмәгән бер тозак. Бөтен инкярчы җәмгыятьләргә илчеләр аркылы

ясалган үгетләр, бик аз кешеләрдән тыш, тәэсирле булмаган. Хәтта, бер өлешенең инкярын да арттырган бу уярулар, асылында аларның җаваплылыгын да арттырган. Иң соңында, дөньяда үзләренә хәтерләтелгән Ахирәт хакыйкатен, Кыямәт көнне Аллаһ иң кирәкле рәвештә кешеләрнең бөтенесенә дә күрсәткән. Аллаһ вәгъдәсенең нәтиҗәләре ни булганлыгын инкярчылар ул көнне бик ачык бер рәвештә аңлаганнар. Чикле яшәешләре һәм дөнья тормышлары беткән. Инде ләззәт һәм теләкләрнең бер хакимияте дә юк, Аллаһның хакимияте бердәнбер хакыйкать. Аллаһка карата хаксызлык эчендә булган бу кешеләргә кылганнарының каршылыгы бирелгән. Алар Аллаһ хөкеме буенча газап һәм хәсрәт эчендә мәңге яшәячәкләр. Инанганнар, иман китергәннәр тарафыннан да хак ителгән, казанылган тормыш, бөтен бөеклеге һәм гүзәллекләре белән Дин Көнендә бөтен кешелеккә күрсәтеләчәк, күренәчәк.

# НӘТИҖӘ

Кыямәт Сәгате һәм аннан соң килүче мәңгелек тормыш кешеләрне көтүче иң мөһим хакыйкатьләрдән. Шул сәбәпле дә, китап буенча дөнья тормышының фани булувына кагылып аңлатылганнар бик зур әһәмияткә ия. Дөньядагы һичбернәрсә, ни карьерагыз, ни өйләнүегез, ни дә мал-мөлкәтегез мәңгелек тормышыгызга алыштырып яшәләчәк кадәр әһәмиятле дәрәҗәдә һәм ваз кичелмәс түгел. Аның өчен яшәләчәк һәм тырышлык күрсәтеләчәк булган тик бер нәрсә - “Аллаһ ризасы”. Аллаһ мәңгелек тормышның башлангычын соң дәрәҗәдәге бөек һәм олы вакыйгалар аркылы булдырачак. Бу көн белән каршылашкан һәркем дөнья тормышының инде бөтенләй соңына ирешкәнен аңлаячак һәм Ахирәтнең барлыгына бик ачык буларак төшенәчәк.

Бөтен кешеләрнең мондый бер көн белән каршылашуларыннан әввәл, элек бәлки дә һич алар тарафыннан уйланылмаган Кыямәт Сәгатен һәм ул китерәчәкләрне хәтерләүләре кирәк.

Бу китапта язылганнар сезне көнлек шөгыльләрдән һәм фани теләкләрдән бер мизгел өчен булса да аерып, яшәүнең бар булувындагы асыл максатны күрүвегезне булдыра. Бу бөек һәм авырлыклы көн килеп җитүдән элек, сезне “шиксез хакыйкать буларак” каршыланачак Кыямәт Көне белән уяруны максатланган. Бу уяру - әһәмиятле бер уяру. Чөнки мондый бер көннән һәм бу көннән соң булачаклардан гафләт эчендә яшәгән һәркеше тарафыннан шаһит булыначак вакыйгалар, чыдый алмаслык булачак һәм Ахирәттә бу кешеләр дә мәңгелек авырлыклар белән каршылашачак.

Көръәндә үзенчәлекле рәвештә аңлатылган Кыямәт Көне белән һичшиксез каршыланачаксыз. Ул көнне бөтен ия булганнарыгызның,

хәтта үзегезнең гәүдәгезнең дә сездән ераклашканын күрәчәк һәм яп-яңа бер терелү белән терeләчәксез. Сезне көткән мәңгелек тормышта, бу дөньядагы белән чагыштыра алмаслык нигъмәткә, рәхәтлеккә һәм хозурга ия булувыгыз өчен, Аллаһ сезгә әле дөньяда булган вакытыгызда биргән форсатны кулланырга тиешсез. Моның өчен эшләнүве кирәк булган бердәнбер нәрсә: Аллаһка иман итү, Аның каршылыксыз буларак биргән нигъмәтләренә шөкер итү һәм Ахирәт Көненең шиксез бер хакыйкать икәнлегенә инану. Моның бөтенләй киресе Ахирәттә бөек үкенеч булачак. Аллаһ бер аятьтә моны шулай хәбәр итә:

***Аллаһка кавышуны ялган санаганнар, дөресе, хәсрәткә таб булганнар. Шулай ки, сәгать (Кыямәт Көне) көтмәгәндә аларга килгәч, гөнаһларын сыртларына йөкләп: "Анда (дөньяда) җавапсызга кылганнарыбыз сәбәпле үкенеч безгә!"-диярләр. Игътибар итегез, ул эшләп йөкләнгәннәре ни кадәр начар. (Әнам сүрәсе, 31).***

Менә бу сәбәптән, Ахирәтнең шиксез бер хакыйкать булувына төшенергә, ул бөек Көн өчен хәзерлек кылырга тиешсез. Менә шул вакытта бу дөньяда эшләгәннәрегезнең кыйммәте булачак һәм Ахирәттә чагыштырувы булмаган каршылык ала алачаксыз. Шиксез, бу каршылык Ахирәттә, нәфсегез теләгән һәрнәрсәгә ия була алганыгыз бер урында, ягъни Җәннәт тә булачак. Шул да онытылмаска тиеш ки, Хисап Көнендә һәркеше Аллаһның хозурында яп-ялгыз килеш хисабын бирәчәк. Ул хәлдә, үлем һәм аңардан соң булачаклар өчен җитди тырышлык күрсәтергә һәм хәзерлек кылырга кирәк. Чөнки һәркеше Ахирәттә дөньяда кылганнарының каршылыгын, хаксызлыкка таб булмыйча, камил рәвештә алачак. Әмма, кешенең иң бөек казанышы, һәрнәрсәдән дә өстен булганы, һичшиксез, Аллаһның ризасы. Хәшер сүрәсендә Аллаһ бу хакыйкатьне шул рәвештә хәбәр итә:

***Әй иман иткәннәр, Аллаһтан куркыгыз. Һәркем иртәгесе өчен ни хәзерләгәненә карасын. Аллаһтан куркыгыз. Үзләре Аллаһны онытткан, шулай итеп Ул да аларга үз нәфесләрен оныттырган кебекләрдән булмагыз. Менә алар тайпылганнарның нәкъ узе. (Хәшер сүрәсе, 18-19).***

# Дарвинизмның соңы

Дарвинизм , ягъни эволюция теориясе, яратылыш хакыйкатен инкяр итү максаты белән уртага атылган, ләкин уңышлы булмаган гыйлемнән тыш бер сафсатадан башка бер нәрсә дә түгел. Җанлыларның җансыз мәддәләрдән үзеннән-үзе барлыкка килгәнен яклаган бу теория, космоста һәм җанлыларда бик ачык бер система барлыгының гыйлем тарафыннан исбат ителүве белән җимерелгән. Шулай итеп, Аллаһның бөтен космосны һәм җанлыларны яраткан булувы хакыйкате гыйлем тарафыннан да расланган. Бүген эволюция теориясен аякта тотар өчен дөньякүләм масштабында алып барылган пропоганда, барытик гыйльми хакыйкатьләрнең үзгәртелүвенә, тарафлы юралуга, гыйльми буларак күрсәтелгән ялганнарга һәм эшләнгән фабрикацияләргә таяна.

Ләкин , бу пропоганда дөреслекне яшерә алмый. Эволюция теориясенең белем тарихындагы иң бөек хата булганлыгы, соңгы 20-30 ел гыйлем дөньясында бара-бара тагын да көчлерәк тавыш белән телгә китерелә башлады. Бигрәк тә 1980 нәрдән соң үткәрелгән эзләнүләр Дарвинист исбатлауларның бөтенләй ялгыш булганын уртага куйган һәм бу хакыйкать бик күп галим тарафыннан телгә китерелгән. Бигрәк тә АКШда биология, биохимия, палеонтология кебек төрле тармаклардан килгән күп сандагы галимнәр, Дарвинизмның яраксызлыгын күрәләр, җанлыларның башлангычын барытик яратылыш хакыйкате аркылы ачыклый алалар. Бүген гыйльми технологияләр космосның һәм җанлыларның Аллаһ тарафыннан яратылган икәнлеген бер хакыйкать буларак күрсәтә.

Эволюция теориясенең бетүвен һәм яратылыш дәлилләрен башка бик күп хезмәтләребездә бөтен гыйльми үзенчәлекләре белән аңлаттык

һәм аңлатувыбызны дәвам итәбез. Ләкин теманы, бик әһәмиятле булганы өчен, монда да кыска гына аңлатуда файда бар.

**Дарвинны еккан читенлекләр**

Эволюция теориясе, борынгы Грециягә кадәр барып тоташучы бер фәлсәфә булувына карамастан, күләмле итеп 19 нчы гасырда уртага чыкты. Теорияне гыйлем дөньясының көнкүрешенә атучы иң мөһим вакыйга, Чарльз Дарвинның 1859 нчы елда басылган “Төрләрнең килеп чыгышы” исемле китабы иде. Дарвин бу китапта дөньядагы бөтен җанлы төрләрнең Аллаһ тарафыннан аерым – аерым буларак яратылувы хакыйкатенә каршы килә иде. Дарвинга күрә, бөтен төрләр уртак бер атадан яралганнар һәм вакыт белән кечкенә үзгәрешләр күреп, аермалы хәлгә килгәннәр.

Дарвинның теориясе һичбер конкрет гыйльми ачышларга таянмый иде; үзе дә кабул иткәне кебек, барытик бер “мантык кылудан” гыйбарәт иде. Хәтта, Дарвин китабындагы “Теориянең авырлыклары” исемле озын бүлегендә үзе белдерүвенчә, теория бик күп кенә әһәмиятле сорауларга җавап таба алмый иде.

Дарвин теориясе каршысындагы авырлыкларның алда булучы гайлем тарафыннан үтеләчәгенә, яңа гыйльми ачышларның теориясен көчләндерүвенә ышана иде. Моны китабында еш-еш белдерде. Ләкин, алга баручы гыйлем, Дарвин өметләренең киресе буларак, теориясенең асылларын бер-бер артлы таянычсыз калдырды.

Дарвинизмның гыйлем каршысындагы җиңелүве өч асыл кысымга бүленеп җентекләнә ала:

Теория җир йөзендәге тормышның иң башта ничек килеп чыкканлыгын һич тә ачыклый алмый.

Теория белдергән “эволюция механизмнарының” эволюциягә китерерлек берәр тәэсиргә ия булувын күрсәтүче һичбер гыйльми ачыш та юк.

Фосиллияләр калдыклары эволюция теориясе тасвирлаган тарихның

бөтенләй киресен аңлата.

Бу бүлемдә бу өч асыл кысымга гомуми һәм кыска буларак кагылып китәрбез.

**Үтелә алмаган беренче киртә: тормышның килеп чыгышы**

Эволюция теориясе бөтен җанлы төрләрнең моннан якынча 3,8 миллиард ел алда, беренчел дөньяда уртага чыккан тик бер җанлы күзәнәктән килгәннәрен белдерә. Ләкин, бер күзәнәкнең ничек миллионларча комплекслы җанлы төрләрен булдырганы һәм әгәр чыннан да бу төр эволюция булган булса, нигә моның эзләре фосиллияләрдә табылмаганы теория ачыклый алмый торган сораулардан. Әмма, бөтен болардан алданрак теория яклаган беренче этапта тукталып китәргә кирәк. Сүз ителгән шул “беренче күзәнәк” ничек барлыкка килгән?

Эволюция теориясе яратылышны инкяр итүве һәм һичбер табигатьтән өстен булган көчне кабул итмәгәнлегеннән, ул “беренче күзәнәкнең” һичбер проект, план һәм системалаштыру булмастан, табигать кануннары аркылы очраклы рәвештә барлыкка килгәнен белдерер. Ягъни, теориягә күрә, җансыз маддә очраклы сәбәпләр нәтиҗәсендә җанлы күзәнәк булдырган. Ләкин , бу беленгән иң асыл биологик кануннарга да каршы килә.

**“Тереклек тередән килә”**

Дарвин китабында тереклекнең килеп чыгышыннан һич сүз итмәгән. Чөнки аның дәверендәге элеккеге гыйлем җансызларның бик гади төзелешкә ия булганнарын исәпли иде. Урта гасырлардан бирле инанылган “spontane jenerasyon” исемле теориягә карата, җансыз маддәләрнең очраклы рәвештә бер арага килеп, җанлы барлык булдыра алачагына ишаныла иде. Бу дәвердә бөҗәкләрнең ризык калдыкларыннан, күсәләрнең дә бодайдан барлыкка килүләре таралган бер фикер иде. Моны исбатлау өчен дә кызык эксперементлар үткәрелә иде. Пычрак берәр чүпрәк өстенә бераз бодай сибелә һәм бераз көтелгәннән соң бу кушылудан күселәрнең барлыкка киләчәге көтелә иде.

Итләрнең кортлануы да тереклекнең җансыз маддәләрдән ярала алувына бер дәлил итеп санала иде. Югыйсә, соңыннан аңлашылачак иде ки, ит өстендәге кортлар үз-үзеннән барлыкка килмиләр, ә чебеннәр калдырган күзгә күренмәгән лечинкалардан чыгалар.

Дарвин "Төрләрнең килеп чыгышы" исемле китабын язган дәвердә исә, бактерияләрнең җансыз маддәләрдән килеп чыга алувына инану гыйлем дөньясында таралган һәм кабул ителгән иде.

Югыйсә, Дарвин китабының таралувыннан биш ел үткәннән соң, мәшһүр биолог француз Луи Пастер эволюциянең фундаментын тәшкил иткән бу инануны бөтенләй буларак черетте. Пастер күрсәткән олы тырышлыгын һәм ул үткәргән эксперементлар аркылы киленгән нәтиҗәне кыска гына шулай аңлаткан иде:

***"Җансыз маддәләрдән тормыш килеп чыга алувын белдерүче караш инде бөтенләй тарихка күмелгән."*** (Sidney Fox, Klaus Dose, "Molecular Evolution and The Origin of Life", New York: Marcel Dekker, 1977, 2 нче бит).

Эволюция теориясен яклаучылар Пастер тарафыннан ачылганнарга карата озын вакыт каршы тордылар. Ләкин, алга баручы гыйлем җанлы күзәнәкнең авыр төзелешен уртага чыгаргач, тормышның үзеннән-үзе килеп чыга алувы карашының яраксызлыгы тагын да ачык хәлдә күренде.

**20 нче гасырдагы нәтиҗәсез эзләнүләр**

20 нче гасырда тормышның ничек килеп чыгышын беренче буларак мәшһүр эволюционист, рус биологы Александр Опарин җентекләде. Опарин, 1930 нчы елларда уртага аткан берничә тезислары аркылы, җанлы күзәнәкнең очраклы рәвештә килеп чыга алувын исбат итәргә тырышты. Ләкин, бу эзләнүләр уңышсызлык белән соңланачак һәм Опарин шуны белдерергә мәҗбүр калачак:

***"Кызганычка каршы, күзәнәкнең килеп чыгышы – эволюция теориясен бөтенләй үз эченә алучы иң караңгы ноктадан гыйбәрәт."*** (Alexander I. Oparin, "Origi of Life", (1936) New York, Dover Publications,

1953(Reprint), 196 нчы бит).

Опарин эзләреннән баручы эволюционистлар, тереклекнең килеп чыгышын чишелешкә китерәчәк экспереметлар эшләргә тырыштылар. Бу эксперементларның иң мәшһүре Америкалы химик Стэнли Миллер тарафыннан 1953 нче елда үткәрелде.

Миллер беренчел дөнья атмосферасында булганлыгын белдергән газларны бер эксперементаль җиһазында берләштереп һәм бу кушылмага энергия өстәп, протеиннарның төзелешендә кулланылган берничә органик молекуланы (аминооксидны) синтезлады. Ул елларда эволюция өчен әһәмиятле бер ачыш кебек таныталган бу эксперементның яраксыз булувы һәм эксперементта кулланылган атмосфераның шул вакыттагы чын дөнья шартларыннан бик тә аермалы булганлыгы киләчәк елларда уртага чыгачак иде. (“New Evidence on Evolution of Early Atmosphere and Life”, Bulletin of the American teorological Society, 63 нче том, ноябрь 1982, 1328-1330 нчы битләр).

Озын итеп дәвам иткән бер тавышсызлыктан соң, Миллер үзе дә кулланылган атмосфераның чын булмаганын белдерде. (Stanley Miller, “Molecular Evolution of Life: Current Status of the Prebiotic Synthesis of Small Molecules, 1986”, 7 нче бит).

Тереклекнең килеп чыгышын ачыклау өчен 20 нче гасыр буенча күрсәтелгән бөтен эволюцион тырышлыклар гел уңышсызлык белән нәтиҗәләнде. Сан Диегоның Скрайс институтының мәшһүр геохимигы Джефрей Бэйда, эволюцион “Earth” журналында, 1998 нче елда чыккан бер мәкаләсендә бу хакыйкатьне шулай кабул итә:

***“Бүген , 20 нче йөзьелны артта калдырганыбыз вакыт, һаман 20 нче йөзьелга кергәнебездә ия булганыбыз иң бөек чишелә алмаган проблема белән кара-каршыбыз: тормыш җир йөзендә ничек башланды?”*** (Jeffrey Bada, Earth, февраль 1998, 40 нчы бит).

**Тормышның комплексслы төзелеше**

Эволюция теориясенең тереклекнең килеп чыгышында бу хәтле

бөек бер чарасызлыкка таб булувының төп сәбәбе, хәтта иң гади саналучы җанлы организмнарның да инанылмас дәрәҗәдәге комплекс төзелешләргә ия булулары. Җанлы күзәнәк – төзелеше белән адәм баласы җитештергән бөтен технологик җиһазлардан тагын да авыррак. Шулай ки, буген дөньяның иң алга киткән лабороторияләрендә дә хәтта, җансыз мәддәләр бер арага китерелеп , җанлы берәр күзәнәк эшләнә алмый.

Бер күзәнәкнең барлыкка килүве өчен кирәк булган шартлар, һич тә очраклы рәвештә булганлыгы ачыклана алмаячак кадәр күп. Күзәнәкләрнең иң асыл төзелеш ташлары саналган протеиннарның очраклы рәвештә синтезлану ихтималы: 500 аминооксидлы уртача бер протеин өчен **10** дә 1 дер. Ләкин, математикада 10 дә 1 дән әзрәк булучы ихтималлар практик буларак “була алмас” дип санала. Күзәнәкнең төшендә урын алган һәм генетик информацияне саклаган ДНК молекуласы исә, инаныла алмаслык бер информация банкы. Әгәр кеше ДНК да булган информацияне кәгазьгә күчерергә алынса, 500 шәр биттән торган 900 томлык бер китапханә булачагы хисаплана.

Монда бик кызыклы тагын бер дилемма бар:

ДНК барытик берничә махсус протеиннарның (энзимнарның) ярдәме белән генә парлана ала. Әмма, бу энзимнарның синтезы да барлык ДНК дагы информация аркылы гына тормышка аша. Бер-берләренә бәйле булганнарынан, парлану барлыкка килә алувы өчен дә берүк вакытта бар булулары кирәк. Бу исә, тормышның үзеннән-үзе килеп чыгу сценариясен тупикка китерә. Сан Диегодагы Калифорния университетыннан мәшһүр эволюционист, профессор Лесли Оргел “Scientific American” журналының 1994 нче елгы октябрь санында бу хакыйкатьне шулай белдерә:

***“ Соңгы дәрәҗә комплекс төзелешләргә ия булган протеиннарның һәм нуклеин оксидларының (РНК һәм ДНК) берүк урында һәм берүк вакытта очраклы рәвештә барлыкка килүләре – ашкан дәрәҗәдә ихтималдан тыш нәрсә. Әмма, боларның берсе булмыйча икенчесенең барлыкка килүве мөмкин түгел. Шулай итеп, кеше яшәешенең химик юллар белән урта чыгувының һич тә***

***мөмкин булмавы нәтиҗәсенә килү мәҗбүриятендә калабыз."*** (Leslic E. Orgel, "The Origin of Life on Earth", Scientific American, 271 нче сан, октябрь 1994, 98 нче бит)**.**

Шиксез, әгәр тормышның табигый факторлар аркылы уртага чыгувы мөмкин түгел исә, ул хәлдә тормышның табигатьтән өстен рәвештә, "яратылганын" кабул итәргә кирәк. Бу хакыйкать, иң асыл максаты Яратучыны инкяр итү булган эволюция теориясен, ачык иттереп яраксыз калдыра.

## ЭВОЛЮЦИЯНЕҢ ФАНТАСТИК МЕХАНИЗМНАРЫ

Дарвинның теориясен яраксыз кылучы икенче олы нокта, теория тарафыннан "Эволюция механизмнары" буларак белдерелгән ике төшенчәнең дә, чынлыкта, һичбер эволюциягә китерүче көчкә ия булмауларының аңлашылган булувы. Дарвин уртага аткан эволюция өйрәтмәсен бөтенлеге белән "табигый селекция" механизмына бәйләгән иде. Бу механизмга бирелгән әһәмият китабының исеменнән дә ачык буларак аңлашыла иде: "Төрләрнең килеп чыгышы, табигый селекция юлы аркылы..."

Табигый селекция табигый сайлауны аңлата. Табигатьтәге яшәү өчен барган көрәш эчендә табигать шартларына яраклы һәм көчле җанлыларның тормышта калулары фикеренә таяныр. Үрнәге, ерткыч хайваннар тарафыннан куркыныч янаган болан көтүвендә тизрәк чаба алган боланнар исән калачаклар. Шулай итеп, болан көтүве тиз һәм көчле индивидлардан формалашачак. Әмма, әлбәттә бу механизм боланнарны эволюцион үзгәрешләргә китермәс, аларны башка берәр җанлы төренә, үрнәге - атларга әйләндермәс.

Шул сәбәпле , табигый селекция механизмы һичбер эволюциягә китерерлек көчкә ия түгел. Дарвин да бу хакыйкатьне белә иде һәм "Төрләрнең килеп чыгышы" исемле китабында "файдалы үзгәрешләр барлыкка килмәве дәвамлылыгында, **табигый синтез һичбер нәрсә**

**эшләмәс"** дип әйтәргә мәҗбүр калган иде (Charles Darwin,"The Origin of Species : A Facsimile of the First Edition", Harvard University Press, 1964, 189 нчы бит).

### Ламаркның тәэсире

Ярар, бу "файдалы үзгәрешләр" ничек барлыкка килә ала иде? Дарвин, дәверенең беренчел гыйлем аңлаешы эчендә, бу сорауга Ломарка таянып җавапларга тырышты. Дарвиннан алданрак яшәгән француз биологы Ламаркка күрә, җанлылар яшәешләре буенча кичергән физик үзгәрешләрне киләчәк нәселләргә ирештерәләр, нәселдән нәселгә җыелган бу үзенчәлекләр нәтиҗәсендә яңа төрләр барлыкка килә иде. Үрнәге, Ламаркка күрә, жирафлар боланнардан килеп чыкканнар иде, югары агачлардагы яфракларны ашар өчен сузыла-сузыла, нәселдән-нәселгә муеннары озынайган иде.

Дарвин да охшаш үрнәкләр биргән. Үрнәге, "Төрләрнең килеп чыгышы" исемле китабында, ашамлык табыр өчен суга кергән кайбер аюларның, заман үтү белән китларга әверелгәнен белдергән иде!? (Charles Darwin, "The Origin of Species : A. Facsimile of the First Edition", Harvard University Press, 1964, 184 нче бит).

Әмма, Мендель ачкан һәм 20 нче йөзьелда алга киткән генетика фәне белән расланган калучанлык кануннары, казанылган үзенчәлекләрнең киләчәк нәселләргә калу легендасын юк итте. Шулай итеп, табигый селекция "ялгыз башын" һәм бөтенләй тәэсирсез механизм буларак калды.

### Неодарвинизм һәм мутацияләр

Дарвинистлар бу мәсьәләгә берәр чишелеш табыр өчен 1930 нчы елларның соңнарында "Модерн синтетик теорияне" яки тагын да таралган исеме белән беленгән "неодарвинизмны" уртага аттылар. Неодарвинизм табигый селекциягә "файдалы үзгәрешләр сәбәбе" буларак мутацияләрне, ягъни җанлыларның геннарында радиация кебек тышкы тәэсирләр яки копияләү хаталары нәтиҗәсендә барлыкка килгән

бозылуларны өстәде.

Бүген әле һаман дөньяда дарвинизм ягыннан яраклы саналган модель – неодарвинизм. Теория җир йөзендәге миллионнарча җанлыларның, аларның колак, күз, үпкә, канат кебек сансыз комплекслы органнарының “мутацияләр”, ягъни генетик бозылуларга таянучы бер процесс нәтиҗәсендә барлыкка килгәнлеген белдерә. Әмма , теорияне чарасыз калдырган ачык бер гыйльми хакыйкать бар: мутацияләр җанлыларга файдалы үзгәрешләр китермәс, киресенчә, һәрзаман җанлыларга зарар китерер.

Моның сәбәбе бик гади: ДНК бик комплекслы системага ия. Бу молекулада очраклы рәвештә барлыкка килгән һәрнинди берәр тәэсир барытик зарар гына бирер. Америка генетигы Б.Г. Рэнгэнэзан моны шулай ачыклый:

***“Мутацияләр кечкенә, очраклы һәм зарарлы. Бик сирәк буларак барлыкка килерләр һәм иң күп очракта тәэсирсезләр. Бу өч сыйфат мутацияләрнең эволюцион берәр үзгәреш китерә алмауларын күрсәтер. Һәм бик махсус берәр организмда барлыкка килә алырлык берәр очраклы үзгәреш, йә тәэсирсез булачак, йә зарарлы. Берәр кул сәгатендә барлыкка киләчәк үзгәреш кул сәгатенә файдалы үзгәреш китермәячәк. Бөек ихтимал, аңа зарар бирәчәк яки иң күп очракта файдасыз булачак. Берәр җир тетрәве шәһәргә файда китермәс, аны һәлакәткә китерер.” ( B. G. Rangathan, “Origins”, Pensylvania : The Banner Of Tharh Trust, 1988).***

Шулай итеп, бүгенгә кадәр һичбер яраклы, ягъни генетик яктан файда китерүче мутация үрнәге күрелмәде. Бөтен мутацияләрнең зарары булганы күренде. Аңлашылды ки, эволюция теориясе тарафыннан “эволюция механизмнары” буларак күрсәтелгән мутацияләр, чынлыкта җанлыларга барытик зарар китерә, аларны инвалид итә (кешеләрдә мутациянең иң еш күрелгән тәэсире-рак). Әлбәттә, зарар китерүче механизм “эволюция механизмы” була алмый. Табигый селекция исә, Дарвин үзе дә кабул иткәне кебек, “үзе генә һичбер нәрсә эшләмәс”. Бу хакыйкать безгә табигатьтә һичбер “эволюция

механизмының” булмавын күрсәтә. Эволюция механизмы булмаганга күрә, эволюция диелгән фантастик процесс та яшәлмәгән.

**Фосиллияләр калдыклары: ара формалардан әсәр юк**

Эволюция теориясен яклаган сценариянең яшәлмәгән булганын иң ачык рәвештә фосиллияләрнең калдыклары күрсәтер.

Эволюция теориясенә күрә, бөтен җанлылар бер-берсеннән килеп чыккан. Башта бар булмаган “бер” җанлы төре, вакыт үтү белән башкага әверелгән һәм бөтен төрләр шулай итеп барлыкка килгән. Теориягә карата, бу әверелү йөз миллионнарча ел дәвам иткән һәм адым-адым тормышка аша биргән.

Бу хәлдә, белдерелгән озын әверелү процессы вакытында сансыз “ара төрләрнең” барлыкка килгән һәм яшәгән булулары кирәк.

Үрнәге, элек балык үзенчәлекләренә ия булуларына карамастан, бер яннан кайбер сөренүчеләрнең дә үзенчәлекләрен казанган ярым балык – ярым сөренүче җанлыларның яшәгән булулары кирәк. Яки сөренүче үзенчәлекләренә ия булган вакытында, бер яннан кайбер кош үзенчәлекләрен казанган сөренүче-кошлар барлыкка килгән булулары тиеш. Болар, бер үзгәрү процессы күргәннәре өчен, инвалид, җитешсезлекле, кимчелекле җанлылар булырга тиеш. Эволюционистлар үткәннәрдә яшәгән дип инанылган бу теорик җанлыларга “ара формалар” исеме бирер.

Әгәр чыннан да бу төр җанлылар үткәндә яшәгән булсалар, аларның саннары һәм төрләре миллионнарча, хәтта миллиардларча булырга тиеш. Һәм бу үзенчәлекле җанлыларның калдыклары, һичшиксез фосиллияләр калдыклары арасында табылырга тиеш. Дарвин “Төрләрнең килеп чыгышы” китабында моны шулай ачыклый:

***“Әгәр теориям дөрес исә, төрләрне бер-берсенә бәйләүче сансыз ара формалар төрләре һичшиксез яшәгән булырга тиеш… Боларның яшәгән икәнлекләренең дәлилләре дә барытик фосиллияләр калдыклар арасында табыла ала.” (Charles Darwin, “The Origin of***

***Species : A Facsimile of the First Edition", Harvard University Press, 1964, 179 нчы бит).***

**Дарвинның тормышка ашмаган өметләре**

Ләкин, 19 нчы йөзләрнең уртасыннан алып бүгенгегә хәтле дөньяның дүрт ягында лихорадкалы рәвештә фосиллияләр эзләнүләре ясалувына карамастан, бу ара формалар һич тә табылмаган. Үткәрелгән казылмалар һәм эзләнүләр аркылы ия булынган бөтен ачышлар, эволюционистлар көткәненең киресе буларак, җанлыларның җир йөзендә берьюлы, көтелмәгәндә, кимчелексез һәм җитешсезлексез бер рәвештә килеп чыкканнарын күрсәтте.

Мәшһүр инглиз палеонтологы (фосиллияләр буенча махсус галим) Дэрэк В. Эйджер, бер эволюционист булувына карамастан, бу хакыйкатьне шулай белдерә: ***"Проблемабыз шул: фосиллияләр калдыкларын ничкәлекләре белән җентекләгәнебездә , төрләр яки сыйныфлар дәрәҗәсендә булсын, гел бертөрле хакыйкатьләр белән каршылашабыз; адым-адым үзгәрешләргә китерүче эволюция аркылы түгел, берьюлы җир йөзендә барлыкка килгән группалар күрәбез."*** (Derek A/ Ager, "The Nature of the Fossil Record", Proceedinns of the British Geological Association, 87 нче том , 1976, 133 нче бит).

Ягъни фосиллияләр калдыклары буенча, бөтен җанлыларның төрләре, араларында һичбер ара формалар булмастан, кимчелексез рәвештә берьюлы уртага чыкканнар. Бу Дарвин исәпләгәннәрнең бөтенләй киресе. Өстәвенә , бу җанлы төрләрнең яратылганнарын күрсәтүче бик көчле бер дәлил. Чөнки берәр җанлы төренең үзеннән эволюцион үзгәреш күреләчәк һичбер атасы булмыйча, бер мизгелдә һәм кимчелексез буларак уртага чыгувының бердәнбер аңлатылмасы – ул төрнең яратылган булувы. Бу хакыйкать мәшһүр эволюционист , биолог Дулас Фютюйма тарафыннан да кабул ителә:

***"Җанлыларның килеп чыгышын барытик яратылыш яки эволюция аркылы гына ачыкларга мөмкин. Җанлылар дөньяда, йә***

***бөтенләй камиль һәм кимчелексез рәвештә уртага чыкканнар, йә болай булмаган. Әгәр болай булмаган булса, бер үзгәреш процессы аркылы үзләреннән алданрак бар булган кайбер җанлы төрләреннән эволюция күреп барлыкка килгән булулары кирәк. Әмма, әгәр кимчелексез һәм камиль бер рәвештә уртага чыкканнар исә, ул хәлдә, чиксез көч иясе бер акыл тарафыннан яратылган булулары кирәк.”*** (Douglas J. Futuyma, “Science on Trial”, New York Pantheon Books, 1983, 197 нче бит).

Фосиллияләр җанлыларның җир йөзендә кимчелексез һәм камиль рәвештә уртага чыкканнарын күрсәтә. **Ягъни “төрләрнең килеп чыгышы”, Дарвин исәпләгәненең киресе буларак, эволюция түгел , яратылыш.**

## Кеше эволюциясе турында әкият

Эволюция теориясен яклаучылар тарафыннан иң күп көндәлеккә китерелгән тема – кешенең килеп чыгышы темасы. Бу теманың дарвинистик эчтәлеге, бүген яшәгән модерн кешенең маймылсыман берничә җанлылардан килеп чыкканын исәпләү. 4-5 миллион ел элек башланган дип саналган бу процесста, модерн кеше белән аталары арасында кайбер “ара формаларның” яшәгәнлеге белдерелә. Чынлыкта, бөтенлеге белән хыялый булган сценариядә дүрт фундаменталь “категория” саналып кителә:

Australopithecus (австралопитек)

Homo habilis (эшчәнлек күрсәтә алучы кеше)

Homo erectus (туры йөрүче кеше)

Homo sapiens (акыллы кеше)

Эволюционистлар, тик сүздә генә булган кешенең беренче маймыл сыман атасына, “көнчыгыш маймылы” дигәнне аңлаткан “Australopithecus” исемен бирерләр. Бу җанлылар, чынлыкта, нәселе тәмамлынган бер маймыл төреннән башка берни түгел.

Лорд Салли Зукерман һәм профессор Чарльз Окснард кебек Англиянең һәм АКШның дөньякүләм мәшһүр ике анатомистының, Astralopithecus үрнәкләре өстендә үткәрелгән бик киң аланлы эзләнүләр нәтиҗәсендә, бу җанлыларның барытик нәселе тәмамланган бер маймыл төре икәнлеген һәм кешеләргә һичбер охшашлыклары булмаганлыгы күренде. (Solly Zuckerman, “Beyond The Ivori Tower”, New York: Toplinger Publications, 1970, 75-94 нче битләр; Charles E. Oxhard, “The Place of Australopithecines in Human Evolution Grounds for Doubt”, “Nature”, 258 сан, 389 нчы бит).

Эволюционистлар кеше эволюциясенең соңгы стадиясен “homo”, ягъни кеше буларак сыйныфландырыр. Белдергәннәренә күрә, “homo” стадиясендәге җанлылар “Australopithecus”lardan тагын да алга киткән үзгәреш күргәннәр. Эволюционистлар бу төрле-төрле җанлыларга кагылышлы фосиллияләрне бер-бер артлы төзеп, хыялый эволюция схемасы төзерләр. Бу фантастик схема, чөнки чынлыкта бу төрле сыйныфлар арасындагы эволюцион бәйлелек булувы һич тә исбатланмаган. Эволюция теориясенең 20 нче гасырдагы иң күренекле яклаучыларыннан берсе булган Эрнст Майр, “**homo sapienska илтүче чылбыр чынлыкта югалган**” диеп, моны кабул итәр. (J. Renic, “Darwin´s Current Bulldog: Ernst Майр”,”Scientific American”, декабрь 1992).

Эволюционистлар “Australopithecus - Homo habilis - Homo erectus - Homo sapiens” чиратын язган вакытта, бу төрләрнең һәрберсе анардан соң килүченең атасы булганын белдерә. Югыйсә, палеантологларның соңгы ачышлары “Australopithecus”, “Homo habilis” һәм “Homo erectusның” дөньяның төрле урыннарында бер үк вакытта яшәгәнлекләрен күрсәтте. (Alan Walker,”Sciense”, 207 нче сан, 1980, 1103 нче бит; A. J. Kelso, “Physical Antropology”, 1 нче басма, New York: J. B. Lipincott Co., 1970, 221 нче бит; M. D. Leakey, “Olduvai Gorge”, 3 нче том, Canbridge: Cambridge University Press, 1971, 272 бит).

Тагын “Homo erectus” дип сыйныфланган кешеләрнең бер өлеше бик модерн заманнарга кадәр яшәгәннәр, “Homo sapiens neandertalensis” (неандерталь кешеләр) белән берүк урында бергә яшәгәннәр. (“Time”,

ноябрь, 1996).

Әлбәттә, бу әлеге сыйныфларның бер-берсенең аталары булганын яклауның яраксыз икәнлеген ачык рәвештә уртага сала. Гарвард университеты палеонтологларыннан Стефан Джей Гоулд , үзе дә бер эволюционист булувына карамастан, дарвинист теория кергән бу тупикны шулай ачыклый:

***“Әгәр бер-берсе белән паралель рәвештә яшәгән өч төрле гоминидның (кешесыманнарның) эзе бар исә, ул вакыт безнең нәсел агачыбызга ни булган? Ачык ки, боларның берсе башкасыннан килә алмый. Тагын, берсе башкасы белән чагыштырылганында эволюцион үзгәреш юнен күрсәтми.”( S. J. Gould, “Natural History”, 85 нче сан, 1976, 30 нчы бит).***

Кыскасы, медиада яки дәреслекләрдә урын алган фантастик берничә “ярым маймыл - ярым кеше” буларак рәсемләнгән җанлылар, ягъни барытик пропоганда юлы белән генә аякта торувы тырышылган кешенең эволюция сценариясе , һичбер гыйльми фундаменты булмаган бер әкияттән генә гыйбарәт.

Бу теманы озын елллар буе җентекләгән, “Australopithecus” фосилияләр өстендә 15 ел буенча махсус эзләнүләр үткәргән Англиянең иң мәшһүр һәм ихтирам ителгән галимнәреннән булучы Лорд Салли Зукерман, бер эволюционист булувына карамастан, уртада маймылсыман җанлылардан кешегә барып тоташучы чын нәсел агачы булмаган нәтиҗәгә килгән.

Зукерман үз чиратында кызыклы бер “гыйльми шкала” да ясаган. Аның тарафыннан гыйльми буларак танылган белем тармакларыннан алып, гыйлемнән тыш буларак кабул ителгән белем тармакларына кадәр бер шкала барлыкка китергән. Зукерманның бу таблицасына күрә, иң “гыйльми” – ягъни конкрет күрсәткечләргә таянучы – белем тармаклары химия һәм физика. Шкалада болардан соң биология белемнәре һәм аннан соң социал белемнәр килә. Шкаланың иң очында, ягъни иң “гыйлемнән

тыш” саналган кысымда исә, Зукерманга күрә, телепатия, алтынчы хис кебек “хис тышындагы сиземләү” төшенчәләре һәм “кеше эволюциясе” бар. Зукерман бу шкаланың очын шулай ачыклый:

***“Объектив хакыйкатьләрнең аланыннан чыгып, биологик белем дип саналган бу аланнарга - ягъни хис тышындагы сиземләүгә һәм кеше ясаган фосиллияләр тарихының юрымлавына – кергәнебез вакыт, эволюция теориясенә иманучы берәү өчен һәрнәрсәнең мөмкин икәнлеген күрербез. Шулай ки, теорияләренә бөтенләй ышанучы бу кешеләрнең, бәхәсле кайбер фикер йөртүләрне берүк вакытта кабул итүләре дә хәттә мөмкин.”*** (Solly Zuckerman, “Beyong The Ivory Tower”, New York Toplinger Publications, 1970, 19 нчы бит).

Менә кеше эволюциясе әкияте дә, теорияләренә сукырларча ышанучы кайбер кешеләр тарафыннан табылган фосиллияләрне үзләренә кирәк булган бер рәвештә юрауларыннан гына гыйбарәт.

## ДАРВИН ФОРМУЛАСЫ

Хәзергегә чаклы кыска гына карап үткәнебез бөтен гыйльми дәлилләр белән бергә, теләсәгез, эволюционистларның нинди уйдырма бер инануга ия булганлыкларын, хәтта балалар да аңлый алачак кадәр ачык булган үрнәкләр белән нитиҗә ясыйк.

Эволюция теориясе җанлыларның очраклы рәвештә барлыкка килгәнен яклый. Шулай итеп, бу теорияга карата, җансыз һәм зиһенсез атомнар бер арага килеп башка күзәнәкне бар иткәннәр һәм соңыннан шулук атомнар бер рәвешле башка җанлыларны һәм кешене дә барлыкка китергәннәр. Хәзер уйланыйк, җанлыларның “төзелеш ташлары” ролень уйнаган карбон, фосфор, азот, калий кебек элементларны бергә туплаганыбызда бер масса барлыкка килә. Бу атомнар массасы, нинди процесстан үтсә үтсен, берәр җанлы барлыкка китерә алмый. Теләсәгез моның өчен берәр “эксперимент” үткәрийк һәм асылында

эволюционистлар тарафыннан якланылган, әмма югары тавыш белән телгә китерелмәгән “Дарвин формуласы” аркылы җентеклийк: эволюционистлар күп сандагы бөек пробиркаларның эчләрен җанлылар төзелешендә булган фосфор, азот, карбон, һава, тимер, магний кебек элементлар белән мул итеп тутырсыннар. Хәтта нормаль шартларда булмаган, ләкин бу кушылма эчендә булувы кирәк дип күрелгән бөтен маддәләрне дә бу пробиркаларга кушсыннар. Кушылмалар эченә теләнелгән кадәр аминооксидлар, теләнелгән кадәр дә (хәтта моның берүзенең генә дә очраклы рәвештә барлыкка килү ихтималы $10^{-}$ булган) протейн тутырсыннар. Бу кушылмаларга теләнелгән пропорциядә җылылык һәм дымлылык бирсеннәр. Боларны теләнелгән модерн җиһазлар белән карыштырсыннар. Пробиркалар янында дөньяның алдынгы галимнәре җыелсын. Бу галимнәр атадан балага, нәселдән нәселгә күчә-күчә, кизү тора-тора, миллиардларча, хәтта триллиардларча ел дәвамында пробиркалар янында көтсеннәр. Бер җанлының барлыкка килүве өчен ниндидер шартларның бар булувы кирәклегенә инаныла икән, һәммәсен дә куллану ирекле булсын. Ләкин, ни эшләнсә эшләнсен, ул пробиркалардан һич бер җанлы чыгара алмаслар. Жирафларны, канарейкаларны, былбылларны, попугайларны, атларны, дельфиннарны, гөлләрне, архидеяларны, лилияләрне, канәферлерне, бананнарны, апельсиннарны, алмаларны, хөрмәләрне, помидорларны, кавыннарны, карбызларны, инҗирләрне, зәйтүннәрне, йөземнәрне, шәфталиләрне, тавис кошларын, фазаннарны, төсле-төсле күбәләкләрне һәм болар кебек миллионнарча җанлы төрләрнең һичберсен дә барлыкка китерә алмаслар. Монда беркадәр санап үтелгән бу җанлы барлыкларга түгел, боларның тик бер күзәнәге генә дә ия була алмаслар!

Кыскасы, зиһенсез атомнар бер арага килеп күзәнәкне булдыра алмас. Соңыннан яңа берәр карар биреп, бер күзәнәкне икегә бүлгән, соңыннан берәр-берәр башка карарлар алып, электрон микроскопны уйлап тапкан, соңыннан үзенең күзәнәге төзелешен бу микроскоп аша караган профессорларны барлыкка китерә алмаслар. Маддә барытик Аллаһның өстен яратувы белән генә барлыкка килер. Моның киресен яклаучы эволюция теориясе исә, акылга бөтенләй каршы килүче бер сафсата. Эволюионистлар тарафыннан уртага атылганнар өстендә бераз

гына булса да уйлану, югарыдагы үрнәктә булганы кебек, бу хакыйкатьне бик ачык рәвештә күрсәтер.

### Куз һәм колак технологиясе

Эволюция теориясе тарафынан һич тә ачыклана алмаган башка бер тема исә, күз һәм колакның өстен сиземләү сыйфатлары. Күз белән бәйле темага күчәр алдыннан, кыска гына ничек иттереп күрувебезне аңлатып үтик. Берәр җисемнән килүче нурлар күздәге ретинага киресенчә төшәр. Бу нурлар мондагы күзәнәкләр тарафыннан электрик сигналларга әйләндерелер һәм минең арткы өлешендәге "күрү мәркәзе" диелгән кечкенә генә бер ноктага ирештерелер. Бу электрик сигналлар берничә процесстан соң, мидәге бу мәркәздә күрү буларак тоемланыр. Хәзер болардан соң уйланыйк:

Ми яктылыкка ябык. Ягъни минең эче кап-караңгы, яктылык ми булган җиргә хәтле керми. Күрү мәркәзе диелгән урын кап-караңгы, яктылыкның һич ирешмәгән, бәлки дә һич күрелмәгән кадәр караңгы бер урын. Әмма, сез бу кап-караңгылыкта якты, нурлы дөньяны тамаша кыласыз.

Өстәвенә, бу шул кадәр ачык һәм сыйфатлы бер күренеш ки, хәтта XXI нче йөз технологиясе дә, һәртөрле мөмкинчелекләренә карамастан, бу ачыклылыкка ирешә алмаган. Үрнәге, хәзер укыганыгыз китапка, китапны тотучы кулларыгызга карагыз, соңыннан башыгызны күтәреп тирә-яныгызга карагыз. Хәзер күрелгән ачыклылыктагы һәм сыйфаттагы бу күренешне башка берәр җирдә күрдегез ме? Бу кадәр ачык күренешне сезгә дөньядагы телевизорлар җитештерү буенча беренче булган ширкәт тарафыннан чыгарылган иң әйбәт экран да бирә алмаячак. 100 ел буенча меңнәрчә инженер бу ачыклыкка ирешергә тырыша. Моның өчен фабрикалар, дәү корылмалар төзелә, эзләнүләр үткәрелә, планнар һәм проектлар әзерләнә. Тагын бер телевизор экранына карагыз һәм тагын хәзер кулыгызда тотканыгыз бу китапка. Арада бөек ачыклык һәм сыйфат аермасы булувын күрәчәксез. Өстәвенә, телевизор экраны сезгә ике үлчәмле күренеш күрсәтер, ә сез өч үлчәмле, тирәнлекле бер манзара күрәсез.

Озак еллар буенча ун меңнәрчә инженер өч үлчәмле телевизор ясарга, күзнең күрү сыйфатына ирешергә тырышты. Әйе, өч үлчәмле телевизор системасы ясый алдылар, әмма аны да күзлек кимичә өч үлчәмле итеп күркү мөмкин түгел, бу ясалма өч үлчәмлелек. Арткы тараф тагын да болганчык, алгы тараф исә кәгазьдән декорация кебек тора. Һичбер заман күзнең күргәне кебек ачык һәм сыйфатлы күренеш формалашмый. Камерада да, телевизорда да мәҗбүри рәвештә күренеш югалтувы барлыкка килә.

Менә эволюционистлар, бу сыйфаттагы һәм ачыклыктагы күренешне булдырган механизмның очраклы рәвештә формалашканын яклыйлар. Хәзер кемдер сезгә бүлмәгездә торучы телевизор очраклы сәбәпләр нитиҗәсендә барлыкка килде, атомнар бер арага килде һәм бу күрсәтүче җиһазны барлыкка китерә дисә ни уйларсыз? Меңнәрчә кеше бер арага килеп ясый алмаганны, зиһенсез атомнар ничек ясасын ?

Күз күргәненнән тагын да гадирәк булучы бер күренешне булдырган җиһазның очраклы барлыкка килә алмавы көн кебек ачык. Шундый ук хәл колак өчен дә яраклы. Тышкы колак тирәдәге тавышларны колак раковинасы ярдәмендә туплап урта колакка ирештерер, урта колак алынган тавыш вибрацияләрен көчләндереп эчке колакка илтеп җиткерер, эчке колак бу вибрацияләрне электрик сигналларга әйләндереп мигә җибәрер. Күрүдә булганы кебек, ишетү процессы да мидәге “ишетү мәркәзендә” тормышка ашар.

Күздәге хәл колак өчен дә яраклы, ягъни ми яктылык белән бергә тавыш өчен дә ябык, тавыш үткәрми. Шуңа күрә, тышта ни кадәр тавыш булса да, ми эче бөтенләй тавышсыз. Моңа карамастан, иң ачык тавышлар ми тарафыннан тоемланыр. Тавыш үткәрмәгән миегездә бер оркестрның симфонияләрен тыңларсыз, бер күп халык җыелган урынның бөтен гаугасын ишетерсез. Әмма, шул вакытта махсус бер җиһаз белән миегез эчендәге тавыш дәрәҗәсе үлчәнсә, миегездә бөтенләй тынлык булганы күреләчәк.

Ачык бер күренешкә ия булу ниятеннән технология ничек кулланылса, тавыш өчен дә шулук тырышлыклар уннарча елдан бирле

дәвам итә. Тавыш язу җиһазлары, музыкаль центлар, күп кенә электроник җиһазлар, тавышны сизүче музыкаль системалар бу тырышлыкларның кайберләре. Ләкин, бөтен технология, бу технологияләр өчен эшләгән меңнәрчә инженерга һәм специалистка карамастан, колак булдырган ачыклыктагы һәм сыйфатлылыктагы тавышка ирешә алмаган. Музыкаль җиһазлар җитештерү буенча иң беренче саналган ширкәт тарафыннан җитештерелгән иң сыйфатлы музыкаль центрны алыйк. Тавышны язган вакытында гел тавышның бер өлеше югалыр яки әз дә булса комачау итүче тавышлар барлыкка килер яки музыкаль центрны кабызган вакытыгызда, әле музыка башламастан, чытырт иткәнен ишетерсез. Әмма, кеше гәүдәсендәге технологиянең продукты булучы тавышлар соңгы дәрәҗәдә ачык һәм кимчелексез. Кеше колагы һичбер заман, музыкаль центрдагы булганы кебек, чытыртлы яки комачау итүче тавышлар белән бергә тоемламас, тавыш ни исә, бөтен һәм ачык килеш аны тоемлар. Бу хәл кеше яратылган көннән алып бүгенгегә хәтле дәвам итә.

Хәзергегә хәтле адәм баласы ясаган һичбер күрү һәм тавыш җиһазы күз һәм колак кадәр сиземле һәм уңышлы тоемлаучы була алмаган.

Әмма, күрү һәм ишетү феноменында бөтен болардан тыш булучы тагын бер бик бөек хакыйкать бар.

**Ми эчендә күрүче һәм ишетүче кем ?**

Ми эчендә якты, төсле дөньяны тамаша кылучы, симфонияләрне, кошларның сайрауларын тыңлаучы, гөлләрне иснәп хушланучы кем?

Кешеләрнең күзләреннән, колакларыннан, борыннарыннан килүче сиземләүләр электрик сигналлар булып мигә бара.

Биология, физиология һәм биохимия китапларында моның мидә ничек барлыкка килүвен аңлатучы күп кенә детальләр белән танышырсыз. Әмма, бу тема белән бәйле булган иң мөһим хакыйкатьне һичбер җирдә очрата алмассыз: мидә бу электрик сигналларны күрү, тавыш, ис һәм хис буларак тоемлаучы кем? Минең эчендә күзгә, колакка, борынга мохтаҗ булмыйча, бөтен боларны тоемлаган бер зиһен бар. Бу

зиһенгә кем ия ?

Әлбәттә , бу зиһенне минең төзелешендә булучы нервлар, май катламы һәм нерв күзәнәкләре булдыра алмый. Менә шул сәбәптән, һәрнәрсәнең маддәдән гыйбарәт булганын исәпләүче дарвинист-материалистлар, бу сорауларга һичбер җәвап таба алмый. Чөнки бу зиһен – Аллаһ яраткан рух. Рух – күрү өчен күзгә, ишетер өчен колакка, уйлау өчен мигә мохтаҗ түгел.

Бу ачык һәм гыйльми хакыйкатьне укыган һәр кешенең, ми эчендәге берничә сантиметр кубтагы, кап-караңгы урынга бөтен галәмне өч үлчәмле, төсле, күләгәле һәм якты буларак сыйдыручы бөек Аллаһ турында уйланып, Аңардан куркып, Аңа сыенувы кирәк.

## Материализм дине

Югарыда җентекләнгәннәр эволюция теориясенең гыйльми ачышларга карата ачык рәвештә каршылыклы булганын күрсәтә. Теориянең тормышның килеп чыкканлыгын аңлатувы гыйлемгә каршы килә, аның тарафыннан белдерелгән “эволюция механизмнарының” һичбер эволюцияга китерерлек тәэсире юк һәм фосиллияләр бу теория кирәктергән ара формаларның яшәмәгәнлекләрен күрсәтә. Бу хәлдә, әлбәттә, эволюция теориясенең гыйлемгә каршы килүче бер төшенчә буларак читкә атылувы кирәк. Тарих буенча, дөньяны космосның үзәге дип белдергән галәм моделе кебек, күп кенә төшенчәләр гыйлем көндәлегеннән чыгарылган. Әмма, эволюция теориясе зур теләк белән гыйлем көндәлегендә тотыла. Хәтта кайбер кешеләр теориянең критикасын “гыйлемгә һөҗүм” буларак та күрсәтергә тырыша. Ни өчен ?

Бу халәтнең сәбәбе, эволюция теориясенең кайбер тирәләр өчен үзеннән һичничек тә ваз кичә алмаслык догматик бер инану булувында. Бу тирәләр материалист фәлсәфәгә сукырларча бәйле һәм дарвивизмны да табигатьтәге нәрсәләрне аңлата алырлык бердәнбер материалист ачыклау булганы өчен хуплый. Кайвакыт моны ачык итеп белдерәләр. Гарвард унивеситетынын мәшһүр генетик һәм шулук вакыта алдынгы эволюционист Ричард Левонтин, “башта материалист, соңыннан галим”

булганын шулай белдерә:

***“Безнең материализмга инанувыбыз бар, “априори” ( алдан кабул ителгән, дөрес дип саналган) инану бу. Безне дөньяга материалист ачыклау китерегә мәҗбүр итүче нәрсә гыйлемнең методлары һәм кануннары түгел. Киресенчә, материализмга булган “априори” бәйлелегебез сәбәпле, дөньяга материалист ачыклау китерүче эзләнү методлары һәм төшенчәләрне булдырабыз. Материализм абсолют дөрес булганы өчен, теологик берәр ачыклауның сәхнәгә керүвенә рөхсәт бирмиячәкбез.”*** (Richard Levontin, “The Demon-Haunted World”, The New York Review of Books, 8 нче январь, 1997, 28 нче бит).

Бу сүзләр, дарвинизмның материалист фәлсәфәгә бәйле булувы сәбәпле, яшәтелгән бер догма икенлегенә ачык буларак ишарәт итә. Бу догма маддәдән башка һичбер барлык булмаганын исәпләр. Шул сәбәпле, җансыз, зиһенсез маддәнең яшәешне яратувына инаныр. Миллионннарча аермалы җанлы төрләренең; үрнәк өчен кошларның, балыкларның, жирафларның, юлбарысларның, бөҗәкләрнең, агачларның, чәчәкләрнең, китларның һәм кешеләрнең маддәнең үз эчендәге тәэсирләре аркылы, ягъни яуган яңгыр, яшнәгән яшен сәбәпле, җаннсыз маддәнең эченнән килеп чыгувын кабул итәр. Чынлыкта исә, бу һәм акылга һәм гыйлемгә каршы килә. Ләкин, дарвинистларның үзләренең әйтеме белән әйткәндә, “теологик берәр ачыклауның сәхнәгә кермәве” өчен моны яклауны дәвам итәләр.

Җанлынарның килеп чыгышына материалистлар кебек “априори” итеп карамаган кешеләр исә, шул ачык хакыйкатьне күрәчәкләр: бөтен җанлылар өстен бер көч, белем һәм акыл иясе булган Яратучының әсәре. Яратучы – бөтен космосны юктан бар иткән, иң кимчелексез рәвештә ситемалаштырган һәм бөтен җанлыларны яратып аларга сүрәт биргән Аллаһ.

## ДӨНЬЯ ТАРИХЫНЫҢ ИҢ ТӘЭСИРЛЕ СИХЕРЕ – ЭВОЛЮЦИЯ ТЕОРИЯСЕ

Монда шуны да билгеләп үтәргә кирәк, ал - карарсыз, һичбер идеологиянең тәэсире астында калмыйча, барытик акылын һәм мантыгын кулланучы һәркеше, белем һәм мәдәнияттән ерак җәмгыятьләрнең хорафатларын хәтерләткән эволюцияия теориясенә ианувы мөмкин түгел икәнлеген җиңеллек белән аңлаячак. Югарыда белдерелгәнчә, эволюцияитеориясенә иманучылар зур берәр пробирка эченә атомнарны, молекулаларны, җансыз маддәләрне тутырган хәлдә, боларның кушылмасыннан заман эчендә фикер йөртүче, аңлаучы, ачышлар ясаучы профессорларның, университет студентларының, Эйнштейн, Хаббл кебек галимнәрнең, Фрэнк Синатра, Чарльтон Хостон кебек музыкантларның, моның белән бергә боланнарның, лемон агачларының, канәфер гөлләрнең чыгувына инаналар. Өстәвенә бу уйдырмаларга инанучылар – галимнәр, профессорлар, мәдәниятле, мәгарифле кешеләр. Шул сәбәптән, эволюция теориясен “дөнья тарихының иң бөек һәм иң тәэсирле сихере” дип билгеләү бик урынлы. Чөнки кешеләрнең бу дәрәҗәдә акылларын башларыннан алган, акыл һәм мантык белән фикер йөртүләренә мөмкинчелек бирмәгән, күзләрен пәрдә белән каплаган кебек бик ачык булган хакыйкатьләрне күрүләренә комачау иткән тагын берәр башка инану яки өйрәтмә юк. Бу иске мисырлыларның кояш алласы Рага, Африкада кайбер кабиләләрнең тотемнарга, Сәбә халкының кояшка табынувыннан, Ибраһим пәйгамбәр (а.с) кавеменең үз куллары белән ясаган потларына, Муса пәйгамбәр (а.с) кавеменең алтыннан ясаган бозауларына табынуларыннан да бик күпкә хәтәр һәм акыл алмаслык сукырлык. Чынлыкта бу халәт, Аллаһ Көръәндә – ишарәт иткән акылсызлык. Аллаһ кайбер кешеләрнең аңлаешлары томалачагын һәм хакыйкатьләрне күрмичә гаҗиз халәткә төшәчәкләрен күп кенә аятьлерендә белдерә. Бу аятьләрнең кайберләре шундый:

***Шиксез, инкяр итүчеләрне кисәтсәң дә, кисәтмәсәң дә алар өчен барыбер. Аллаһ аларның йөрәкләренә һәм колакларына тамга суккан; күзләрендә пәрдәләр бар. Һәм бөек газап аларныкы. (Бакара сүрәсе, 6-7).***

***... Йөрәкләре бар, алар белән төшенеп аңламаслар. Күзләре бар, алар белән күрмәсләр. Колаклары бар, алар белән ишетмәсләр.***

***Болар хайваннар кебек, хәтта тагын да түбәнрәк. Менә болар гафиль булучылар. (Араф сүрәсе, 179).***

Аллаһ Һиждр сүрәсендә исә, бу кешеләр хәтта могҗизаларны күрсәләр дә, инанмыйча тәкәбберләнәчәкләрен шулай белдерә:

***Аларга күк йөзеннән берәр ишек ачсак, аннан югары күтәрелсәләр дә, шиксез: Ккүзләребезгә нидер булды, белки без сихерләнгән бер туплылык",-диячәкләр. (Һижр сүрәсе, 14-15).***

Бу хәтле киң массага бу сихернең тәэсирле булувы, кешеләрнең хакыйкатьләрдән бу хәтле ерак тотылулары һәм 150 елдан бирле бу сихернең бозылмавы исә, сүз белән аңлатыла алмаслык, хәйран калдыручы хәл. Чөнки берәр яки берничә кешенең була алмаган сценарияләргә, уйдырмалар һәм алогизмнар тулы нәрсәләргә ышануларын аңлап була. Әмма, дөньянын дүрт ягындагы кешеләрнең, зиһенсез һәм җансыз атомнарның очраклы берәр карары белән бер арага килеп, могҗизалы организацияне, дисциплинаны, акылны һәм зиһенне күрсәтүче, кимчелексез система белән эшләүче космосны, җанлылар өчен яраклы һәртөрле сыйфатларга ия булучы Дөнья планетасын һәм сансыз комплекслы системаларны үзендә ташучы җанлыларны барлыкка китергәннәренә ышануларын "сихердән" башка берәр нәрсә аркылы аңлатып булмый.

Шуңа да, Аллаһ Көръәндә инкярчы фәлсәфәне яклаучы кайберәүләр тарафыннан ясалган сихерләрнең кешеләргә тәэсир иткәнлеген Муса пәйгамбәр (а.с) һәм фирьгавен арасында булган бер вакыйга аркылы безгә белдерә. Муса пәйгамбәр фирьгавенгә хак динне аңлатканда, фирьгавен Муса пәйгамбәргә (а.с) аның "белгеч сихерчеләре" һәм халык тупланачак җирдә каршылашуларын сөйләр. Муса пөйгамбәр (а.с) сихерчеләр белән карчылашкач, башта сихерчеләргә үзләренең белгәннәрен күрсәтүләрен әмер итә. Бу вакыйганы аңлатучы аять шулай:

***(Муса):"Сез атыгыз!",-диде. (Таякларын) атканнан соң, кешеләрнең күзләре сихерләнде, аларны дәһшәттә калдырдылар һәм (уртага) бөек сихер китергән булдылар. (Араф сүрәсе, 116).***

Күрелгәнче, фирьгавеннең сихерчеләре үзләре ясаган “алдатмалар” аркылы, Муса пәйгамбәр (а.с) һәм аңа иман иткәннәрдән башка, кешеләрнең һәммәсен дә сихерли алганнар. Әмма, аларның атканнарына каршы буларак, Муса пәйгамбәрнең (а.с) уртага салган дәлиле аларның бу сихерен тәэсирсез калдырган. Көръәндә бу “уйдырмаларын йотты” дип китерелә:

***Без дә Мусага: “Асаңны (таягыңны) ат!”-дип вахый кылдык. (Ул да аткач) бер карадылар ки, ул бөтен уйдырганнарын җыя, туплап йота бирә. Шулай итеп хак урынын тапты, аларның бөтен эшләгәннәрен яраксыз кылды. Анда җиңелгән булдылар һәм түбәнсетелгәннәр буларак йөз асты калдылар. (Араф сүрәсе, 117-119).***

Аятьләрдә дә белдерелгәнчә, элеккеге заманнарда сихер аркылы халыкка тәэсир итүче бу кешеләрнең эшләгәннәре ялган икәнлеге аңлашылувы белән, югарыда әйтеп үтелгән кешеләр түбәнчелеккә төшкән. Хәзерге көндә дә, бер сихернең тәэсире сәбәпле, фән кыяфәтендә соңгы дәрәҗәдәге уйдырмаларга инанган һәм аларны яклар өчен тормышларын багышлаганнар, әгәр бу ялганнардан ваз кичмәсәләр, хакыйкатьләр бөтенлеге белән ачыкка чыккач һәм “сихер бозылгач” түбәнчелеккә төшәчәкләр. Шуңа да, якынча 60 яшенә чаклы эволюцияны яклаган һәм атеист фәлсәфәче булган, ләкин, соңыннан хакыйкатьләрне күргән Малколи Маггерайдж, эволюция теориясенең якын киләчәктә ни хәлдә булачагын шулай ачыклый:

***“Мин үзем эволюция теориясенең, бигрәк тә ул кулланылган аланнарда, киләчәкнең тарих китапларындагы иң бөек анекдот булачагын аңладым. Киләчәк нәсел бу хәтле черек һәм билгесез гипотезаның ышана алмаслык акылсызлык белән кабул ителүвен хәйранлык белән каршылаячак”.*** (Malcolt Muggeridge, “The End of Christendom”, Grand Rapids: Eerdmans; 1980, 43 нче бит).

Бу киләчәк ерак түгел, киресенчә, бик якын киләчәктә кешеләр “очраклы сәбәпләрнең” иляһ була алмаганлыкларын аңлаячаклар һәм эволюция теориясе дөнья тарихының иң бөек уйдырмасы һәм иң көчле

сихере буларак танылачак. Югары тизлек белән бу көчле сихер дөньякүләм рәвештә юкка чыга башлады. Эволюция алдатмасының серен өйрәнгән күп кенә кеше, бу алдатмага ничек килеп эләккәне турында хәйранлык һәм шашкынлык белән уйлана.

***... Син Бөек, безгә өйрәткәнеңнән башка безнең һичбер белгәнебез юк. Чыннан да, Син һәрнәрсәне белуче, хөкем һәм хикмәт иясе. (Бакара сүрәсе, 32).***

**Ишарәтләр**

Профессор Джордж О. Абель, “Космосның ачылышы”, 67 нче бит.

“Миллият” газетасы, 19 нчы июль, 1998.

Карл Сэйгэн “Космос. Галәмнең һәм яшәешнең серләре”, 101 нче бит.

“Хөррият, яшәеш”, 14 нче декабрь, 1997.

“Хөррият” газетасы, 19 нче ноябрь, 1997.

“Хөррият” газетасы, 29 нче июль, 1997.

Пауэл Дэвис, “Тәңре һәм яңа физика”, 51 нче бит.

Доктор Джон Гуаббин, “Омега ноктасы”, 128 нче бит.

“Белем. Техника”, 185 нче сан.

Туна Ташкын , “Космосның теге ягы!, 24 нче бит.

“А.д.е.”, 62 нче бит.

Туна Ташкын, “Космосның серләре”, 278 нче бит.

Паул Дэвис, “Тәңре һәм яна физика”, 51 нче бит.

“Хөррият” газетасы, 17 нче август, 1997.

Карл Сэйгэн, “Космос. Галәмнең һәм яшәешләрнең серләре”, 98 нче бит.

“А.д.е.”, 98-99 нчы битләр.

“А.д.е.”, 101 нче бит.

“Сабах” газетасы, 12 нче апрель, 1992.

Вальтер Альварез, “Т. Рэкс һәм Кыямәт Көненең яратучысы”, 11 нче бит.

“А.д.е.”, 11 нче бит.

“Сабах” газетасы, 14 нче март, 1998.

Пауэл Дэвис, “Соңгы өч минут”, 3 нче бит.

“А.д.е.”, 1-2 нче битләр.

“Миллият” газетасы, 19 нчы июль, 1998.

“Сабах” басмаханәсе, “Хайваннар энциклопедиясе”, 1776-1779.